ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 5 (352)
МАЙ 2021



ИЗГЕ ҖАН



6+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин,Катерина Котова, Ксения Сёмина, Равил Фәйзуллин, Нурсөя Шәйдуллина
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Казанның күренекле хәйриячесе Әсгать Галимҗанов. Фото Г. Ризванов архивыннан.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-1393
Басарга кул куелды: 17.05.2021
Басмадан чыкты: 21.05.2021

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БӘХЕТ НӘРСӘДӘ?

Бары тик санаулы массакүләм мәгълүмат чаралары гына журналистиканың үзегенә кешене кайтарырга тырыша. Каләм әһелләрен туры сүздән, үз фикерләреннән, кешегә кызганулы, кайгыртучан мөнәсәбәттән һәм журналистның төп миссиясе – үз мәкаләләренең геройларына ярдәм итү теләгеннән аерган замана җилләре йогынтысында югалткан кешене. Кайда ул булышу! Чираттагы тау-тау яңалык-хисапны тапшырасы, өлгер-елгыр блогерларны куып тотып узасы, социаль челтәрләрдә күбрәк лайклар җыясы бар!.. Фикер йөртергә, уйларга, төшенергә, кызганырга һәм булышырга – бүгенге көн журналистикасының моңа вакыты калмый. Көндәлек ыгы-зыгы аны бөтереп алган. Шуңа күрә безнең бу санныбыз кадерлерәк тә, дип уйлыйбыз. Ул изге җаннар, игелекле гамәлләр кылучылар һәм тормышыбызны ямьлерәк итүчеләр турында. Алар кылган гамәлләрдә иң мөһиме лайклар, телгә алулар саны түгел, бәлки, кешелеклелек, кеше булып калу ихтыяҗыдыр. Бәхетнең асылын, тормышларының мәгънәсен алар әнә шунда тапканнар һәм табалар.

Сезнең кешелекле редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары ТИК ТАТАРСТАНДА

СУГЫШНЫҢ АКЛЫ-КАРАЛЫ СУРӘТЕ

Старшина Харис Якупов фронттан алып кайткан трофей бик кадерле: сугыш тынып торган арада землянкаларда, окопларда ясалган 250 рәсем... Сугышка алынганнан соң беренче рәсемен ул 1941 елның декабрендә ясый. Соңгысын – 1945 елның 9 маенда. Автор рәсемгә үз кулы белән язып та куйган: «Наши войска вступают в Прагу. 1945». Фронтовик рәссамның рәсемнәре – сугышның документаль шаһитлары. Җиңүдән соң Якупов танылган рәсем остасына әверелә, аның әсәрләре Третьяковкада һәм илебезнең башка бик күп сәнгать галереяларында саклана.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. **Гап-гади миллионер**
Колхоз базары олаучысы кемгә машина һәм фатир бүләк иткән

14. **Игелеклек феномены**
Казанда XIX гасырның иң эре милли проектын ничек гамәлгә ашырганнар

18. **Александр пассажы, Шамов хастаханәсе, «Мөхәммәдия»...**
Хәйрияче бабаларыбыз безгә нинди бүләкләр калдырган

28. **Аклы-каралы шакмаклар шифасы**
Шахматлар үсәргә һәм ныгырга ничек булыша

32. **Изге ниятләр һәм тәмугка юл**
Кемнәргә ярдәм итүнең мәгънәсе юк

38. **COVID-19га каршы тору**
Бизнес һәм волонтёрлар пандемия белән ничек көрәшә

42. **Авыл хуҗалыгы**
Басу-кырларны эшкәртү нәтиҗәләре өчен кем җаваплы

игелекле эшләр

48. **Ут күршеләребез**
Киров татарлары Иске Пенәгәрне ничек итеп «икенче Мәскәүгә» әйләндергәннәр

54. **Милли ашлар**
Марича өчпочмак ничек була

62. **Рафаэль Мостафин истәлегенә**
Якты шәхес

64. **«Әбидә кунакта» проекты**
Казларда да аккош мәхәббәте

мәңгелек кыйммәтләр

70. **Сугыш кайтавазы**
Татарстанлылар Җиңүне ничек якынайткан

72. **Сугыш еллары хатирәсе**
«Кайтып җиткәч, өйгә кермәдең»

74. **Тыелган мәхәббәт**
Фин кызының сөю тарихы ничек тәмамланган

78. **Тарих сәхифәләре**
Садрый Максуди язмышы

82. **Татар авыллары**
Олы Тигәнәле – тарихлы авыл

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

29.04

Михаил МИШУСТИН, РФ Премьер-министры, – Казанда, Евразия хөкүмәтара совет утырышында:

– Без катлаулы чорда эшлибез: пандемия, региональ кризислар, сәүдә сугышлары – әлеге проблемалар Көнбатышның башка илләрнең эчке эшләренә тыкшыну, көчле сәяси һәм икътисадый басым белән катлаулана. Әмма хәтта әлеге шартларда да бердәм базарны ныгыту, товарларны, хезмәт күрсәтүләрне, капиталны һәм эшче көчләрне алга этәрү максатында чикләүләрне алып ату өчен без нәтиҗәле карарлар кабул итәбез.

Фото ТР Президенты сайтыннан

7.04

Резедә БОДРОВА, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының тернәкләндерү медицинасы буенча штаттан тыш баш белгече:

– Барлык халыкара тәкъдимнәрдә бары тик прививканың гына коронавирусның, шул исәптән икенче тапкыр авырганда җиңел узуын гарантияли ала дип танылa. Әйе, вакцинадан соң да авыру йоктыру ихтималы 10-15%, әмма илебездә уйлап табылган прививка бөтенләй авырмауга иң югары гарантияне бирә.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

23.04

Герман ГРЕФ, Саклык банкы идарәсе рәисе, – «Tatarstan Today. Ачык дөнья» программасы эфирында:

– Татар халык ашларын бик яратам, шулай да, чәкчәккә тиңнәр юк. Берәр бәйрәмгә күчтәнәч итеп чәкчәк җибәргәндә мин күңелсезләнәм, чөнки ашый башласам, туктый алмыйм – ашап бетерәм... Татарстанлылар минем күз алдында республиканы яңадан торгыздылар. Бүген биредә булу бик күңелле. Хәзерге вакытта бик күп туристларның Казанга килүен беләм. Татарстанның, Казанның, башка шәһәрләрнең элек нинди булуларын мин күрдем. Күз алдымда диярлек миллионлаган татарстанлының тырыш хезмәте республиканы иң заманча, кунаклар өчен дустанә һәм кунакчыл төбәккә әверелдерде.

акыллы гамәлләр /

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Әсгать Галимҗанов тормышның мәгънәсен **НӘРСӘДӘ** күргән

Казанда XIX гасырның иң эре милли проектын **НИЧЕК** гамәлгә ашырганнар

Хәйрияче бабаларыбыз безгә **НИНДИ** бүләкләр калдырган

КЕМГӘ ярдәм итүнең мәгънәсе юк

Кырларны эшкәртү нәтиҗәләре өчен **КЕМ** җаваплы

ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛ КЫЛУЧЫЛАР

Искиткеч тарихлар... Алар Казан губернасы, ТАССР, Татарстан архивларында сакланган игелекле эшләр турында.

ИЗГЕ ҖАН

Татарстанда июнь аенда елның иң яхшы хәйриячеләренең исемнәре аталачак. Бу – ел саен уздырыла торган традиция, һәм Татарстанда игелекле гамәлләр кылучыларның күбәя баруын күрү бик күңелле күренеш. Хәзерге заманның иң атаклы Казан хәйриячесе, «ярлы миллионер» Әсгать Галимҗанов турында китапны чыгару быел әлеге чарага туры китерелде. Әсгать Галимҗанов озак еллар дәвамында Татария, Чувашия, Башкирия балалар йортларына булыша, Әрмәнстандагы җир тетрәү вакытында зыян күргәннәргә, «Курск» су асты көймәсендә һәлак булганнарның гаиләләренә акчалата ярдәм күрсәтә. Әлеге игелекле эшләрне башкара алганга, ул үзен гомерен заяга үткәрмәгән иң бәхетле кеше дип саный.

«Изге җан. Лучший из нас» китабын бастыруның инициаторы – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев. Китап Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә чыгарыла.

«Татарстан» журналына китап турында проект җитәкчесе – ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева һәм басманы төзүче авторларның берсе – ТР Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина сөйләде.

ИЗГЕЛЕК ҺӘМ ИГЕЛЕК ХАКЫНДА

Ләйлә Фазлыева, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, заманча дөнья сурәтен хәйриячелек-иганәчелек-филантропия–меценатлык-попечительлек-волонтерлык һәм альтруизмнан башка күз алдына да китереп булмавы турында.

ИГЕЛЕК ҺӘМ ИЗГЕЛЕКНЕҢ АСЫЛ МӘГЪНӘСЕ

– Минемчә, хәйрияче икән, ул һәрвакытта да акча белән генә бәйле түгел. Хәйрияче – беренче чиратта, рухы белән көчле кеше, аның җан фәлсәфәсе үзгә.

Заманча дөнья сурәтен хәйриячелек-иганәчелек-волонтерлык-филантропия-меценатлык-попечительлек-миссионерлык-альтруизм кебек төшенчәләрдән башка күз алдына да китереп булмый, алар безнең тормыш-көнкүрешнең бер өлешенә әйләнде.

«Игелек» белән «изгелек» сүзләренең мәгънәләре охшаш, шуңа да хәйриячененең төп нияте – кемнеңдер яки нәрсәнеңдер бәхете, глобаль мәгънәдә – дөньяны яхшы якка үзгәртү хакына гамәл кылу. Лев Толстойда ничек иде әле? «...Безнең гомер – игелеккә омтылу ул».

Республикабызда үз вакыты һәм акчасын мохтаҗларга ярдәмгә, социаль әһәмияттәге проблемаларны хәл итүгә сарыф итүче кешеләрнең һаман артуы җәмгыятебез камиллегенең мөһим индикаторы булып тора.

ЯРДӘМ ИТҮГӘ ИХТЫЯҖ

Безнең республика һәрвакытта да мәхрүм ителгән, авыру-мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга әзер торган кешеләргә бай булды.

Зур сәнәгать предприятиеләре традицион рәвештә хәйриячелек эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Һәм бу әлеге предприятиеләрнең хәйрия белән шөгыльләнерлек зур финанс мөмкинлекләре булган өчен генә дә түгел. Иң әүвәл бу – предприятие җитәкчеләре һәм коллективларының социаль әһәмияттәге фәкыйрьлек, ятимлек, инвалидлык проблемаларын хәл итүгә, шәфкатьлелек һәм кешеләрне яратуның күпгасырлык традицияләрен популярлаштыруга эчке ихтыяҗы булу.

Республика икътисадының флагманнары даими рәвештә төрле социаль проектларны гамәлгә ашыра. «Татнефть» компаниясе проектлары даими алып барыла. «Нәфис» компанияләр төркеме, «ТАИФ» компаниясе, «Ак Барс» холдингы, КАМАЗ, «РИТЭК», «Таттелеком», «Бәхетле» кибетләр челтәре ел саен хәйриячелек ярдәме күрсәтә.

«Ел хәйриячесе» республика конкурсы тарихы шуны күрсәтә: хәйриячелек кече бизнес предприятиеләре, коммерциячел булмаган оешмалар һәм гомумән, битараф калмаган кешеләр тормышының аерылгысыз бер өлешенә әверелә бара.

МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ БУЛЫШУ. ҺӘМ УЛ ГЫНА ДА ТҮГЕЛ

Республикада җәмәгать филантропиясе институты дистәләрчә еллар дәвамында

Фото: Ната Смирнова

үстерелеп килә. Мәсәлән, 2007 елдан башлап, Хәйриячелек эшчәнлеге мәсьәләләре буенча республика советы башлангычы һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов хуплавы белән аз керемле, күп балалы гаиләләргә, асрамага алынган балаларга, инвалид балаларга адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан «Мәктәпкә әзерләнергә булыш» дигән хәйрия акциясе үткәрелә.

Мәктәп портфеленә, гадәттәгечә, канцелярия товарлары, дәфтәрләр, хезмәт һәм рәсем дәресләре өчен кирәк-яраклар салына. Боларга акча җәлеп итү ысуллары исә яңа технологияләр аша башкарыла: хәйрия аукционнары; бер көнлек хезмәт хакын күчерү; игелекле гамәлләр марафоннары; сәүдә үзәкләренә мәктәп кирәк-яраклары җыю өчен тартмалар урнаштыру.

2020 елда акциягә йомгак ясала – аз керемле гаиләдән булган 18284 мәктәп баласына ярдәм күрсәтелгән. Гомуми суммасы – 37 219 399 сум.

2013 ЕЛ – АЕРЫМ БЕР ЧОР

Игелеклелек һәм волонтерлык үсешендә 2013 ел аерым бер чор булды. Яшь, шат күңелле Универсиада безнең тормышка өермә булып бәреп керде. Универсиада-2013 волонтерлары игелек кылу буенча дөньякүләм дәрәҗәдә яңа практика булды. Бөек спорт вакыйгасыннан мирас булып калган волонтерлык эшчәнлеге технологияләре күпсанлы халыкара чаралар аша узды, һәм алар бүген дә сафта. Бүген республикада 1247 волонтерлык берләшмәсе бар, аларда 60 633 кеше исәпләнә. Искиткеч куәтле көч!

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев бу турыда: «Волонтерлык хәрәкәте – барыбыз өчен дә, бөтен җәмгыять өчен матур күренеш. Ә һәркем өчен ул – уңышка юл», – дигән иде.

КЕШЕ ХӘСРӘТЕНӘ БИТАРАФ БУЛМАУ

Татарстанлыларның күбесе тарихка кереп калган күренекле хәйриячеләрдән уйламыйча да ун кешене атый аладыр – аларның фамилияләре еш яңгырый, исемнәре йортларга, паркларга бирелгән, алар кылган игелекле гамәлләр турында Татарстан кунакларына экскурсия вакытында сөйлиләр. Болар – уңышка ирешкән эшкуарлар Яков Шамов, Иван Алафузов. Болар – сәүдәгәр Әҗемовлар, Апанаевлар, Борнаевлар, Крестовниковлар, Казаковлар, Крупенниковлар, Юнысовлар династияләре...

Хәзерге заманда хәйриячеләр арасында мохтаҗларга акчалата яки башка төрле ярдәм күрсәтүче гади кешеләр дә торган саен ешрак очрый. «Бәләкәй принц»тагы кебек «сизгер йөрәкле» кешеләр алар. Аларның йөрәкләре ярдәмгә мохтаҗларның хәсрәтенә битараф калмый. Мәсәлән, **Лениногорск районыннан ветеран Рәсим Мулла улы Гәрәев** 87 яшендә туган авылында Бөек Җиңүгә өлеш керткән авылдашлары истәлеген мәңгеләштерергә ниятләгән. Бу идеясен уллары һәм оныклары хуплаган, һәм 2019 елда аның акчасына Сокман авылында Хәтер мемориалы куелган.

Яшел Үзәннән сугыш ветераны Николай Петрович Лазарев инде тәҗрибәле хәйрияче. Ел саен ул 11 нче мәктәптә «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә укуда, спортта һәм җәмәгать эшләрендә уңышларга ирешкән чыгарылыш сыйныфы укучыларына акчалата грант тапшыра.

Спас районыннан Валентина Федоровна Борисова өчен шәфкатьлелек һәм ярдәм итү бигрәк тә кече улы Василийның үлеменнән соң ихтыяҗга әйләнгән.

Улы кечкенәдән башкаларга ярдәм итәргә омтылган. «Бервакыт, – дип искә төшерә ул, – өйгә балык тотып кайткан. Соңрак уха пешерербез, дидек. Вася коймак ашады да урамга йөгерде. Бераздан кайтты да: «Теге балыкны бирик әле...» – ди».

Улының игелекле йөрәгенә һәм якты истәлегенә багышлап, Валентина Федоровна ул укыган мәктәптәге мохтаҗларга ярдәм итәргә тырыша. Полянка мәктәбенә видеокамера, ашханәсенә савыт-саба бүләк иткән, 2011 елдан бирле күп балалы һәм социаль яктан якланмаган гаиләдән булган өч баланың ашханәдә туклануы өчен түләп бара, Яңа ел бүләкләре ала...

2012 елдан бирле Мамадыш районы Түбән Ушма авылында спорт белән шөгыльләнүчеләр саны өч тапкырга арткан. Сәбәбе – яңа спорт комплексы. Элеккеге «Кызыл флаг» хуҗалыгына инвестор булып килгән эшкуар Рифат Мотыйгуллин Түбән Ушма авылы кешеләренә шундый бүләк ясаган. Былтыр пандемия вакытында **Рифат Мотыйгуллин** Алабуга, Яр Чаллы, Казан арасында йөри торган ашыгыч ярдәм машиналарының ягулыгына киткән чыгымны үз өстенә алган.

Балтачтан Гөлнара Камил кызы Якупова, гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә 22 ел эшләү дәверендә, мохтаҗ кешеләргә ярдәм кулы сузу өчен бер кешенең генә дә көче җитүен күп тапкырлар раслаган. Гөлнара Камил кызы йортсыз-җирсез калган өлкән яшьтәге апаны үзенә сыендыра. 2 нче төркем инвалиды булган Гөлфирә апа Гыйльмуллина Якуповларда бер елга якын кадер-хөрмәттә яши. Бөтенләй чит гаиләнең ихластан ярдәм итүе Гөлфирә апаның җанын тынычландырган.

Гөлнара Камил кызының игелекле гамәлләре республика масштабында булмаса да, мохтаҗ кешеләргә бик кирәк. Ул 1 нче төркем инвалиды Эльза Вәлиевага газе-

та яздырган, ялгыз яшәүче инвалид Ания Нигъмәтҗанованың су торбасын алмаштырттырган...

УҢЫШЛЫЛЫК ҮЛЧӘМЕ

Бүген социаль челтәрләр хәйриячелек эшчәнлегенең яңа технологияләрен формалаштыра, алар ап-ачык һәм адреслы ярдәм итү мөмкинлеген бирә. Андый хәйриячеләргә ачык мисал – Казандагы «Россия җаны. Волонтерлар» иҗтимагый хәрәкәте эшчәнлеге. Алар игелекле гамәлләрдә катнашудан тәм табарга өйрәтә, чөнки ни дәрәҗәдә уңышка ирешүең икътисади казанышлар белән генә түгел, ә мохтаҗларга ярдәм итү белән дә үлчәнә.

ИГЕЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР РЕСПУБЛИКАСЫ

Без – игелекле кешеләр республикасы. Һәм без моның шулай икәнен безнең кешелеклелек сыйфатларыбыз сыналган узган елда аңладык. COVID-19 таралу белән бәйле рәвештә, Татарстанда өлкәннәргә һәм авыру йоктыру куркыныч нәтиҗәләргә китерү ихтималы зур булган төркемгә кергән кешеләргә өстәмә ярдәм күрсәтү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырылды.

Казанда ялгыз әби-бабайларга азык-төлек һәм даруларны бушлай китерә торган «Ярдәм итәбез!» колл-үзәге эшләде. «Ак Барс Созидание» хәйрия фонды, предприятиеләрдән иганә җыеп, ул акчага «Задень.ру» Логистика компаниясе» ҖЧҖ керемнәре яшәү минимумыннан азрак булган өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә азык-төлек илтеп бирүне оештырды.

Казан Башкарма комитеты да, «Бәхетле» ҖЧҖ белән берлектә, башкаладагы аз керемле кешеләргә азык-төлек белән ярдәм итте.

«Россия җаны. Волонтерлар» исә республиканың муниципаль районнарындагы өлкән яшьтәге гражданнарга бушлай ашамлык җыелмалары таратты.

«Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» масштаблы хәйрия акциясе былтыр май-июнь айларында Татарстанның 55 мең аз керемле гаиләсен һәм ялгыз картларны азык-төлек белән тәэмин итте. Ашамлыклар зур предприятие җитәкчеләре, бизнес хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре һәм барлык битараф булмаган гражданнарның акчасына сатып алынды.

Азык-төлек җыелмаларын республика муниципаль районнары, шәһәр округларының логистика үзәкләреннән волонтерлар белән бергәләп тараттылар.

Татарстан шулай ук «Магнит» ҖЧҖ нең күп балалы гаиләләрне азык-төлек белән тәэмин итү хәйрия акциясен дә хуплады.

ӘСГАТЬ ГАЛИМҖАНОВНЫҢ ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Татарстан меценатлары һәм хәйриячеләре – тыйнак кешеләр, үз исемнәре яңгыраганны бик өнәп бетермәсә дә (һәм бу аңлашыла да), аларның игелекле эшләре турында барыбыз дә белеп торырга тиеш дип саныйм. Илһамланыр өчен, үрнәк алыр өчен, кеше булып калыр өчен. Шуңа күрә дә зур игелек һәм ул игелекне кылган олы йөрәкле бәләкәй кеше турындагы «Арабыздан иң яхшысы» дигән үзенчәлекле китапның басылып чыгуын бигрәк тә сөенеп кабул иттем. Озакламый китапны республиканың район һәм мәктәп китапханәләрендә укып булачак. Китапка Әсгать Галимҗанов турында соңгы елларда массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан бөтен материаллар да тупланган, һәм алар барысы бергә безне, укучыларны, гүя вакыт елгасында данлыклы якташыбызның игелекле гамәлләр дөньясына алып китә.

Татарстанда яшәүчеләр өчен Әсгать Галимҗанов – күптән инде легендага әверелгән шәхес. СССРда әле «хәйриячелек» дигән төшенчә дә булмаганда, ул – Бауман районы азык-төлек сәүдәсе олаучысы – үз хезмәте белән эшләп тапкан акчасын балалар йортларына күчергән һәм интернатларга автомобильләр бүләк иткән. Әсгать Галимҗановның ярдәме Башкортостан, Чувашстан, Иваново өлкәсе, Украинаның балалар йортларына кадәр тигән. Радиация белән агуланган Чернобыль, Әрмәнстандагы җир тетрәү, Грузиядә кар ишелмәсе төшү, «Курск» суасты көймәсе бату, Көньяк Осетиядә тоткырлар алу – бу фаҗигаләрдә зыян күргән кешеләргә Бауман районы азык-төлек сәүдәсе олаучысы ярдәменнән өлеш тигән. Туган авылында ул үз хисабына кипкән күлне торгызган, балалар бакчасы төзеткән, мәктәп укучыларына автобус алып биргән, мәчет төзелешенә булышкан. Совет тынычлык фондына Әсгать Галимҗанов советлар чорындагы акча белән 600 мең сумнан артык акча күчергән.

Картларга, ятимнәргә, бәлагә тарыган кешеләргә күпме акча белән ярдәм итүен бүген санап бетерү мөмкин дә түгел инде.

Ул ачык күңелле, намуслы, фикер йөртүдә ирекле кеше булган, үзен сәер дип атаучыларга үпкәләмәгән. Үзен бәхетле кеше дип санаган, чөнки «игелек кылыр өчен» яшәгән.

Аның гомер юлы һәм фактлары безнең аңыбызга тәэсир итә, мәгънәләрне үзгәртә һәм ориентирларыбызны камилләштерә. Әсгать Галимҗанов образы ике тапкыр мәңгеләштерелде – Казан Кремле янында Хәйриячегә һәйкәл куелды һәм менә хәзер «Изге җан. Лучший из нас» дигән китап басылып чыкты.

ТИҢДӘШ ДУСЛАР

Нурсөя Шәйдуллина, ТР Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе, кеше ни өчен матди уңайлылыклардан баш тартып, үз гомерен башкаларның иминлеген тәэмин итүгә багышлавы турында.

– Көн саен эшкә барганда Хәйрияче һәйкәле яныннан узам. Әсгать ага Галимҗанов үзе басып торган шикелле тоела. Ярый әле аны үзе исән чакта ук белә идем, эшем буенча күргәнем, аралашканым да бар. Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең Әсгать Галимҗан улы Галимҗанов белән очрашуларында да була идем. Аларның әңгәмә коруын карап тору кызыклы иде. Иркенләп, рәхәтләнеп, тыныч кына сөйләшеп утыралар. Бернинди протокол шартларына карамыйча, дуслар-яшьтәшләр кебек, бер-берсен тиң күреп...

Бервакыт Әсгать Галимҗан улы Хәйриячелек буенча совет утырышында сүз алды да, Татарстан Президентына һәйкәл куярга теләгән белдерде. Серле генә елмаеп тыңлаган Минтимер Шәймиев, аның фикерен эләктереп алып, үзенең уллары белән бергәләп, Әсгать аганың үзенә куйды һәйкәлне.

ПРЕЗИДЕНТ КУЙГАН ҺӘЙКӘЛ

Һәйкәлне ачканда Әсгать абыйның уңайсызланганын да хәтерлим. Ул арабыздан киткәч, һәйкәл тирәсендәге бакчага Әсгать Галимҗанов исемен бирергә карар ителде. Шәймиевләр гаиләсе бу бакчаны төзекләндерү эшен дә үз өстенә алды. Атаклы хәйриячебез исемен мәңгеләштерү максатында башкарган эшләренең күбесен әйтеп тә тормады бу гаилә.

ТУГАН КӨНГӘ – КИТАП

Ә мин бу китапның барлыкка килү тарихын бераз сөйләп бирергә уйладым. Әсгать Галимҗанов белән күп еллар аралашкан, аның турында беренчеләрдән булып язган журналист Габделбәр Ризванов хәйрияче турында китап чыгарырга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәч, Минтимер Шәрипович аның идеясен шунда ук күтәреп алды. Аңа Татарстан Республикасы Президенты, Хәйриячелек мәсьәләләре буенча Республика Советы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов та кушылды.

Минтимер Шәрипович китапны русча – «Лучший из нас», татарча – «Изге җан» дип исемләргә тәкъдим итте. Күренекле хәйриячене ул үзе бервакыт шулай атаган иде. Ул ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Ринат кызы Фазлыевадан әлеге проектның җитәкләвен үтенде. Ләйлә Ринат кызы – республикада хәйриячелек хәрәкәтен тергезүне актив башлап йөрүчеләрнең берсе буларак, тагын бер игелекле гамәл кылу мөмкинлегенә шатланып риза булды. Ул – иҗат кешесе, белеме буенча филолог, китапның концепциясенә күп кенә кызыклы фикерләр кертте, мәсәлән, Әсгать Галимҗанов тарихын хәзерге мәктәп укучыларының дулкынландыргыч иншалары аша бүгенге көнгә бәйләде. Балалар аның турында беләләр, язалар икән, димәк, хәйрияче арбасы үз юлын дәвам итә...

Дөресен генә әйткәндә, китапны әзерләү аның герое турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат җыярга теләү аркасында бераз сузылды. Габделбәр Ризванов җыйган мәкаләләргә журналист һәм дизайнер Розалина Мусабирова бик күп архив материаллары, башка авторлар язмалары өстәде. Ул хәтта моңарчы беркайда да басылмаган берничә фоторәсем дә тапты.

Иҗади эш барышын коронавирус та тоткарларга өлгерде, шуңа да карамастан, китапны нәшрияткә быел 2 мартка – Әсгать Галимҗановның тууына 85 ел тулу көненә әзерләп бетердек. Бу игелекле эштә катнашучы һәркемгә зур рәхмәтебезне җиткерәбез!

ХАКЫЙКАТЬ КАЯДЫР ЯНӘШӘДӘ ГЕНӘ

Минем карашка, бу китапның кадеремәгънәсе тирән, дикъкатьле һәм уйланучан укучы Әсгать абыйны безнең өчен гаҗәп тоелган киң күңеллелеккә этәргән көчне аңларга омтылачак. Шулай да, ни сәбәпле бу кеше, үзе өчен барлык матди байлыклардан баш тартып, абсолют альтруистка әйләнгән? Әсгать ага журналистлар белән бик теләп һәм иркенләп аралашса да, үзенең күпсанлы әңгәмәләренең берсендә дә бу сорауга ачык җавап бирмәгән. Ул моны махсус эшләгән дип уйлыйм. Ул безгә уйланырга-төпченергә, игелек асылына үзебезгә төшенергә мөмкинлек калдырган. Бу юлда әлеге китап безгә ярдәм итәр дип ышанам...

Фотолар Н.Шәйдуллина архивыннан

АНЫҢ ТОРМЫШ ӘКИЯТЕ

Бернинди торгынлык заманына, инфляциягә, акчасызлыкка, кешеләрнең имеш-мимешенә, аларның кырын карашына да карамастан, ул үз тормышын бер генә нәрсәгә – иганәчелеккә буйсындыра. Әсгать Галимҗановның Казан Балалар йорты белән дуслыгы берничә дистә елга сузыла...

Автор: Алсу Троицкая

НӘРСӘНЕҢ МӨҺИМ БУЛУЫН ҺӘРКЕМ ҮЗЕ САЙЛЫЙ

1987 елның 23 февралендә Казан Балалар йортының ишегалдында йөзләгән кеше җыела. Ике ир-ат һәйкәл өстенә ябылган ак җәймәне тартып ала. Һәм бергә җыелганнар каршында «Әкият» дип аталган композиция пәйда була: кулына китап тоткан тәрбияче янәшәсендә балалар һәм халык әкиятләрендәге персонажлар...

Әлеге ике ир-ат – монументның авторы Виктор Рогожин һәм бу эшкә акча белән ярдәм итүче Әсгать Галимҗанов.

Бүген, кызганычка каршы, монумент инде юк. Балалар йорты педагоглары кайчандыр һәйкәл торган урынны һәм Галимҗановның балалар белән бергә төшкән фотографияләрен генә күрсәтә алалар. Бүген Балалар йортына кергәндә эленеп торган «Алтын йөрәкләр» мактау тактасында күп кенә шәхси иганәчеләрнең фамилияләре һәм оешмаларның исемнәре язылган. Ә ул берүзе генә булган заманнар да бар иде бит.

Әсгать абыйның Республика махсуслаштырылган балалар йортына күпме игелекле эшләр эшләп калдыруы турында бу **йортның директоры Алсу Надыйршина** белән сөйләштек:

– Элеккеге олаучы миллионер дәрәҗәсенә җитеп, аннан соң үз акчаларын филантропларча тота – бу искиткеч уникаль очрак. Тугыз ел бирердә эшләү дәверендә мин аның дүртесендә аның белән таныш идем. Үзенең бөтен керемен ул тигез булмаган өч өлешкә бүлә иде: кешеләргә ярдәмгә, хуҗалыгын үстерүгә һәм гаилә кирәк-яракларына. Беренче өлеш – иң зурысы, соңгысы – иң кечкенәсе. Колхоз базарында шактый тир түгеп тапкан акчасын Бауман районы азык-төлек сәүдә оешмасының 110 сум окладка эшләүче йөк ташучысы, үзенә ашарга гына калдырып, калганын кешеләргә бирә. Ул бер сезонда күп кенә хуҗалыклар булдыра алмаган хезмәтне берүзе башкарып чыга,

Фото Казан Балалар йортыннан алынды

«иткә» дип терлек симертә. Һәм бөтен кергән керемен иганәчелеккә бирә бара. Күпләр моны аңлый алмый, ләкин нәрсәнең мөһимрәк булуын һәркем үзе сайлый.

КӘНФИТЛӘР ДӘ, ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР ДӘ...

Мөгаен, Әсгать абый үзе дә безнең Балалар йортына күпме акча бүләк итүе турындагы сорауга җавап бирә алмас иде. Нәрсә әйтсәң дә, бүгенге көндәге 100 мең сум акча белән 1987 елгы шул ук сумма арасында, үзегез беләсез, аерма шактый зур. Ул исә ел саен шундый зур суммадагы акчаларны хәйриячелеккә тота иде.

Җитмешенче елларда Салих Япеев (элеккеге Леонид Красин урамы) урамында урнашкан безнең Балалар йортының ишегалдында ат пәйда була, ул әфлисуннар төялгән арбаны көчкә тартып килә. Хәзерге вакытта ул вакытларны хәтерләгән хезмәткәрләребездән, кызганычка каршы, беркем дә калмады. Ләкин миңа кадәр эшләгән коллегаларым аның безгә еш килеп йөрүе турында сөйлиләр иде: балаларны арбага утыртып ат әйләндергән. Сабыйлар тәрәзәдән аның килүен күрүгә, ишегалдына йөгереп чыкканнар: гаджетларны һәм башка заманча «цивилизация җимешләрен» белмәгән балалар өчен үзе бер юаныч, күңел ачу була. Алай гына да түгел, Әсгать абыйның буш кул белән килмәячәген алар белә: димәк, кәнфитләр белән дә, җиләк-җимешләр белән дә сыйланачаклар...

ТУННАР ДА, АВТОБУС ТА...

Бервакыт кыш көнне чираттагы мәртәбә балалар йортына килгәч, ул балаларның салкында юка курткалардан уйнавына игътибар итә. Шулай итеп Әсгать абый бер айдан ат арбасына натураль мехтан дистәләгән тун төяп алып килә. Бүләкләрне таратканда, кыска гына итеп: «Җылы киемнән башка чын кеше булып үсеп булмый». Тагын әле уенчыклар, музыка уен кораллары, «Әкият» һәйкәле бүләк итәчәк ул... Бераз соңрак ул безнең Балалар йортына яңа «Нива» машинасы, тагын берникадәр вакыттан соң «ПАЗ» автобусы ачкычларын тапшыра: «Хәзер сабыйлар чыршы бәйрәмнәренә автобуска утырып бара алачак». Әсгать абый шуны аңлаган: балалар вакытларын балалар йортларында һәм интернатларда үткәрергә тиеш түгел, аларның чыршы бәйрәмнәренә, экскурсияләргә чыгар һәм цирк тамашаларын карар өчен мөмкинлекләре булырга тиеш. Нәкъ менә шуңа ул автобуслар сатып алып бүләк итә дә. Бу һәрвакыт шулай булды да. Узган ел гына безнең өчен искәрмә булды: кызганычка каршы, карантин аркасында, балаларны беркая да алып чыга алмадык.

...ГАРМУН КӨЕНӘ БИЮЛӘР ДӘ БУЛЫР

Ул беркайчан да тормыш рәвешен кешеләрдән яшерми, бик тыйнак яши. Безнең хезмәткәрләр аның янына кунакка баргач, ул үзенең бүләкләрен күрсәткән, чәй белән сыйлаган. Һәм без дә аны һәрвакыт шатланып көтә идек. Бигрәк тә балалар – алар гомумән капка төбенә кадәр йөгереп чыга иде, Әсгать абыйның килүен яраталар иде. Балалар аны чын дәү әтиләре кебек кабул иттеләр.

Педагоглар сөйләвенчә, бервакыт ул бәйрәмгә гармун белән килә. Балаларның чыгышларыннан соң көтмәгәндә болай ди:

– Ә хәзер, балалар, мин сезгә гармунда уйнап күрсәтәм.

Һәм шулкадәр матур уйный, балалар – кем ничек булдыра ала – туйганчы биилəр.

P.S. Килә алганда ул һәрвакыт безгә килеп йөрде. Соңга кадәр. Ишегалдында балалар белән йөрде, төркемнәргә кереп йөри иде. Аңа үзенә дә бөтен нәрсә белән танышу кызык булды. Миңа болай дия иде: «Әйе, замана хәзер башка. Совет чорында балалар бөтенесе бертөрле киемнән йөрде, ә хәзер сез аларны бик матур киендерәсез, карарга күңелле! Әкияттә яшәгәндәй яшибез». 2012 елда без Балалар йортында бик зур ремонт эшенә тотындык. Эшләр беткәннән соң, Әсгать абыйны чакырдык һәм, яңартылган төркемнәр буенча йөртеп, яңа җиһазларны, интерьерны, уенчыкларны күрсәттек. Ул һәр почмакны карады һәм канәгать калды. Балалар өчен бик куанды: «Молодец, кызым, барысын да бик яхшы эшлисең. Иң мөһиме, дөрес итеп. Кара, син нинди бай».

«20 ЕЛГА АЛДАНРАК ТУГАН БЕРЕНЧЕ ТАТАР КАПИТАЛИСТЫМЫ, ӘЛЛӘ ТОРМЫШ ЮЛЫ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ҮРНӘК ЯИСӘ ШЕЛТӘ БУЛГАН ИЗГЕМЕ? Юләрме – яисә әлеге иксез-чиксез юләрләр йортында бердәнбер нормаль кешеме?» – дип яза «Огонёк» журналы Әсгать Галимҗанов турында 1997 елда. 1990 елда ул Тереза Ана белән бергә Халыкара балалар фонды ассоциациясенең иң югары бүләге – Лев Толстой алтын медаленә лаек була – балачакны яклауга керткән гаять зур өлеше өчен. Бүләкне алганда ул үзе болай ди: «...Намуслы хезмәтем белән мин зур акчалар эшли алдым һәм гомеремнең күп өлешен бәхетле балачактан мәхрүм булган ятим балаларны кайгыртуга багышладым. Шуңа күрә мин үземне бик бәхетле кешегә саныйм һәм гомеремне заяга үткәрмәдем, дип уйлыйм. Әйдәгез, минем кадерлеләрем, тормышны кадерлик, аны тагын да яхшырак һәм миһербанлырак итү өчен, кирәк вакытларда бер-беребезгә булышыйк, кайгыртучанлык һәм игътибар күрсәтик».

2007 ел ахырында Балалар йорты попечителенә «Ышаныч һәм Тугрылык өчен» дип аталган Халыкара изге апостол Андрей Первозванный премиясен тапшыралар.

HOMO SAPIENS*. ЭВОЛЮЦИЯСЕ. КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК

«Чын фәкыйрьлектә гомер кичерүчеләргә ярдәм кулы сузу...» – мондый игелекле гамәлне Казанда һәрчак эшли беләләр. XIX гасырда Казан ярлыларга ярдәм итү комитеты бередә иң йогынтылы хәйрия оешмаларыннан берсе була. Әлеге комитет ул чорның иң зур илкүләм проекты – Император кешелеклелек җәмгыяте кысаларында оештырыла.

Автор:
Катерина Котова

1802 ЕЛНЫҢ МАЕ. КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕ

«Бәхетсезләрне, бичараларны үзләре яшәгән урыннардан – әнә шул күз яше һәм газап тулы йортлардан эзләргә кирәк. Ягымлы мөгамәлә, файдалы киңәш белән, кыскасы, барлык рухи һәм матди чаралар белән аларның язмышын җиңеләйтү – менә кайда ул чын игелек, чын изгелек...» – император Александр I нең иң югары дәрәҗәдәге фәрманы әнә шулай яңгырый. Югарыда искә алынган кешелеклелек җәмгыяте 1802 елның 16 маенда патша Россиясендә шул боерык нигезендә барлыкка килә. Йөз ел эшләү дәвамында бу хәйрия оешмасы 8 миллионга якын мохтаҗ кешегә «һәртөрле ярдәм» күрсәтә! Аларның җенесенә, яшенә һәм диненә карап тормыйча...

1816 ЕЛ. КАЗАН ЯРЛЫЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ КОМИТЕТЫ

Казан «кешелеклелек» идеясен күтәреп алган тәүге шәһәрләрдән берсе була: 1816 елда бередә җәмгыятьнең «филиалы» – Казан ярлыларга ярдәм итү комитеты барлыкка килә. Сүз уңаенн, аны оештыру шактый мәшәкатьле эш булып чыга. Комитетка хакыйкый статский советник һәм масон Василий Романовский нигез сала. Кайбер мәгълүматларга караганда, ул Казанда үз рәислегендәге масонлык орденын да оештырган кеше булып санала.

Акчалата, азык-төлек, әйберләр, тукымалар белән ел саен ярдәм итеп торырга әзер кешеләрдән ризалык турында имзалар җыю өчен аның бер елга якын вакыты китә... Нәтиҗәдә, тупланган мәгълүмат Император Галиҗәнапларына тапшырыла, ә җавап итеп аннан «иң югары рөхсәт» алына.

Тарихчылар, беренче елларда комитетка хәйрия кертемнәре шактый начар килгән, дип яза. Гасыр уртасына табарак хәл уңай якка үзгәрә. 1862 елда хәйриячеләр өчен салым ташламаларын кертү дә моңа ярдәм иткән, дигән фикер дә бар. Иганәче эшкуарлар өчен салым йөгенең гомуми күләме 10% ка кадәр кимегән, ә җирле салымнардан алар бөтенләй азат ителгән булырга мөмкин. Хәер, бу эш белән аеруча янып йөргән актив кешеләрнең тырышлыгын да исәптән чыгарырга кирәкми. Әйтик, комитетны ун елдан артык Казан шәһәре башлыгы, оештыру һәм рухландыру талантына ия Сергей Дьяченко җитәкли.

Гасыр ахырына Казан комитеты үз сафларында 150 хәйриячене туплый. 1915 елда аларның саны инде 210 га җитә, ә җәмгыятьнең капиталы 204 мең сумнан артып китә. XIX гасырның 80 нче елларында аның өчен Зур Мещан һәм Троицкая урамнары чатында махсус бина төзелә, анда комитет учреждениеләре урнаша. Бүген бу урында – инде Таҗи Гыйззәт урамы, 15 нче йорт адресы буенча – биш катлы күп фатирлы яңа бина күрергә була.

ҺӘРТӨРЛЕ ЯРДӘМ

Казан ярлыларга ярдәм итү комитеты алып барган эшчәнлек колачы белән шаккатыра. Аның карамагында хәйрия оешмаларының бик зур өлтәре эшли. Аңа картлар йортлары, остаханәләр, даруханәләр, мәктәпләр, ятимнәр өчен башлангыч училище, акылга зәгыйфьләр йорты керә. Шәһәрнең мохтаҗ кешесенә финанс ярдәме күрсәтелә. Әлеге ярдәм бер тапкыр бирелә торган акча да булырга мөмкин яисә күпмедер акча ай саен түләнеп барыла, шулай ук түләүсез торак һәм укыту, бушлай кием-салым, юридик консультацияләр һәм хәтта эшкә урнашуда арадашчылык рәвешендә дә ярдәм оештырыла. Хәйрияче табиблар исә мохтаҗ фәкыйрьне дәвалый.

Ул вакытта социаль ярдәмнең иң мөһим юнәлешләреннән берсе җәмәгать туклануын оештыру булгандыр, мөгаен. Хәйрия ашханәләре һәм мохтаҗлар өчен чәйханәләр танылган сәүдәгәрләрнең йортларында ачыла. Пләтән бистәсендә урнашкан Сәйдәшев йортындагы ашханә – өч йөз, ә Талчуктагы сәүдәгәр Щербаков йортына караган чәйханә мең казанлыга хезмәт күрсәтә алган! Сәүдәгәр Галиев, Үтәмешев, Апанаевларның хәйрия хәрчәүнәләрен ул заманда һәркем белә. Сәүдәгәр Госмановлар нәселе мөселманнар өчен бушлай ашханә оештыра, ә Юеш бистә сәүдәгәре, атаклы Соболев номерларын тоткан Иван Соболев ашханәсендә сукбайлар тукландырыла...

УПКЫНГА ТӘГӘРӘҮ

Казан ярлыларга ярдәм итү комитеты, Император кешелеклелек җәмгыяте кебек үк, 1917 елда, Россия империясе таркалган чакта, үз эшчәнлеген туктата. Ул заманда бөтенесе буталып бетә: кайчандыр «чын фәкыйрьлектә гомер кичергәннәр»нең кайберсе, ниһаять, власть тәмен татып карый, ә шул ук вакытта кайчандыр аларның химаячесе булганнарның язмышы упкынга тәгәри.

** Латин теленнән тәрҗемә итканда «Аңлы кеше».*

АЛЛАҺ ҺӘМ КЕШЕЛӘР ЯРДӘМЕ БЕЛӘН

1900 ел. Сәүдәгәр Юнысовның бик шәп өендә Казан тарихында беренче мөселман хәйрия йорты ачыла. Бу шәһәр халкының күптәнге хыялы була, аны тормышка ашырырга исә яңа филантроплык оешмасы – Казан мөселман хәйрия җәмгыяте барлыкка килү нәтиҗәсендә генә мөмкинлек туа.

1898 ЕЛ. ЯРЛЫ МӨСЕЛМАННАРГА ЯРДӘМ ИТҮ ҖӘМГЫЯТЕ

Казан мөселман хәйрия җәмгыяте яки, башка исеме белән әйткәндә, Ярлы мөселманнарга ярдәм итү җәмгыяте 1898 елда барлыкка килә һәм шунда ук диярлек үзе турында күп профильле берләшмә буларак дөньяга аваз сала, аның төп максаты – «җенесе, яше, дәрәҗәсе һәм хәл-әхвәленә карамастан, Казанның ярлы мөселманнарының матди һәм рухи хәлен яхшыртуга акчалата булышу» була.

Оешманың тиңсезлеге шунда: ул стандарт хәйрия эшчәнлеген – ярлыларга акчалата пособиеләр бирү, янгыннан зыян күрүчеләргә булышу, азык-төлек һәм кием-салым белән тәэмин итү, туган якларына кайтырга, белем алырга һәм эш табарга ярдәм итүне Казан татарларының милли һәм дини аерымлыкларын күздә тотып башкара. Шул ук вакытта үз сафларына төрледән-төрле милләт вәкилләрен, төрле дин тоткан, төрле иҗтимагый катламга караган һәм хәтта сәяси карашлары да төрле булган хәйриячеләрне туплый.

ХӘЙРИЯЧЕЛЕКТӘ БЕРЛӘШКӘННӘР

Әйтик, аның химаячеләре арасында генерал-майор Шамил Мөхәммәд-Шәфи, 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Әхмәд Хөсәенов, Салих Гобәйдуллин, Исхак Айтуганов була... Мактаулы әгъзалар исемлегендә Ольга Александрова-Гейнс, Сергей Дьяченко исемнәрен күрә аласыз. Сәүдәгәрләр династиясе варисы булган ханым хәйрия оешмасына саллы ярдәм күрсәткән. Шәһәр башлыгы Сергей Дьяченко исә җәмгыятьне төзүгә кулдан килгәнчә булышкан. Исемлектә Надель-Пружанская да бар. Татар халкына медицина хезмәтләре күрсәтә торган учреждениеләр челтәрен үстерү эшенә күп көч салган иң яхшы Казан табибларыннан берсе ул... Хәйрия җәмгыятендә зыялылар – руханилар белән, миллионерлар – яңа аякка басып килгән эшкуарлар, реформалар тарафдарлары исә үзгәрешләргә каршы торучылар белән берләшә. Бәлки, нәкъ менә шул факт илдә мөселман хәйрия оешмаларының беренчесе булган Ярлы мөселманнарга ярдәм итү җәмгыятенең инде 1915 елга ук шәһәрдәге иң зур хәйрия берләшмәләре өчлегенә керергә булышкандыр да!

ЯЛГЫЗ ИР-АТЛАРГА

Җәмгыятьнең тәүге зур хәйриячелек проекты – «хезмәткә сәләтсез» ялгыз ир-атлар өчен мөселман картлар йорты. Башта ул 10 кешегә генә исәпләнгән булса да, 1911 елда анда Казан губернасының төрле өязләреннән 13 карт яшәгән.

ФӘКЫЙРЬ ХАСТАЛАР ӨЧЕН

Медицина амбулаториясе шундый икенче учреждение була, анда ярлы-ябагайга бушлай табиб ярдәме күрсәтелә һәм дарулар бирелә. Сүз уңаеннан, халыкка хезмәт күрсәткән белгечләр арасында ул чорның иң яхшы табибларын телгә алырга мөмкин: танылган галим, гастроэнтеролог Роман Лурия, медицина профессоры Алексей Захарьевский һәм башка бик күпләр. 2 меңнән артык пациент һәм 5 меңнән артык консультация – бу амбулатория статистикасы 1911 ел өчен генә әле.

ЯТИМНӘР ӨЧЕН

Ә соңрак Постау бистәсендә тантаналы рәвештә мөселман балалар приюты ачыла, 1911 елда анда 23 ятим тулы пансионда яши. Приют карамагында бераз соңрак ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен рус-татар училищелары эшли башлый, аларда ярлы-ябагай баласы белем ала.

БӘБИ ТАБУЧЫЛАР ӨЧЕН

1912 елда җәмгыять үзенең тагын бер хыялын тормышка ашыра – мөселман хатын-кызлары өчен бала тудыру йорты ача. Анда хатын-кызларга профессиональ медицина ярдәме күрсәтелә. 1914 елда моннан 200 ләп хатын-кыз файдалана.

ГАУГАЛЫ АДЫМ

Әлбәттә, бүтән хәйрия оешмалары кебек, Казан мөселман хәйрия җәмгыяте дә, нигездә, иганә кертемнәре хисабына яши. Ләкин алай гына түгел! Аның җитәкчелеге акча җыю мәсьәләсендә үз вакыты өчен бик кыю адымга бара – хәйрия кичәләре, концертлар, спектакльләр оештыра башлый. Бу – мөселман хәйриячелеге тарихында бөтенләй яңа, бераз гаугалы да юл була. Сүз уңаеннан, аның нәтиҗәлелеге бик тиз раслана.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДА ХӘЙРИЯ АКЧАЛАРЫНА ТӨЗЕЛГӘН БИНАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Казан губернасында оештырылган хәйрия эшчәнлегенең колачы шаккатыра. XX гасыр башына Казанда гына да дистәгә якын төрле филантропик оешма исәпләнә: Телсез-чукрак балаларны тәрбияләү һәм укыту җәмгыяте, Ярлы һәм авыру балаларны кайгырту җәмгыяте, Игенчелек колонияләре һәм һөнәр приютлары җәмгыяте, Сукырлар турында кайгыртуның Мария бүлеге, Үлем очрагында үзара ярдәмләшү җәмгыяте...

Хәер, меценатлар социаль ихтыяҗларны хәл итүгә акчаларны шулай ук турыдан-туры да юллаган. Алар тарафыннан социаль юнәлешле йөзәрләгән оешма ачылган һәм йөзәрләгән бина төзелгән. Без ул заманнардагы иганәчелеккә берничә мисал гына китерәбез.

- Фәкыйрь, картайган һәм гарип гражданнарны кайгырту йорты (Казанда Ложкин хәйрия йорты)
- Казанда Александр Фон-Финкның дворян ирләр хәйрия йорты
- Чистайда «Камалия» мәдрәсәсе
- Крупенниковның Казан шәһәре сәүдәгәр, мещан һәм тар катлауларга кергән фәкыйрь, картайган һәм гарип хатын-кызлар өчен шәһәр хәйрия йорты
- Алабугада су торбаларын тулысынча алыштыру
- Казанда ваба белән авыручылар өчен хастаханә
- Чистайда Скарятин бакчасы
- Казанда Александр ятимнәр приюты
- Казанда хезмәт сөючеләр йорты (хезмәт һәм дини-әхләкый тәрбия бирү аша фәкыйрьләрне тәрбияләү өчен)
- Чистайда түбәнге һөнәр мәктәбе
- Казанда һөнәрчеләр һәм кара эшчеләр өчен Александр шәһәр хастаханәсе
- Чистайда русча-татарча башлангыч хатын-кызлар училищесы

ХӘЙРИЯЧЕЛӘР

Ольга Сергеевна Александрова-Гейнс, Александровлар сәүдә династиясе варисы, җәмәгать эшлеклесе, Казан шәһәренең мактаулы гражданины

Ибраһим Гобәйдулла улы Юнысов, 1 нче гильдия сәүдәгәр, Казан татар җәмгыяте башлыгы, нәселдән килгән мактаулы гражданин

Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитов, 1 нче гильдия сәүдәгәр, шәһәр Думасына гласный итеп сайлана, Казан губерна балалар приютлары попечительлегенең мактаулы әгъзасы булып тора

Иван Иванович Алафузов, 1 нче гильдия сәүдәгәр, мануфактур-киңәшче, нәселдән килгән мактаулы гражданин

Ибраһим Исхак улы Аппаков, 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы гражданин

Яков Филиппович Шамов, 1 нче гильдия сәүдәгәр, мактаулы гражданин, Казанның иске йолалык җәмгыяте башлыгы

Василий Львович Челышев, 1 нче гильдия сәүдәгәр, коммерция киңәшчесе, Чистай шәһәре башлыгы, шәһәрнең мактаулы гражданины

Габдулла Абдулсәлам улы Үтәмешев, 1 нче гильдия сәүдәгәр

Дмитрий Иванович Стахеев, 1 нче гильдия сәүдәгәр, Алабуга шәһәре башлыгы

Бәдретдин Абдулкәрим улы Апанаев, 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы гражданин, Казан ярлы мөселманнарга ярдәм итү җәмгыяте идарәсе рәисе

Иван Петрович Оконишников, 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы гражданин

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы Галикәев, 1 нче гильдия сәүдәгәр

Кузьма Сидорович Четвергов, 1 нче гильдия сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе

Мөхәммәтшакир Абдуллатыйф улы Хәкимов (Хәким бай), 2 нче гильдия сәүдәгәр

БҮЛӘКЛӘР

ИЗГЕ АННА ОРДЕНЫ

Гольштейн-Готторпский герцоглыгының нәсел бүләге буларак 1735 елда гамәлгә куела. Россия империясенең бүләкләү системасына Павел I указы белән 1797 елда кертелә. Дәүләт эшләрендәге уңышлар һәм хәрби казанышлар өчен тапшырыла.

ИЗГЕ СТАНИСЛАВ ОРДЕНЫ

Польша короле Станислав-Август Понятовский тарафыннан 1765 елда гамәлгә куела. 1831 елда Россия империясе орден системасына кертелә һәм әлеге иерархиясендә иң яше исәпләнә. Шунысы кызык: 1844 елдан башлап, бүләкләнүче зат христиан булмаган очракта Изге Станислав исеменең сурәте кара император бөркете сурәтенә алыштырыла башлый.

«ЗА УСЕРДИЕ» БҮЛӘКЛӘҮ МЕДАЛЕ

Россия империясенең бүләкләү системасында иң киң таралган медаль. Аның белән дәүләт каршындагы казанышлары өчен барлык катлау вәкилләре дә, ирләр дә, хатын-кызлар да бүләкләнә. Көмештән һәм алтыннан ясала, муенга тасма белән асыла, күкрәктә йөртү өчен бүләкләрнең дәрәҗәсен билгели торган орден тасмаларына беркетелә.



БЕЗНЕҢ КӨННӘРДӘ ХӘЙРИЯЧЕЛЕК ҮРНӘКЛӘРЕ

- **Казан хосписы.** Анжела Вавилова исемендәге Фонд тарафыннан меценатлар акчасына төзелә. Төзелеш әле дә дәвам итә, икенче хоспис бинасы салына.

- **«Кол Шәриф» мәчете.** Төзелеш өчен хәйрия акчалары җыюда 40 меңнән артык кеше һәм оешма катнашты.

- **Изге Болгар һәм Зөя утрау-шәһәре ядкәрләрен торгызу.** Әлеге максатларга җыелган хәйрия акчаларының өчтән ике өлешен гади кешеләр бирде.

- **БРКХнең кечкенә пациентлары һәм аларның әти-әнисе өчен гаилә кунакханәсе.** «Роналд Макдоналд йорты» Фондына килгән хәйрия акчалары хисабына оештырылды.

- **«Әни йорты» кризис үзәге.** Ул йорт-җирсез калган балалы хатыннар өчен ачылды. «Изге эшләр» («Благие дела») Фондына килгән хәйрия акчалары хисабына оештырылды.

- **Әлмәт районының Дербеден авылындагы Николай Чудотворец православие кәшәнәсе.** Шул авылда туып-үскән хәйрияче Владимир Малышев акчасына төзелде.

- **Әлки районы Татар Борнае авылындагы мәчет.** Эшкуар меценатлар Альберт һәм Дамир Шәйхетдиновларның акчасына төзелде.

- **Яшел Үзән районы Мамадыш-Әкил авылындагы юл һәм авыл зираты коймасы.** Шул авыл кешесе Тәлгать Гыйниятуллинның туган җирен төзекләндерүгә керткән өлеше.

- **Казандагы бер ишегалдындагы балалар һәм футбол мәйданчыклары** – шул тирәдә яшәүче Николай Ширяев бүләге.

- **Югары Ослан районы Татар Мәмәтхуҗасы авылындагы «Инеш чишмәсе».** Җирле меценатлар көче белән яңартылды.

- **«Люськин дом» мәчеләр приюты.** «Хотим домой» Хәйрия фонды тарафыннан шәхси акчалар хисабына оештырылды.

Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Киңәшчесе:

«Кол Шәриф» мәчетен яңадан төзү идеясе баштан ук, татулык һәм миһербанлыкка өнди торган ислам диненең үзе кебек, Татарстан халыклары арасындагы тынычлыкны ныгытуга булышты. Шуңа күрә мәчетне без бөтенебез бергә төзедек, соборны да бергә торгызыдк. Мәчет төзелешендә төп чыгымны республика нефтьчеләре күтәрде. Гәрчә мәчетне ислам республикалары акчасына төзү турындагы тәкъдимнәр булса да. Ләкин без бу тәкъдимнән әдәпле генә итеп баш тарттык. Болай дип карар кылдык: әгәр бу җәмигъ мәчете икән, аны үзебез төзергә тиеш – әлеге изге эштә катнашырга теләк белдергән барлык кешеләр белән бергә.

Әлеге карар кабул ителгән елда иген бик уңды. Мин район администрацияләре башлыкларын җыйдым да болай дидем: «Аллаһ яңгырны, яхшы һава торышын биреп торды, без икмәкне гектарыннан гадәттәгегә караганда бер-ике центнерга күбрәк алдык. Шуңа күрә, – мин әйтәм, – болай эшлибез: Аллаһ югарыдан бүләк иткән ашлыкны сатабыз, ә акчасын ядкәрләребезне төзүгә, яңартуга салабыз». Республика буенча җыелышлар башланды. Бердәм фонд төзелде. Шул рәвешле деноминацияләнмәгән акчаларда 32 миллиард сум тупланды. Әлеге изге эшкә ярдәм күрсәткәннәрнең исемнәрен теркәп бару өчен «мәңгелек китап» башладык. Кемнең күпме бирүе мөһим түгел, һәркем үз мөмкинлекләреннән чыгып сала акчаны. Иң мөһиме шунда: татарстанлылар өчен дини корылмаларны салу-торгызу уртак игелекле гамәлгә әверелде».

(«Минтимер Шаймиев» китабыннан өзек, тәрҗемә. «Жизнь замечательных людей» сериясе)

ИСЕМНӘРЕ ТАШКА КҮЧКӘН

Автор:
Катерина Котова

Таш диварларда мәңгеләштерелгән мәрхәмәтлелек үрнәкләре – башкалабызның кайбер архитектура һәйкәлләрен нәкъ менә шулай атап булыр иде. Шәһәрнең бүгенге йөзен алардан башка күз алдына китереп булмаган кебек, башкала тарихын да шул биналарга бәйле исемнәрдән башка күзаллау мөмкин түгел.



АЛЕКСАНДР ПАССАЖЫ

Бу мәгърур бина бүген дә 1000 еллык тарихлы Казанның иң матур урыннарыннан берсе булып кала бирә. Аны шәһәребезгә бик бай нәселнең варисы, хәйриячелекне гомеренең төп эшенә әверелдергән Ольга Александрова-Гейнс бүләк иткән.

Пассажны беренче гильдия сәүдәгәре, чәй магнаты, Казанның мактаулы гражданы Сергей Александровның улы Александр Александров төзеткән. Затлы-зиннәтле бинаны салып чыгу 800 мең сумга төшә – бу вакыт өчен коточкыч зур сумма булу өстенә, сәүдәгәрнең бар мөлкәтенең уннан бер өлеше булуын да искәртик! Бина проектына игълан ителгән бәйгедә яшь архитекторлар Владимир Суслов белән Николай Поздеевларның идеясе җиңә һәм проектны алар эшләп чыга. Төзелеш эшләрен «архитектурада күңелсезлекләргә урын юк» дигән шигаргә тугры оста Генрих Рушка ышанып тапшыралар. Шул рәвешле, зур чыгымнар, көчле мавыгу, кыюлык һәм талант бәрабәренә Воскресенская урамында пассаж калкып чыга.

Бинаны 1883 елның ноябрендә файдалануга тапшыралар. Казанлылар өчен монда гаҗәеп нәрсәләр күп була. Үтә күренмәле идәннәрне генә әйт син, ә аның астында – җылы ишегалды! Пыяла түбә, электр яктырткычлары – боларны үз күзләре белән күрергә ярты шәһәр халкы килгән. Биш катлы бинада хәтта лифт та була! Һава белән җылыту системасы, суүткәргеч, гаҗәеп матур баскычлар, нәзакәтле кариатида сыннары, алтын йөгертелгән су кызлары, кыңгыраулы сәгать... Дөрес булса, бу сәгать үзен ясаучы оста үлгән көнне мәңгелеккә туктап калган, диләр.

Кайбер мәгълүматлар буенча, сәүдәгәр бу бинаны сеңлесе Ольга Сергеевнага сатып биргән, кайбер чыганаклар исә Гейнсның пассажны абыйсы үлеменнән соң мирас итеп алганлыгы турында сөйли. Гүзәл архитектура бинасында хәл итәсе проблемалар да күп булган.

Соңрак Ольга Сергеевна моңарчы күрелмәгән хәйрия ярдәме күрсәтә – Казанга шәһәр музее өчен бина сатып алырга 500 мең сум көмеш бүләк итә. Сәүдәгәрлек эшендә тәҗрибәсе аз ханым шул рәвешле нәкъ менә пассажны музей хаҗәтләренә бирергә уйлый. «Хәйрия акчасы бүләк итүемнең берничә шарты бар: бу акчага барлык учреждениеләрне дә (музей һәм кибетләр – ред. иск.) үзенә сыйдырган бина сатып алынырга тиеш, ул бина Казанның Воскресенская урамында урнашып, бинаны сайлаганда минем ризалыкны алу шарт», – дип яза ул шәһәр башлыгы Сергей Дьяченкога хатында. Шулай итеп, пассаж шәһәр карамагына күчә. Бинаның чын бәясе ярты миллионнан күпкә кыйммәтрәк була, билгеле. Ник дигәндә, аның төзелешенә генә дә 800 мең сум сарыф ителеп, җиһазлау 100 мең тирәсе дип бәяләнә. Сүз уңаеннан, музейны әлеге бинада урнаштыру мөмкин эш булып чыкмый, һәм пассаж озак еллар дәвамында үзенең алдан билгеләнгән вазыйфасын үти – сәүдә галереясе буларак хезмәт итә.

Шаккаткыч кыйммәт бүләккә ия булган шәһәр хакимияте хәйриячегә ничек итеп рәхмәт белдерергә дә белми, ахыр чиктә, Ольга Александрова-Гейнсны Казанның мактаулы гражданы дип игълан итәләр, ә Илья Репин аның портретын яза. Бүген дә Татарстан Милли музеенда саклана торган әлеге картинада без көчле рухлы затлы нәсел дәвамчысын күрәбез. Ул гомерен меценатлыкка багышлый, приютлар, хастаханәләр, гимназияләр ача һәм аларны тәэмин итә, төрле фондларга зур суммалар бирә. Хәйриячеңең фамилиясен йөрткән, гыйбрәтле язмышлы мәһабәт пассаж исә Ольга Александровнаның мәрхәмәтлелеген күрсәткән иң зур ядкәрдер мөгаен.

ҺИЧ АРТТЫРУСЫЗ, АЛЕКСАНДРОВ ТИҢДӘШСЕЗ АРХИТЕКТУРА ҖӘҮҺӘРЕ, ШӘҺӘРДӘГЕ ИҢ МӘҺАБӘТ БИНАНЫ ТӨЗЕТТЕРҮГӘ ИРЕШӘ, ӘММА ЧЫГЫМНАР АНЫҢ ФИНАНС ӨМЕТЛӘРЕН АКЛАМЫЙ – ПАССАЖНЫ КАРАП ТОТУ АРТЫК КЫЙММӘТКӘ ТӨШӘ.

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

Казанның нәкъ үзәгендә, Габдулла Тукай урамында кызыл кирпечтән өч катлы бина бар. Монда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе – югары мөселман белем бирү учреждениесе урнашкан. Үзенең исеме белән мәдрәсә икенче гильдия сәүдәгәре, милли аяк һәм баш киемнәре фабрикасы хуҗасы, җәмәгать эшлеклесе һәм меценат Мөхәммәтҗан Галиевкә бурычлы.

«МӨХӘММӘДИЯ»НЕҢ ЯҢА КОМПЛЕКСЫНДА, АШ БҮЛМӘСЕ ҺӘМ АШХАНӘДӘН ТЫШ, ЛАЗАРЕТ, АЯК КИЕМНӘРЕ РЕМОНТЛАУ ҺӘМ КИТАП ТЫШЛАУ ОСТАХАНӘЛӘРЕ ДӘ УРЫН АЛА. МӘДРӘСӘНЕҢ ҮЗ БАКЧАСЫ ДА БУЛА, КЫШЫН ШӘКЕРТЛӘР АНДА ТИМЕРАЯКТА ШУАРГА ЯРАТА. УКУ ЙОРТЫНДА ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРГӘ ДӘ, ЗАМАНЧА ЧАРАЛАРГА ДА УРЫН ТАБЫЛА.

Асылда сәүдәгәр мәдрәсәне үзенең улы өчен салдыра – алдынгы карашлы егет икенче мулла вазыйфасын башкару хокукына ия була. Озак та үтми, яшь егет атаклы дин эшлеклесе һәм мәгърифәтче булып үсеп җитә, ә ул җитәкләгән мәдрәсә Россиядә иң зур уку йортларының берсе санала.

Бу тарихка 1882 елда нигез салына. Башта Галиев 8 гә 16 метр мәйданлы зур булмаган таш бина төзетә – беренче сабакларны Галимҗан Баруди шул бинада уздыра башлый. Әгәр беренче вакытларда «Мөхәммәдия» үзе кебек дини белем йортларыннан әллә ни аерылмаса, инде берничә елдан ук ул мәгариф һәм мәдәният үзәгенә әверелә. Баруди укыту программасына дөньяви фәннәрне дә кертүгә ирешә: шәкертләр математика, география, табигать белеме, физика, тарих дәресләрен дә үзләштерә башлый. Мәдрәсәдә газеталар чыга, 1906 елда исә профессиональ театр оеша!

Мәдрәсәнең даны чит илләргә кадәр тарала. Укырга теләк белдерүче шәкертләрнең саны шулкадәр арта ки, «Мөхәммәдия» бинасы барлык теләүчеләрне дә сыйдыра алмый. Уку йортын киңәйтәләр, әмма бу да әллә ни ярдәм итми. 1901 елда атаклы мәдрәсәгә яңа бина төзү турында карар кабул ителә.

Галимҗанның җәмәгате Бибимаһруй Үтәмешева һәр эштә дә иренең ярдәмчесе була, һәм мәдрәсәнең бинасын зурайтып салырга бай фабрикантлар, меценат Үтәмешевләр гаиләсе зур ярдәм күрсәтә. Яңа бинаның нигезенә беренче таш салу тантанасына мәгърифәтче, илдәге абруйлы дин әһелләреннән берсе, халыкта «татарларның рухи короле» дигән даны таралган Зәйнулла Рәсүлевны чакыралар.

36 ел дәвамында мәдрәсәдә меңнән артык шәкерт белем ала. Галиәсгар Камал, Нәкый Исәнбәт, Хөсәен Ямашев, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Фатих Әмирхан – алар барысы да «Мөхәммәдия» тәмамлаган.

Хакимияткә советлар килгәч, Галиев төзегән бина яңа дәүләт карамагына тапшырыла, мәдрәсә эшен туктата. Әмма «Мөхәммәдия»нең язмышы сөенечле була: 1993 елда мәдрәсәнең икенче гомере башлана, хәйрияче Мөхәммәтҗанның исеме яңадан яңгырый башлый.

ШАМОВ ХАСТАХАНӘСЕ

Казанлылардан Шамов хастаханәсенә юл күрсәтүләрен үтенсәгез, сезгә бик теләп җавап бирерләр. Гәрчә биредә инде күптән хастаханә түгел, биш йолдызлы затлы кунакханә урнашкан булса да – чөнки архитектура үзенчәлекләре андый мөмкинлек тә бирә...

1910 елның 25 апреле. Клиника ачылу тантанасына башкаланың зыялылары җыела. Казанның Осокин эрәмәсендәге Өченче тауда урнашкан хастаханә ачылышына губернатор

үзе, шәһәр башлыгы, Казан хәрби округы башлыгы һәм күпсанлы дәрәҗәле кунаклар килә... Кызганыч, тантананы вакыйганың төп сәбәпчесе – атаклы меценат, миллионнар белән эш иткән беренче гильдия икмәк сәүдәгәре һәм Казанның иске йолалык общинасы башлыгы Яков Филиппович Шамовка гына күрергә насыйп булмый. Сәүдәгәр 1908 елда, клиника төзелешенә 100 меңнән артык акча бүлеп бирергә карар кылган елны үлеп китә. Иренең игелекле эшен җәмәгате Агриппина Хрисанфовна ахырына җиткерә, ул Шамов хастаханәсе төзелешенә ярты миллион сум акча тота.

Проектның авторы, Казан архитекторы Константин Олешкевич Шамовның исемен өч катлы бинада мәңгеләштерә – бина «Ш» хәрефе рәвешендә төзелгән. Хастаханәнең проектын бик төгәл башкаралар, үз вакыты өчен ул алдынгылардан санала.

Шамовларның идарәчесе Иван Строкин төзелеш урынына һәр шимбә саен килеп йөри, эш барышын тикшерә, төзүчеләр белән алышбиреш итә – шуңа да эш җитез бара, намус белән башкаралар. Әлбәттә, тагын бер сәбәбе дә була – гади эшчеләр хастаханәне үзләре өчен сала бит, чөнки ул шәһәр халкына һәм Казан өязе крестьяннарына хезмәт итәргә тиеш була. Шамов шулай кушып калдыра.

Сәүдәгәрнең гади халыкны кайгыртырга алынуының сәбәбен соңрак бер риваятькә бәйләп аңлатачаклар, безнең көннәргә ул Александр Репин атлы кеше аша килеп җитә. Имеш, аның сүзләренә ышансак, рус-япон сугышы вакытында ашлык сәүдәгәре Шамов Россия армиясен он белән тәэмин иткән. Онның бер партиясе бозылган булып чыга, солдатларның сәламәтлегенә зыян сала. Шамовка төрмә яный, әмма ул, тәҗрибәле сәүдәгәр буларак, хакимияттәгеләр белән килешүгә ирешә. «Тимер рәшәткә артында казна икмәге ашап ятуымнан ни мәгънә булыр икән? – ди ул. – Әллә соң шәһәр өчен хастаханә төзеттеримме, ничек уйлыйсыз, файдалырак булмасмы?»

ШАМОВ ХАСТАХАНӘСЕ ШУЛКАДӘР МУЛДАН ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛГАН, ТӘЭМИН ИТЕЛГӘН БУЛГАН КИ, ИМЕШ, УРЫН-ҖИР ЗАПАСЫ 1990 НЧЫ ЕЛЛАРГА КАДӘР ҖИТКӘН! ИҢ МӨҺИМЕ, ХАСТАХАНӘ АЧЫЛГАН БЕРЕНЧЕ КӨННӘРДӘН ҮК БИРЕДӘ БАРЛЫК МӨҺИМ БҮЛЕКЛӘР ДӘ ДИЯРЛЕК ЭШЛИ: ТЕРАПИЯ, ХИРУРГИЯ, КҮЗ АВЫРУЛАРЫ, ГИНЕКОЛОГИЯ БҮЛЕКЛӘРЕ... КЛИНИКАНЫҢ ИНФРАСТРУКТУРАСЫ ТАҢ КАЛДЫРА – ЛАБОРАТОРИЯДӘН БАШЛАП, АПТЕКА ҺӘМ КЕР ЮУ ЙОРТЫНА КАДӘР БУЛГАН АНДА.

Ничек кенә булмасын, Шамов хастаханәсе бинасы – Яков Филипповичның безнең көннәргәчә килеп җиткән хәйрия үрнәге. Бина сәүдәгәрнең исемен Казан тарихына күп гасырларга кертеп калдыра, юмарт меценатка үзенчәлекле һәйкәл сыман ул. Шамов үлгәч тә, аның васыятьнамәсендә күрсәтелгәнчә, мирасның зур гына өлеше хәйриягә тотыла. Үзенең тугры хезмәтчеләрен дә, туганнары һәм якыннарын да игътибарсыз калдырмый ул.

PRESSA

ЧЫН ЧИСТАЙЧА

Фото: Александр Ефремов, Ната Смирнова

Чистай халкы үзләренең кечкенә өяз шәһәрендәге хәйриячелек иске йолалык сәүдәгәрләреннән башланган, дип саный. Челышевлар, Шашиннар, Маланьичевлар, Вачуговлар, Маклаковлар, Мешкичевлар, Поляковлар, Мельниковлар... – бу фамилияләр Чистайда һәркемгә таныш. Алар меценат сәүдәгәр династияләре җирләнгән Татарстандагы бердәнбер Иске йолалык зиратындагы кабер ташларына уеп язылган. Хәйриячеләрнең игелекле эшләре исә чистайлылар хәтеренә мәңгегә уелган – сәүдәгәрләрдән бүләккә калган күчемсез милек әле бүген дә Чулман буендагы каланың үсешенә армый-талмый хезмәт итә һәм, әлбәттә инде, аны бизәп тора, вакыт-вакыт исә Чистай хуҗаларын һәм кунакларын әлеге сөйкемле урынның данлы үткәннәренә алып кайта.

ЭКСКУРСИЯЧЕ – БАШЛЫК ҮЗЕ

Чистайдагы хәйриячелеккә багышланган экскурсияне «Татарстан» журналына район башлыгы Дмитрий Иванов үзе үткәрде. Үзенең туган шәһәренең тарихын ул биш бармагыдай белә. Һәр архитектура ядкәре хакында җентекләп һәм мавыктыргыч итеп сөйли ала, биредәге һәр йорт турында әллә никадәр чын вакыйга һәм әллә ничә төрле риваять сакланган бит.

– Әмма теге яки бу йорт турында һаман саен нинди дә булса яңалык белеп алам – экскурсиячеләрдәнме, шәһәр халкыннанмы яисә кайчагында килгән кунаклар шундый катлаулы сорау бирә ки, аңа җавап эзләп шактый тырышырга туры килә, – ди Дмитрий Алексеевич.

Аңлавыгызча, без журналистларның сораулары да шактый күп иде. Әмма район башлыгы аларның һәркайсына җавап тапты.

1 Чистайдагы хәйриячелеккә багышланган экскурсияне «Татарстан» журналына район башлыгы Дмитрий Иванов үзе үткәрде.



2
Меценатлар арасында бигрәк тә миллионер-сәүдәгәр Василий Львович Челышев аерылып торган. Аны 1872 елда шәһәр башлыгы булырга күндергәннәр.

3
Сәүдәгәр Челышев йорты – ул чакта Чистайдагы иң зур һәм иң бай бина. XIX гасыр уртасында салынган. Сугыш вакытында биредә госпиталь урнашкан, хәзер исә бина – күп профильле көллиятнеке.

СӘҮДӘГӘР ЧЕЛЫШЕВНЫҢ ЧИСТАЙДАГЫ ЭЗЕ:

– МАРИЯ КЫЗЛАР ПРИЮТЫНА ЯРДӘМ (ҺӘР ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕГӘ БИРНӘГӘ 500 СУМ);

– ЧИСТАЙ ХАТЫН-КЫЗЛАР УЧИЛИЩЕСЫ ӨЧЕН ИКЕ БИНА;

– ШӘҺӘР ХАСТАХАНӘСЕНЕҢ ТӨП КОРПУСЫ;

– ӨЛКӘН ЯШЬТӘГЕ СУКБАЙЛАР ӨЧЕН ИСКЕ ЙОЛАЛЫК КАРТЛАР ЙОРТЫ;

– «ҖӘБЕРЛӘНГӘННӘР, ГИДАЙЛАР, ЗИМАГУРЛАР, ЯНГЫННАН ЗЫЯН КҮРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ТАЛАНУЧЫЛАР» ӨЧЕН «ПАТША-ИМПЕРАТОР АЛЕКСАНДР III ИСТӘЛЕГЕНӘ ТӨНГЕ КУНУ ЙОРТЫ»;

– ЗЕМСТВО ИДАРӘСЕ БИНАСЫ;

– ЯРЛЫ ХАЛЫК БУШЛАЙ ФАЙДАЛАНУ МӘҖБҮРИ ШАРТЫ БЕЛӘН ШӘҺӘР СУҮТКӘРГЕЧЕН ТӨЗҮ ҺӘМ КАРАП ТОТУ;

– «ФӘКЫЙРЬ МАЛАЙЛАР ӨЧЕН СЫЕНУ УРЫНЫ» ПРИЮТЫ.

СӘҮДӘГӘРЛӘР МИРАСЫ

– Чистай – бик бай тарихлы шәһәр, бездә зиннәтле биналар, архитектура ядкәрләре күп, – дип башлый экскурсияне Дмитрий Алексеевич. – Алар барысы да безгә сәүдәгәрләрдән мирас булып калган. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында Казан губернасындагы икмәк сәүдәсе тулысынча диярлек алар кулында булган. Революциягә кадәр Чистайның атаклы сәүдәгәрләре туган шәһәрләрен үстерүгә зур акчалар тоткан, меценатлар арасында бигрәк тә Василий Челышев аерылып торган. Аны 1872 елда шәһәр башлыгы булырга күндергәннәр, шунлыктан бу шәхеснең тормышы белән танышу миңа аеруча кызыклы.

ЧЕЛЫШЕВ

Василий Львович – 1 нче гильдия сәүдәгәре, күпсанлы дәүләт бүләкләре иясе, данлыклы хәйрияче, Чистайның мактаулы гражданы. Менә бу аның йорты – ул чакта Чистайдагы иң зур һәм иң бай бина. XIX гасыр уртасында салынган. Өске катлары соңрак өстәп төзелгән, әмма йорт алардан башка да бик зур булган. Сугыш вакытында биредә госпиталь урнашкан, хәзер исә бина – күп профильле көллиятнеке.

Василий Львович шәһәрдәге иң хөрмәтле хәйрияче булган. Сәүдәгәр Челышев акчалары нигездә мәгариф, сәламәтлек



саклау тармакларына ярдәмгә һәм ярлы халыкның тормышын яхшырту максатларында тотылган. Әйтик, балалар приютларын карап тотуга (ул ятим балаларның Казан попечительләр советы рәисе була); Чистайдагы Мария кызлар приютына ярдәмгә (биредә тәрбияләнүче һәр кызга аннан чыгып киткәндә 500 сум акча бирелгән); Чистай хатын-кызлар училищесы өчен ике бина сатып алуга; шәһәр хастаханәсен төзүгә; өлкән яшьтәге сукбайлар өчен иске йолалык картлар йортын төзүгә. Аның актив катнашында «җәберләнгәннәр, гидайлар, зимагурлар, янгыннан зыян күрүчеләр һәм таланучылар» өчен «Патша-император Александр III истәлегенә төнге куну йорты» салынган. Аларны биредә иртән һәм кичен бушлай ашатканнар, шимбә көнне мунча керткәннәр. Биредә елына 10 меңләп кеше кабул ителгән. Челышев шәһәргә Земство идарәсе бинасын да бүләк иткән.

Шәһәрдә беренче суүткәргечне Чистай халкы атаклы якташларының төп казанышларыннан берсе дип саный – аны төзү һәм карап тотуга акчаны Василий Львовичның хатыны Екатерина Васильевна Челышева бирә, аның шарты буенча ярлы халык суүткәргечтән бушлай файдаланырга тиеш була. Моның өчен сәүдәгәр хатынына император Николай II рәхмәт белдерә. 1904 елда исә Екатерина Челышева акчасына 25 урынлык «Фәкыйрь малайлар өчен сыену урыны» приюты төзелә.

ШӘҺӘР БИЗӘКЛӘРЕ

Чистайның 2 нче гильдия сәүдәгәрләре Григорий Андреевич һәм Дмитрий Андреевич Поляковлар акчасына төзелгән Никола соборы – шәһәрдәге иң борынгы биналарның берсе һәм аның бизәге. Гыйбадәтханә 1838 елда танылган Казан архитекторы Петр Пятницкий проекты буенча салынган, 1842 елда архитектор Фома Петонди планы буенча коймасы һәм капкасы төзелгән. 1875–1877 елларда чиркәүнең эче инде башка сәүдәгәр – Иван Леонтьевич Мешкичев акчасына төзекләндерелгән.

Сәүдәгәрләр – бертуган Чукашевлар һәм Ефим Павлович Шашин биргән акчага ирләр рухани училищесы бинасы төзелгән, анда XIX гасыр башында рухани балаларын чиркәү хезмәтенә әзерләгәннәр.

Чистайның иң матур бинасында – сәүдәгәр Мельников йортында бушлай карау өчен картиналар галереясы урнашкан булган.

4 Миллионнарны – суга! Суүткәргеч төзүгә акча биргән өчен Екатерина Васильевна Челышевага император Николай II рәхмәт белдергән.

5 Чистайның иң матур бинасында – сәүдәгәр Мельников йортында бушлай карау өчен картиналар галереясы урнашкан була.

ИСКЕ ЙОЛАЛЫК СӘҮДӘГӘРЛӘРЕНЕҢ НАМУС КОДЕКСЫ

РОССИЯДӘ СӘҮДӘГӘРЛӘРНЕҢ 64% ИСКЕ ЙОЛАЛЫК ТАРАФДАРЛАРЫ ГАИЛӘСЕННӘН ЧЫККАН. ИКЪТИСАДТА АЛАРНЫҢ АБРУЕ БИК ЮГАРЫ БУЛГАН, АЛАРНЫҢ ЭШ ЭТИКАСЫ ИСӘ 1912 ЕЛДА «РОССИЯДӘ ЭШ АЛЫП БАРУНЫҢ ҖИДЕ ПРИНЦИБЫ» ДОКУМЕНТЫ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН.

1. ХАКИМИЯТНЕ ХӨРМӘТ ИТ;
2. НАМУСЛЫ ҺӘМ ГАДЕЛ БУЛ;
3. ХОСУСЫЙ МИЛЕККӘ ХОКУКНЫ ХӨРМӘТ ИТ;
4. КЕШЕНЕ ЯРАТ ҺӘМ ХӨРМӘТ ИТ;
5. ҮЗ СҮЗЕҢДӘ ТОР;
6. АКЧАҢА КАРАП ЯШӘ;
7. МАКСАТЧАН БУЛ.



6



7

8

6

Скарятин бакчасы. Агачларның кайберләренә йөз елдан артык!

7

Замана хәйриячеләре буләге – «Умиление» Изге Ана иконасы чиркәве. Гыйбадәтханә диварларын «Палехский образ» остаханәсе икона ясаучылар бригадасы бизәгән.

8

«Камалия» балалар ял итү-үсеш үзәге. Укытуның төп принцибы, моннан 200 ел элеккеге кебек үк, – «гөнаһлардан тыелырга һәм игелек кылырга» өйрәтү.

«КАМАЛИЯ»

Татар сәүдәгәрләре дә бик теләп һәм ихлас күңелдән хәйриячелек белән шөгыльләнгән. Хәзер балаларның ял итү-үсеш үзәге урнашкан «Камалия» мәдрәсәсе дә сәүдәгәрләр заманыннан калган. Кызганычка, әлеге мәдрәсәне төзеткән Мөхәммәдзакир Камалның бер генә фотосурәте дә сакланмаган. Без аның кыяфәтен күз алдына китерә алмасак та, игелекле эшләреннән хәбәрдар. Ул Казан губернасындагы иң борынгы «Нур» мәчете суфые булган. Казандагы «Мәрҗани» мәчете кебек үк, ул да үз эшен бер дә туктатмаган. Гыйлемле, уй-фикерле Мөхәммәдзакир «Камалия» мәдрәсәсен үз акчасына салдырткан һәм карап торткан: андагы шәкертләрне киендергән, укыткан, ашаткан һәм 1847 елдан үзе шунда белем биргән. Укыту методикасы әледән-әле көчле тәнкыйть утына тотылса да (чөнки биредә нибары өч телдә – гарәп, фарсы һәм татар телендә укытканнар), бу мәдрәсәдән танылган җәмәгать эшлеклеләре һәм мәгърифәтчеләр чыккан: Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Кәрими, Галиәскәр Гафуров-Чыгатай, Харис Фәйзи-Чистапули, татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый, революционер, журналист һәм педагог Фәрит Туктаров... Мөхәммәдзакир хезмәтләрен өйрәнгән саен, Чистай аның гомеренең яңа сәхифәләре белән таныша. Аның 18 баласы булуын, көрәшче булуын беләбез... Ә күптән түгел аның хезмәтләреннән берсе Сүриядә табылды – остазларга тәгаенләнгән әлеге китапны ТР мөселманнарының Диния нәзарәте ярдәмендә нәшер иттек...

ГАДӘТЛӘРГӘ ТУГРЫ БЕЗ...

Чистай сәүдәгәрләренең эшкуарлыгы һәрвакыт социаль юнәлештә булган, бу аларның юмарт хәйриячелегеннән күренеп тора. Әйе, алар барысы да бай, затлы, намуслы булган, һәм бервакытта да мохтаҗларны, бәла-казага тарганнарны ярдәмсез калдырмаган. Узган гасырлардан калган күркәм гадәт – булышу. Һәм без дә аңа тугры булырга тиеш.

Якташыбыз Гомәр Исмәгыйль улы Усмановның әти-әнисе яшәгән йорт урынындагы җир кишәрлеген шәһәребезгә бүләк итүен хәтердән чыгармыйбыз. Соңрак анда сәнгать мәктәбе төзелде.

«Камалия» балалар үзәген торгызуга илһамландыручы һәм андагы эшләрнең иганәчесе – тагын бер якташыбыз Марат Шакирҗан улы Хөснуллин. Хәзер балаларны «Камалия»дән алып китеп булмый. Аларны роботлар җыярга да, балта эшләренә дә, сәхнәдә чыгыш ясарга да, ашарга әзерләргә дә, этикет кагыйдәләренә дә өйрәтәләр – биредә үсмерләргә әллә никадәр осталык һәм күнекмә сеңдерелә. Әмма иң мөһиме – моннан 200 ел элеккеге кебек үк, балаларны биредә «гөнаһлардан тыелырга һәм игелек кылырга» өйрәтәләр. Бу – ислам тәгълиматына нигезләнгән укытуның төп принцибы.

9

10

ПАРК ҺӘМ СКВЕРЛАР: ЧИСТАЙ ҮРНӘГЕНДӘ

Бөтен яңа нәрсә – онытылган иске улдыр. Ә бездә әле бөтенләй онытылмаган да. 1868 елда Казан губернаторы Николай Яковлевич Скарятинның бирегә килүен Чистай яхшы хәтерли. Ул Икмәк мәйданының нинди коточкыч хәлдә булуын күреп бик хафалана. Анда борын заманнардан бирле ашлык, тары, икмәк белән сәүдә иткәннәр. Арбалар, атлар, бихисап халык, пычраклык... Губернатор Чистай сәүдәгәрләренә бу урында җәмәгать бакчасы төзергә тәкъдим итә. Ярты ел эчендә сәүдәгәрләр 3000 көмеш акча туплый. Николай Яковлевич Казаннан үзенең архитекторы белән бакчачысын җибәрә. Беренчесе план төзи, икенчесе мәйданга Петербургтагы кебек агачлар утырта. Бу агачларга хәзер йөз елдан артык! Һәм бакча чистайларның яраткан ял итү урынына әйләнә. 1872 елда аны Скарятин исеме белән атарга карар кылалар. Әлбәттә, яшәү дәверендә ул исемен әллә ничә тапкыр үзгәртә: Карл Маркс исемен дә йөртеп ала, җәмәгать бакчасы да була... Әмма 2000 нче еллар башында кабат Скарятин бакчасы исеме кайтарыла.

Берара Чистай районыннан ТР Дәүләт Советында депутат булып торган Виктор Смыков инициативасы белән 2010 елда парк реконструкцияләнә, гашыйклар өчен чатырлар, матур эскәмияләр пәйда була... Республикадагы «Парклар һәм скверлар» программасы турында ишеткәнегез бардыр, мөгаен? Менә әлеге программа нәкъ биредән башланган. Президент Рөстәм Миңнеханов, Скарятин бакчасын күргәч, әлеге идеяне бик ошаткан һәм парк-скверларны төзекләндерүне республика программасы итәргә карар кылган. Моннан ике ел элек бакчабызда фонтан пәйда булды – Виктор Смыковның тагын бер бүләге. Фонтанны мәктәптә чыгарылыш кичәсе булган көнне ачтык. Бирегә бөтен шәһәр халкы җыелды. Скарятин бакчасында сугышчан дан почмагы да бар – анда атаклы «Катюша» тора. Нәкъ менә «Катюша» җыры өчен шагыйрь Михаил Исаковскийга Чистайда премия бирелгән бит. Һәм ул бөтен премиясен фашистларга каршы көрәшкә биргән. Чистайда халыкка хәйриячелек әнә шулай йога ул. Һәм яңа казанышларга рухландыра.

ИГЕЛЕК ЭШЛӘҮ РӘХӘТ УЛ

Шунлыктан бүген дә ярдәм итү гадәте саклана. Замана хәйриячеләре шәһәр өчен әһәмиятле объектларны төзүдә һәм төзекләндерүдә булыша: «Чистай» мәдәният үзәге, «Лидер» спорт комплексы, «Татнефть-Олимп» стадионы, «Чулман» яр буе. 2013 елда әлеге дә баягы Виктор Смыков инициативасы һәм финанс ярдәме белән «Умиление» Изге Ана иконасы чиркәве салынды. Гыйбадәтханә диварларын «Палехский образ» остаханәсе икона ясаучылар бригадасы бизәде. Чиркәүне «Ямашнефть» НГТИ исемендәге сквер әйләндереп алган – ял итү һәм сәйран кылу өчен менә дигән урын бу.

Ә борынгы сәүдәгәрләрнең дәвамчысы булган Чистай эшкуарлары акчасына Энгельс урамының җәяүлеләр йөри торган өлеше төзекләндерелде: иске катлам куптарылып, яңа таш түшәлде, бордюрлар яңартылды, фонарь һәм эскәмияләр куелды. Чистайның мактаулы гражданы, «Бетар» ҖЧҖ җитештерү фирмасы җитәкчесе Владимир Иванович Зайцев әлеге проектка зур ярдәм күрсәтте. Аның булышлыгы белән «Молодежный» скверында матур фонтан һәм арыслан сыннары пәйда булды. Аның инициативасы белән шунда ук сәгать заводының Бөек Ватан сугышы елларындагы эшчәнлегенә багышланган истәлек стенды куелды. Чистай дәүләт музей-тыюлыгының Музей-күргәзмәләр комплексында исә «Восток» Чистай сәгать заводына багышланган күргәзмә оештырылды. Владимир Иванович районда спортны үстерүгә булыша, чиркәү һәм мәчетләрне торгызуда катнаша, балалар йортына, авыру балаларга ярдәм күрсәтә... Игелек эшләү – рәхәт ул. Бу нәкъ менә чын чистайча.

9

Ярдәм итү гадәте шәһәрдә бүген дә саклана. «Чулман» яр буе – калага замана меценатларыннан бүләк.

10

Хәйриячеләрнең исемнәре меценат сәүдәгәр династияләре җирләнгән Татарстандагы бердәнбер Иске йолалык зиратындагы кабер ташларына уеп язылган.

КАТЛАУЛЫ ШАРТЛАРДА ШАХ ҺӘМ МАТ

Автор:
Ольга Туманская

– Көндәшеңне кызганмадың син – пешкасын ашадың!
Көләргә яратучан малай шахмат тактасына төбәлгән. Бүген ул «аклар» белән уйный. Каршында – нәфис хатын-кыз.
– Егет икәнсең, булдырасың! – дип, чын күңелдән сөенә ул үзенең отылуына. «Шахмат йөрәкләрне берләштерә» хәйрия проектының авторы һәм илһамчысы Татьяна Ширяева фигуралар хәрәкәтенә ниндидер бер яшерен мәгънә салынган булуга ихластан ышана. Проектта катнашучылар, бөтен күңелләрен биреп, кыен хәлдә калган һәр балага әлеге уенга ачкыч табуда ярдәм итәргә әзер.

Фото: Александр Ефремов

АППЕТИТ УЙНАГАНДА АЧЫЛА

Беренче карашка бу бер дә ниндидер махсус, ябык урынга охшамаган. Бүлмәдә – тып-тын. Малайлар һәркайсы үз ноутбугының мониторына төбәлгән. Юк, экранда Minecraft та, хәтта «Танклар» да түгел – ә шахмат уены!

Н. Галләмов исемендәге махсус мәктәптә девиант тәртипле 36 бала укый. Һәм алардан егермесе әлеге интеллектуаль уенда шактый уңышка ирешкән, еш кына турнирларда көндәшләрен тиз арада «егып сала»!

Мәсәлән, күптән түгел Россия һәм БДБ илләре махсус укыту-тәрбия бирү учреждениеләре арасында үткәрелгән Киберспорт буенча халыкара ярышларда аларның командасы беренче урынны алган, шахмат турнир таблицасының бөтен призлы урыннарын диярлек алар яулаган. Бер бала исә көндәшенең бөтен фигураларын «ашаган», ә үзенекеләрнең берсен дә югалтмаган.

АК КОРОЛЕВА

– Чынлыкта, шахмат – очрашу өчен сәбәп кенә ул, – ди Татьяна Ширяева. Күз алдына китерегез әле: бер мәлне кыен хәлгә юлыккан балалар кинәт дустанә фикердәшләр мохитенә килеп эләгә – менә шунысы мөһим!

Проектның «Шахмат йөрәкләрне берләштерә» дип аталуы аңлашыла да. Синергия законы буенча, битараф булмаган берничә кешенең кайгыртуы инвалид балаларга да, әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калучыларга һәм, әлбәттә инде, тәртипсез яшүсмерләргә дә җитә.

– Кайвакыт аларга тәртипне үзгәртү моделен тәкъдим итү дә җитә, әмма ул модель кызыктыргыч булырга тиеш! – ди Татьяна. – Юкка гына әлеге борынгы хикмәтле уенга аксөяк даирәләрдә зур әһәмият бирмәгәннәр бит, чөнки бу – сайлап алынганнарга гына аңлаешлы ниндидер символик тел. Фигураны күчергәндә, үткән буыннар үз мәгънәсен кодлаштырып калдырган меңьеллык акыл һәм иҗат тәҗрибәсенә таянып, син шул телдә сөйләшәсең, ә һәр яңа буын исә үзе өчен һаман яңа мөмкинлекләр ача.

ШАХМАТНЫҢ ПСИХИКАНЫ ДӘВАЛАУ ЭФФЕКТЫ

Күпсанлы тикшеренүләрдән күренгәнчә, шахмат кешенең психикасын дәвалау үзлегенә ия. Әлеге уен баш миенең ике ярымшарын да гармониягә китерә һәм акыл сәләтен генә түгел, иҗатны да үстерә. Ул берничә адымга алданрак уйлау осталыгына, күп вариантлылыкка һәм үз партиясендә генә түгел, үз тормышында да әллә никадәр вариант табарга өйрәтә. Һәм моны Татьяна үз мисалында бик яхшы белә.

...Кайчандыр, моннан күп еллар элек, ул пионер лагеренда шахмат буенча чемпион була. Аннары шахмат мәктәбенә улын алып килә. Аның уңышларына һәм җиңүләренә сөенә. Улының гадел акыл көрәшендә яуланган кубок, медаль, бүләкләрен күргәч, бәхеткә чума. Әмма нигәдер һәрвакыт бер фикер тынгы бирми: менә бу мизгелдә мондый җиңү тәмен беркайчан да татымаячак балалар да бар бит, чөнки шахмат һәм аларның тормышы – ике параллель чынбарлык, һәм аларның кайчан да булса бер кисешәсе икеле...

Аннары исә ул чирләп китә һәм, үзенең физик авыртуыңны басуның иң яхшы юлы –

Татьяна Ширяева, «Шахмат йөрәкләрне берләштерә» хәйрия проектының авторы һәм илһамчысы.



Артур – спортчы егет. Иртәгә ул хоккей турнирында катнаша! Бу бик хәрәкәтчән малай җаны-тәне белән бирелеп шахматка мөкиббән китәр дип уйламассың да. «Миңа исә бик ошады! – дип көлә ул. – Шахмат буенча разрядны бик тә аласым килә».

башкаларга җан авыртуын басуга ярдәм итү, дигән карарга килә. Һәм кайчандыр тынгы бирмәгән теге фикер асыл мәгънәгә төренә башлый. Шул рәвешле кыен хәлдә калган балаларны шахмат уйнарга өйрәтү буенча хәйрия проекты идеясе пәйда була.

– Мин моны рациональ аңлата алмыйм, – ди Татьяна. – Нindидер бер мәлдә син үзеңнән авыррак хәлдә булучыларга ярдәм итәргә тиешлегеңне аңлыйсың. Һәм моңа көч табыла!

Татьянаның идеясе ТР Профессиональ тренерлар ассоциациясенә дә ошый, беренче булып аны Ассоциация рәисе, шахмат буенча спорт мастеры Иван Герасимов хуплый. Тәүге хәйрия дәресләрен алар Казандагы «Гаврош» социаль приютында үткәрә башлый.

– Кызыктыру, җәлеп итү, баланың «эчке дулкынын» тотып алу – мин боларның барысын да эшли алам булып чыкты! – дип елмая Татьяна. – Мин мактыйм, сокланам, хуплыйм, кирәк икән – һәркайсы белән бергә кайгырам, хаталарын аңлатам... Ә безнең тренерларыбыз? Алар арасында хәтта гроссмейстерлар да бар. Әмма аларның һәрберсенең иң мөһим сыйфаты – әлбәттә инде, ихлас йөрәге. Бәлки, шуңа күрә безнең эшебез уңгандыр, нәтиҗәләребез сөендерерлектер дә!

Баштарак балалар белән мастер-классларда әллә нигә бер тапкыр гына шөгыльләнсәләр, хәзер инде проект эшчәнлеген чын, даими белем бирү процессына тиңләп була. 2019 елда «Шахмат мәгарифе: шахмат йөрәкләрне берләштерә» проектын «Президент грантлары фонды» һәм ТР Министрлар Кабинеты хуплый. Аңа башка тренерлар да кушыла, һәм барысы бергә алар Казандагы «Дуслык» һәм Яшел Үзәндәге «Гнездышко» приютларындагы балаларны, Лаеш, Чистай, Алабуга, Казанның Идел буе районы балалар йортларында тәрбияләнүчеләрне, Галләмов исемендәге девиант тәртипле балалар өчен махсус мәктәп укучыларын һәм Раифадагы махсус училище студентларын шахмат белән мавыктыра ала.

ШӘХСИ СЦЕНАРИЙНЫ «ЯҢАДАН ЯЗУ»

– Безнең методика уникаль, – дип сөйли Татьяна. – Дәресләрдә тренер балаларны йөрешләргә һәм тактик алымнарга гына өйрәтми бит. Иң мөһиме – ул аларга бөек шахматчылар тормышыннан төрле вакыйгаларны сөйли. Әлеге атаклы кешеләрнең тормыш сынауларын ничек җиңүе, кыен хәлләрдән ничек чыгуы, бернигә дә карамыйча ничек алга баруы хакында. Минем иманым камил: мондый уңай мисаллар белән таныш балалар кирәкле мизгелдә үзләренең шәхси сценарийларын да «яңадан яза» алачак.

АТ БЕЛӘН ЙӨРҮ

Сергей Шарин – дзюдо буенча спорт мастеры, әмма ул, Татьяна Ширяева һәм Иван Герасимов Галләмов исемендәге махсус мәктәпкә дә әлеге шахмат проектында катнашырга тәкъдим иткәч, аны кайнар хуплаган. Әлеге идея аның йөрәгенә дә үтеп кергән. Һәм шулкадәр тирән кергән ки, хәтта мәктәптә тәрбия эше өчен җаваплы Сергей Александрович шахмат уйнарга өйрәнү өчен кирәкле ноутбукларны үз өеннән китереп куйган.

– Дәресләр атнага өч тапкыр үткәрелә. Әмма бу рәсми рәвештәгесе генә – калган көннәрдә малайлар мине кичке аштан соң ничек тә бирегә китерү әмәлен эзли, – дип көлә Шарин. – Тренерлары кушкан шахмат биремнәрен алар инде бер атна эчендә үк үтәп өлгерә!

Гадәттә, ябык мәктәп, интернат һәм балалар йортларында шашка белән мавыгалар – анысы җиңелрәк бит, дип сөйли Сергей Александрович. Әмма биредә шахматка бәйле тарих 2017 елдан ук башлана. Ул елны мәктәпкә елгыр шахмат һәм блиц буенча дөнья чемпионы, 12 яшендә дөньяда иң яшь гроссмейстер булган Сергей Карякин килә! Бу кабинеттагы теләсә кайсы шахмат тактасын әйләндереп карасагыз, сез аның автографын күрәчәксез.

Беренче елны Галләмов мәктәбендә шахмат уйнарга нибары биш малай гына теләк

белдерә. Әмма әлеге акыл спорты пионерлары ярышларга бара һәм, призлы урыннар ала башлагач, шахмат белән кызыксынучылар саны күп тапкырга арта. Сүз уңаенда, әлеге процесска пандемия дә үз өлешен кертә һәм... уңай яктан. Тренерлар белән дистанцион (компьютерлы, дип укы) шөгыльләнү форматы балалар күңеленә хуш килә.

Эш кыза! Һәм менә инде алар игътибар белән мониторларына төбәлгән. Электрон пешкаларны күчереп яки ат белән атлап, алар йөрешләрне исәпли. Итальян һәм Лондон партияләрен уйный, Сицилия яклавын кора. Ә көндәшләре кем соң? Ихтимал, күрше шәһәрдән шундый ук малайдыр. Әллә... ерак илдән берәр гроссмейстермы икән? Кемгә ничек туры килә инде!

Хәер, алар «классикада», чын тактада да уйный белә. Балалар шахмат буенча ачык турнирларда еш була, яшьтәшләре белән очраша, игътибарны туплау һәм үздисциплина могҗизаларын күрсәтә. Аларны хәзер хулиганлыкка урын булмаган, әмма җиңүгә омтылыш һәм үз казанышларың белән сөенү тулы бөтенләй башка тормыш көтә бит.

ӨЧЛЕСЕЗ ЕЛ

– Бер ел шөгыльләнгәннән соң ук, безне сөендерерлек хәлләр булды: балаларның тәртибе, укуы яхшырды, күбесе хәтта уку елын өчлеләрсез тәгәлләде, – дип сөйли Сергей Шарин. – Малайлар үзгәрә, үсә, уйлана... Бер сүз белән әйткәндә, реабилитация үтә. Әлбәттә, вакыт җиткәч, алар өйләренә, әти-әниләре янына, үзләренең гадәти мәктәпләренә кайтыр. Һәм бирédә без биргән белемне ничек файдалану бары тик аларның үзеннән генә торачак. Күз алдыгызга китерәсезме, безнең мәктәптән алар бит шахмат буенча разряд та алып китәчәк! Ә иң мөһиме – әлеге уен безне аннан соң да берләштереп торачак, малайларның безнең мәктәп белән дә, шахмат клубы белән дә элемтәләре сакланачак.

ШАХМАТ БЕРДӘМЛЕГЕ

– ...чөнки шахмат – бердәмлек ул! – дип, коллегасының фикеренә кушыла Татьяна Ширяева. – Балалар үзләрен безнең спорт командасында дип хис итә башлый. Әйе, кайчандыр алар начар гамәл кылган, ялгышкан, әмма бу инде үткәндә калган. Проект аларны нормаль тормышка кайтарырга булыша, анда актив катнашырга өйрәтә. Шахмат бит ул үз гамәлләреңне берничә адымга алданрак уйлап төгәл планлаштыру, җиңүгә омтылу гына түгел... Мондый балалар өчен шахмат – уникаль дәва-адаптация чарасы да ул. Сезгә без уйныйбыз кебек кенә тоеладыр. Чынлыкта исә без уен аша яңа, яшерен мәгънәләр табабыз.

Ике Дмитрий – үз мәктәпләренең иң көчле шахматчылары. «Ярыш алдыннан, әлбәттә, дулкынланам. Әмма партияне башлауга ук, пространство һәм вакыт барлыгын онытам һәм үз уеныма кереп чумам», – дип сөйли Дима (фотода – уңда). «Нинди дә булса бер бөек кеше белән уйнарга кызык булыр иде. Мин Карякин белән уйнадым инде, хәзер Магнус Карлсен белән көч сынашасым килә!» – дип хыяллана аның адашы (фотода – сулда).

– Мин бу мәктәпкә күчкәнче үк шахмат белән бераз таныш идем, әмма бирédә аны чынлап ярата башладым, – дип сөйли Влад. – Шахмат уены логиканы үстерә – бу миңа математикада бик булышты! Хәер, башка предметларны үзләштерүдә дә – хәзер мин дүртле һәм бишле билгеләренә генә укыйм.

ИГЕЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР КАЛАСЫНДА

Иртәнге биштә ул Мәскәүдән чираттагы сәфәреннән кайтып төште. Эш белән Дмитрий Рогачёв исемендәге Балалар гематология, онкология һәм иммунология үзәгендә булды. Тагын бер-ике сәгатьтән волонтерлар белән очрашасы, кичкә Республика балалар клиник хастаханәсенең онкология гематологиясе бүлегенә бәләкәй пациентлар һәм аларның әниләре янына – азык-төлек, көнкүреш химиясе һәм гигиена әйберләре илтеп кайтасы бар.

Автор: Алсу Троицкая

– Балалар онкология бүлегендә без биләү чүпрәкләре, памперслар һәм «әниләр кухнясы»на азык-төлек белән ярдәм итүне үз өстебезгә алдык. Юк, сез уйламагыз, хастаханә боларның барысы белән дә тәэмин итә, ашата да, әмма химия терапиясе вакытында, мәсәлән, балаларның аппетитлары үзгәрә. Аларның борщ ашыйсы килә, бер минуттан токмачлы аш, тагын өч минуттан кыздырылган керпе сорарга мөмкиннәр. Шуның өчен дә әнинең балага берәр тәмле әйбер пешерү мөмкинлеге булырга тиеш, – ди «Игелекле кешеләр каласы» хәйрия фонды директоры Гөлнара Җәләлетдинова. – Кер дә юарга кирәк. Кайберәүләр айлар буе дәвалана анда...

ЗУР ЭШЛӘР ҺӘРВАКЫТ КЕЧКЕНӘДӘН БАШЛАНА

Барысы да бик гади башланган. Гөлнара биредә 2007–2008 елларда улы Марат белән яткан. Авыруны көч-хәл белән җиңгәннән соң, бу бүлеккә планлы рәвештә тикшеренергә килеп йөргәннәр, бер очтан биредә дәваланып калган дусларына күчтәнәчләр дә алып килә торган булганнар. Кер юу порошогы кирәклеген белеп, Гөлнара һәрвакыт үзе белән шуны алып килгән. Шуннан башланган да инде: плитә ватылгач, ул дусларына, танышларына хәбәр салган. Сатып алып куйганнар. Бер генә суыткыч җитми башлагач, тагын берне китереп урнаштырганнар. Шул рәвешле ул үзенең керем китерә торган төп эше белән түгел, ә бүлекнең волонтеры буларак шөгыльләнә башлавын сизми дә кала. Шунда гаиләсендә дә: «Рәсми рәвештә хәйрия фонды булдырсак?» – дигән тәкъдим яңгырый.

– Һәм менә 2016 елның 30 маенда фондны теркәдек. 31 майда исә улымның туган көне. Димәк, май аенда ике баламның туган көне, – дип елмая Гөлнара.

ХЫЯЛЛАР

Алар чынга аша. Күптән түгел булган хәлләрдән:

– Бүлектә бер кызда рәсем ясау әсбаплары күрдем. Шундый зур: фломастерлар, бик күп төсле карандашлар. Балаларны яклау көненә бөтен сабыйларга да шундыйны алырга иде, дип хыялланып куйдым. Аларга беркая да чыкмыйча, бүлектә генә утыру күңелсез бит. Пандемия шартларында бигрәк тә. Һәм ике көн уздымы икән, бер танышым шалтырата: «Гөлнара, интернет-кибетләрнең берсендә рәсем ясау өчен арзанлы гына әсбаплар күрдем». Һәм фотосын җибәрә. Кыскасы, без 1 июньне көтеп тормадык, алып, балаларга өләшеп чыктык. Еш була андый хәлләр. Берәр нәрсә кирәк булса, әниләр белән җыелышып, фикер алышабыз, берәр нәрсә эшләсәк яки алсак, әйбәт булыр иде, дибез. Һәм шунда ук тылсымлы рәвештә берәрсе ярдәм итү тәкъдиме белән шалтырата яки яза. Могҗизалар булып тора...

Кайчагында авыруны сөяк мие күчереп утырту аша гына җиңеп була. Бу процедура меңнәрчә пациентка, шул исәптән балаларга да кирәк, әмма донор табу – катлаулы мәсьәлә. Ә көннәр санаулы гына булган очраклар да бар.

– Без Россиядә, ниһаять, җелек (арка мие) донорларының бердәм базасын булдыруны зарыгып көтәбез. Шулай ук ярдәм итәргә теләүчеләр дәүләттән ярдәм алсын иде.

БЕЗ КӨТӘ АЛМЫЙБЫЗ

– Миңа бер сорауны еш кабатлыйлар: «Янып бетмәдеңме әле?» Ә минем аңа хакым юк. Әйе, арыдым, иртәгә ял итәм дигән мизгелләр була... Әмма бераздан ук: «Гөлнара, бу юк, тегесе бетеп килә, барып кайтасы

җир бар», – дип шылтырата башлыйлар. Һәм иртән торасың да, янә эшкә тотынасың.

Безнең фонд ничә балага ярдәм итте дип, еш сорыйлар. Без андый статистика алып бармыйбыз, бу мөмкин дә түгел. Үзәк телеканаллардан берсе «Игелекле кешеләр каласы» турында сюжет төшергәндә, журналистлар безнең фондның ай саен ике йөзләп балага ярдәм итүен санап чыгарган иде.

«Игелекле кешеләр каласы» онкология авырулы балаларга һәм аларның әниләренә төрлечә ярдәм итә. Аның рәсми булмаган икенче исеме юкка гына «Әниләр фонды» түгел бит. Ә менә фондның үзенә теләп ярдәм итәләрме соң?

– Даими рәвештә ярдәм итүче финанс донорларыбыз бар, яңа хәйриячеләрнең ярдәмен дә кабул итеп алырга һәрвакыт әзер без. Безнең, акча җыябыз дип оран салып, ярдәм килгәнне көтеп утырырлык мөмкинлегебез юк. Барысы да үтә күренмәле: предприятиеләр яки аерым кешеләр безгә финанс белән ярдәм итә, без аларга хисап бирәбез. Фонд кешеләргә үзләрен яхшы яктан күрсәтергә, игелекле гамәл кылуда катнашырга тәкъдим итә. Барыбыз бергәләп, авыру балаларга җитди ярдәм күрсәтә алабыз. Балалар өчен иң мөһиме – әнисенең янәшәдә булуы. Әнисенең исә күңеле тыныч, өмете яхшыда булырга тиеш.

«Игелекле кешеләр каласы» хәйрия фондының офисы юк. Әгәр дә сезнең ярдәм итәргә теләгегез бар икән, фондның директоры белән +7 (903) 344-10-00 телефоны аша элемтәгә керергә мөмкин.

УЙЛАП ЯРДӘМ ИТ

Хәйриячелек – җитди шөгыль. Бу эштә иң мөһиме: ярдәмнең аңа мохтаҗ кешегә барып җитүе. Кем әйтмешли, кулдан кулга. Бу җәһәттән теге яки бу фонд эшчәнлегенең ни дәрәҗәдә үтә күренмәле булуын, хисапларын бастырып чыгарамы, юкмы икәнен белү мөһим. Бу яктан тәртип булуына инангач кына, максатлы программа сайлап, кемгә ничек булышырга кирәклеген хәл итүең яхшы.

P.S. Әгәр ярдәм итәргә телисез икән, хәзер үк башлагыз.

ТАТАРСТАНДА ЫШАНЫЧЛЫ ФОНДЛАР ҖИТӘРЛЕК. МЕНӘ АЛАРНЫҢ БЕРНИЧӘСЕ:

«Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды
Меценатлар хисабына яшәп килә һәм төрле юнәлештә әһәмиятле социаль эш алып бара. Әлеге фонд ярдәмгә мохтаҗ кешенең диненә, милләтенә һәм яшенә карамыйча хәйрия ярдәме күрсәтә.
«Ярдәм» фондының Россиядә һәм якын чит илләрдә тиңдәше булмаган уникаль реабилитация үзәгендә сәламәтлеге чикләнгән кешеләрне аякка бастыру буенча эшчәнлеге бигрәк тә киң танылган.
Шулай ук фонд «Бер-беребезгә ярдәм итик» проекты буенча ДЦПлыларга, коляскадагы инвалидларга һәм терәк-хәрәкәт аппараты авырулары булган кешеләргә тернәкләндерү курслары уздыра.
«Ярдәм» фонды балаларга аерым игътибар бирә. Теләче районының Иске Җөри авылында «Гаилә учагы» проектында асрамага бала алучылар өчен ике йорт сатып алынган. Балалар йортларыннан алынган 13 балага «Ярдәм» тернәкләндерү үзәгенең директоры, фондның вице-президенты Мәликә ханым Гыйльметдинова әни булган.
Болар фонд эшчәнлегенең бик күп юнәлешләреннән берничәсе генә.
Элемтә өчен:
Казан шәһәре,
Серов урамы, 4а йорты
Тел.: +7 (843) 223-03-75
e-mail: info@yardem.ru

«Роналд Макдоналд йорты» хәйрия фонды
Гаилә кунакханәсе Казанда Республика балалар клиник хастаханәсе территориясендә урнашкан. «Роналд Макдоналд йорты» анда яшәүче гаиләләр өчен чын мәгънәсендә «өйдән еракта гы өй»гә әйләнә. Проект хастаханәдә дәваланучы балаларның яшәү шартларын уңайлы итүне, иң мөһиме – якын кешеләренең янәшәдә булу мөмкинлеген күздә тота. 2013 елның июлендә ачылганнан алып, «Роналд Макдоналд йорты» 7400 гаиләне кабул иткән. Гаилә кунакханәсе аерым бәдрәф-ваннасы булган 24 йокы бүлмәсеннән, балалар әти-әниләре белән ял итә, аралаша ала торган кунак бүлмәсеннән, нәниләр өчен уен бүлмәсеннән һәм ашханәдән гыйбарәт. Кунакханә территориясендә җәйге веранда һәм балалар өчен махсус җиһазландырылган мәйданчык бар. Кунакханәдә яшәү бушлай, гаиләләрне анда урнаштыру турында карарны ТР Республика балалар клиник хастаханәсе кабул итә.
Элемтә өчен:
Казан шәһәре,
Оренбург тракты, 140а йорты
Тел.: +7 (843) 237-36-23
e-mail: rmhc@ru.mcd.com

Светлана Изамбаева фонды
Татарстан Республикасында 2008 елдан бирле хатын-кызлар, балалар һәм үсмерләр арасында ВИЧ/СПИД профилактикасы өлкәсендә эшчәнлек алып бара. Фонд социаль әһәмиятле ике бурычны хәл итә:
– Социаль әһәмиятле авырулар профилактикасы, ВИЧ авырулы кешеләргә карата яшьләр, җәмгыять, белгечләр арасында стигма һәм дискриминацияне киметү.
– ВИЧ-инфекциягә мөнәсәбәте булган балалар, үсмерләр, хатын-кызлар һәм гаиләләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү.
Элемтә өчен:
Казан шәһәре,
Челюскин урамы, 48 йорт, 67 фатир
Тел.: +7 (843) 297-78-91; +7 (987) 297-78-91
e-mail: info@izambaeva.org

Анжела Вавилова исемендәге хәйрия фонды
Татарстан Республикасындагы онкология авырулы балаларга төрле яклап ярдәм итә.
Кызганыч ки, дөньяда дарулары да, дәвасы да уйлап табылмаган авырулар бар әле. Өлкәнәю насыйп булмаган балалар да бар. Андый пациентларга карата Анжела Вавилова исемендәге фонд 2010 елдан бирле «Паллиатив-хоспис ярдәме» хәйрия программасын гамәлгә ашыра. 2014 елда хосписның Анжела Вавилова фонды төзеткән яңа стационары (балалар һәм өлкәннәр бүлекләре) эшли башлады. Ул 4000 нән артык татарстанлыга ярдәм иткән инде. 2020 елда хосписның өлкән пациентлар өчен яңа стационары төзелә башлады. Әлеге вакытта авыр хәлдәге 300 гә якын бала һәм 50 өлкән яшьтәге кеше фонд карамагында тәрбияләнә.
Элемтә өчен:
420039, ТР, Казан шәһәре,
Академик Королёв урамы, 67 йорт
Тел.: +7 (843) 237-97-57 (фонд);
+7 (843) 237-75-66 (хоспис).

Фото: «Казанские ведомости» газетасы архивы, Ләйсән Ситдыйкованың Инстаграмдагы аккаунты, www.tatarstan24.tv

ЭЧКӘН СУЛАРЫНА ТӨКЕРҮЧЕЛӘР

Хәйриячелек – мөһим һәм кирәкле эш, ул хәтта өметсез хәлләрне дә яхшыга үзгәртә ала. Әмма кайвакыт башкаларга ярдәм итү омтылышы көтелмәгән нәтиҗәгә дә китерергә мөмкин. Бик уңышлы булмаган хәйриячелек тәҗрибәсе һәм анда катнашучылар ясаган нәтиҗәләргә берничә мисал китерик.

Автор: Ксения Сёмина

1 НЧЕ ТАРИХ. ЯРДӘМЧЕЛ ЖУРНАЛИСТЛАР ҺӘМ ҖЫЛЫЛЫК ТРАССАСЫ КОРОЛЕ ХАКЫНДА

Кайчандыр Юрка-чукрак әйбәт аяк киеме остасы була, театрда эшли, патша кызлары һәм корольләр өчен парчадан туфлиләр тегә, берничә җирдә аяк киеме ремонтлау павильоны да тота хәтта. Әмма язмыш зилзиләсе аны эшсез, акчасыз, аннары исә гаиләсез дә калдыра – хатыны башка кеше белән яши башлый, кызы аралашудан туктый. 1999 елга Юрка-чукрак инде берничә ел Казан урамнарында сукбайлыкта йөри. Нәкъ шул вакытта

аны «Казанские ведомости» газетасы хезмәткәрләре күреп ала.

– Журналистлар?.. Керегез алайса. Чәй эчәсезме?

– Ә нишләп сезнең суыгызның төсе сәер?

– Нишләп сәер булсын, эчәргә яраклы су – сазлыктан алам. Бер-ике сәгать тондырам да, учакта консерва банкасында кайнатам.

– Чәй дә саласызмы?

– Әлбәттә! Әнә, клуб янында чәй пакетлары чыгарып ташлыйлар, шуларны җыям да пешерәм. Яхшы әйбер уйлап тапканнар – бер эчәрлек аерым төргәк, элегрәк мондыйлар юк иде бит. Йә, эчәсезме инде?

Юрка-чукрак кушаматлы Геннадий Александрович Гордеев ул чакта яшәгән җылылык трассасындагы шушы диалогтан аны җәмәгатьчелек фикерләгәнчә нормаль тормышка кире кайтару эпопеясе башлана да инде. Газетада «трасса короле» маҗаралары хакында материал чыга, аның язмышы күпләрне битараф калдырмый. Северный бистәсеннән Елизавета Курзаева, газетага шалтыратып, сукбайны үзендә яшәтергә әзер булуын белдерә, тик бер шарт куя: редакция ир-атның моннан 13 ел элек югалган паспортын юллауда булышырга тиеш. Икенче бер әби сукбайны юындырырга, ашатырга һәм чиста-пөхтә киендерергә әзер булуын хәбәр итә. Менә бераздан Юрка-чукрак кабат кеше кыяфәтенә керер, кабат Геннадий Гордеевка әйләнер кебек тоела. Әмма барып чыкмый. «Казанские ведомости» үзенең хәйрия акциясендәге кискен үзгәрешләрне чираттагы мәкаләсендә бәян итә: рәкетчы бомжлар, Гордеевны ниндидер бер хатын үзенең йортына кертергә теләвен белеп алгач, аның белән көченергә ниятли. Елизавета Курзаева, әлбәттә инде, шүрләп кала һәм сукбайны коткару проектыннан баш тарта. Паспортны торгызу процессында исә Геннадий Александровичның Казандагы фатирда теркәлгән булуы ачыклана.

– Хәзер үк өемә кайтам. Булды, җитте миңа чүплектә яшәргә! Бомж түгел бит мин! Хәзер минем паспортым бар һәм өемнән беркем дә куып чыгара алмаячак. Ә инде хатыныма бу ошамый икән, үзе чыгып китсен. Мин исә үз өемдә яшәячәкмен. Иртәгә эшкә урнашачакмын, – дип белдерә ул.

«Россиянең горур гражданы – Геннадий Александрович Гордеев өенә кайта. 25 августтан аның тормышы яңадан башлана. Кызганыч, шәһәрләрендә бер сукбайның кимүен казанлылар ул көнне белми калды», – дип тәмамлана «трасса короле» хакындагы мәкаләләр шәлкеме. Берничә айдан соң Юрка-чукракның кире сукбайлыкка чыгасын кем белгән бит ул вакытта? Аны кабат урамга чыгып китәргә нәрсә мәҗбүр иткәндер – билгесез. Җылылык трассасына «керү» юлын инде япканнар, шунлыктан Юрка-чукракка

Юрка-чукрак кушаматлы Геннадий Александрович Гордеев.

яшәр өчен яңа урын эзләргә туры килгәндер, мөгаен. Журналистлар бүтән аңа ярдәм итәргә тырышмый да инде. Үзләренең изге нияте аркасында, кешенең сукбайга әйләнүе өчен берничә ел буе бер-берсен генә битәрлиләр.

– Без героебызның үзгәрүен, социумга кайтуын теләдек – нигәдер бу безгә аның өчен яхшырак булыр кебек тоелды. Без аның ирекне бөтенләй башкача аңлавы хакында уйланмадык та, – ди «трасса короле» турындагы материаллар авторы Алсу Мөбәракшина. – Безгә аңа ризык калдырырга да, китәргә кирәк булган. Әмма бу иң катлаулысы да шул инде: син теләгәнчә яки сиңа дөрес тоелганча түгел, бәлки, кеше үзе теләгәнчә булышу.

2 НЧЕ ТАРИХ. БЛОГЕР ҺӘМ АЛМА САТУЧЫ ӘБИ ХАКЫНДА

Моннан ике ел элек җәйге кичтә Татарстандагы бер блогер дус кызы белән Казан супермаркетларының берсенә ашамлык алырга керә. Чыкканда, алар ишек янында алма сатып торучы әбигә игътибар итәләр. Яшьләргә әби бик кызганыч булып тоела. Мондый караңгыда алма сатарга мохтаҗлыктан чыккандыр, дип уйлыйлар. Блогер икмәк, сөт, казылык сатып ала да пенсионер әбигә бирә. Әбинең күңеле була. Блогерның дус кызы моны смартфонга төшерә. Пиарда гаепләрләр дип, блогер элеге видеоны баштарак социаль челтәренә дә куймый. Әмма дуслары күндерә – башкалар да үрнәк алсын һәм игелек эшләсен янәсе. Видео шул рәвешле челтәргә эләгә, блогер үзенең язмасында ялгыз картларга булышырга өнди.

Бераз вакыттан соң, Татарстан басмаларының берсеннән шылтыраткач һәм әлеге әби белән очрашырга тәкъдим иткәч, егетнең ничек гаҗәпләнүен күрсәгез иде сез! Әби, блогерны табуда булышуларын үтенеп, редакциягә мөрәҗәгать иткән. Видео гаиләдә конфликт китереп чыгарган икән: аны әбинең балалары, танышлары, авылдашлары күргән... Бәхетсез әбине гаепләгәннәр: балалар бөтен кирәкле нәрсәне алып биргәндә, ай саен пенсия килеп торганда, үзеңне шулай хәерче кебек тотарга ярыймыни инде, янәсе? Инфарктка китереп җиткерә язганнар. Блогер алар белән көрәшүдән баш тарткан, хәл тагын да начарланыр, дип курыккан. Социаль челтәрдән видеосын алып аткан. Әби әле блогерга тагын берничә тапкыр шалтыраткан, хастаханәгә салуларын әйткән, даруларга күп акча китүдән зарланган... Блогер аны бик кызганган, әмма инде башка булышырга җөрьәт итмәгән. Үзе өчен нәтиҗә ясаган – игелек эшлисең икән, бернинди видеосын да, фотосын да беркайчан беркая да куярга кирәкми. Моны фәлсәфә законы да раслый бит: «ялгыш аңлау мөмкин булган һәрнәрсә ялгыш аңланачак та»...

3 НЧЕ ТАРИХ. РИЭЛТОР ҺӘМ ҖИМЕРЕК ӨЙДӘ ЯШӘҮЧЕ МАЛАЙ ХАКЫНДА

«Мин бу кешеләр өчен хәлемнән килгәннең барысын да эшләдем. Минем миссиям тәмам...» – күчемсез милек сату агенты Ләйсән Ситдыйкованың инстаграм-аккаунтындагы гыйнвар азагындагы язмасы шулай тәгәлләнә. Кызны берничә мең язылучысы да хуплый, шул исәптән хәбәрдә сүз барган кешеләргә торак сатып алу өчен акча җыюда катнашучылар да. Үткән көздә башланган тарих Ләйсән өчен әле бүген дә тәгәлләнмәгән.

13 яшьлек Тимур аңа ноябрьдә шалтырата һәм яшәп тору өчен бүлмә эзләвен үтенә. Әбисе һәм инвалид әнисе белән яшәгән йортның менә-менә ишелергә торуын аңлата. Ә алда – салкын кыш бит... Ләйсәнгә малай бик кызганыч тоела, һәм ул булышырга ниятли. Тимурның өен күргәч, Ләйсән шаккаты. Баланы мондый коточкыч шартларда калдыра алмый. Гаиләсе белән килешә: Тимур вакытлыча аның өендә яшәячәк, аннары приютка күчәчәк. Малайга торак сатып алыр өчен, хәйриячелек эшен башлый.

Ләйсәннең Инстаграмдагы сәхифәләреннән туганнан бирле хәрабәдән башы чыкмаган

1 13 яшьлек Тимур.

2 3 Тимур элек яшәгән йорттагы шартлар.





Тимурның гомерендә беренче тапкыр стоматологка баруын, яңа матур киемле булуын, дуслар табуын – кыскасы, нормаль үсмерләр кебек яши башлавын күреп була. Кыз һәм аның гаиләсе Тимурны үз итә. Буш көннәрендә Ләйсән приюттан малайны үзенә алып китсен өчен, әнисе ышанычнамә язарга вәгъдә бирә.

Акча җыю акциясе социаль челтәрләрдә һәм телевидениедә киң яңгыраш таба. Бик күп кешенең игелекле гамәле нәтиҗәсендә Ләйсән берничә көн эчендә бүлмә сатып алырлык акча туплый. Күчену көне якынлаша... Шуннан сюрпризлар башлана да инде.

Бүлмәне күргәч, малайның әбисе Нурия апаның чырае үзгәрә. Ул өч бүлмәле фатирга күчәргә өметләнгән икән. Авиатөзелеш районы гаиләгә фатир бүләк иткән икән бит инде. Әмма аны сатканнар да, фатирны Кукмарадан алганнар. Анда исә Тимурның әнисе дә, әбисе дә яши алмый, шунлыктан Казандагы өлешчә үзләренеке булган тузган торакка килеп урнашканнар да кабат фатир даулый башлаганнар...

Торакны Тимурга бүләк итү кәгазен шундук язуны шарт итеп куеп, Ләйсән яңа бүлмәне Нурия апа исеменә терки. Әмма бүлмәгә күченгәч, малайның әнисе һәм әбисе бүләк кәгазе язудан баш тарта, яңа торакны исә сатарга җыена. Алай гына да түгел, алар Ләйсәнне үзләре өчен җыелган акчаны үзләштерүдә гаепли башлый. Риэлтор кыз исә бөтен керем һәм чыгымнар өчен социаль челтәрдә тиененә кадәр хисап биреп бара. Хәйриячелек мажаралары кызган мәлдә Нурия апа вафат була. Бүлмәдә хәзер Тимурның инвалид абзасы яши. Әнисе Тимурны приюттан алган. Беркадәр вакыт элек малай Ләйсәнгә Вотсапта җавап бирми башлаган. Хәзер аның язмышы опека хезмәтенә генә мәгълүм. Бүлмәнең документлары Ләйсәндә саклана, ул кайчан да булса Тимур әлеге торакка милек хокукын алыр, дип өметләнә.

– Мин үсмер өчен бик борчылам. Аның урамда тәмәке тартуын күргәннәр. Моңа ышанасым килми. Мин белгән Тимур тәмәке тартмый иде. Аның безнең белән булмавы бик кызганыч. Тимур яратуга һәм кайгыртуга мохтаҗ, без аңа моны бирә алабыз. Аның бездән башка кемгәдер кирәк булуына ышанмыйм, – ди Ләйсән. – Әлеге вакыйга хәйриячелектән минем гайрәтемне чигерде, дип әйтә алмыйм. Әмма ул миңа һәр нәрсәнең сәбәбе булуны аңлатты. Бу гаилә тиктомалдан гына җимерек йортта яшәүгә калмаган бит. Мин бернәрсәгә дә үкенмим, әмма Тимур белән мөнәсәбәтләрне торгызуга өметләнәм. Аның өчен кайгырам һәм бу бала яхшырак тормышта яшәргә лаек, дип саныйм. Т

4

Волонтер Юлия Хәкимова һәм Казан шәһәр Думасы депутаты Рушан Минһаҗев Нурия апа белән очраша.

5

Ләйсән Тимур өчен шопинг оештырган.

6

Тимурның элеккеге йорты.

PRESSA

COVID-19 га

Татарстан предприятиеләре һәм волонтёрлары пандемия белән көрәштә.

«Татнефть» компаниясе **МЕДПЕРСОНАЛ ӨЧЕН САКЛАГЫЧ КОСТЮМНАР** җитештерүне җайга салды. Комплектка куртка, чалбар, халат, алъяпкыч, җиңсәләр, башлык, бахила керә. Костюмнарның күп катлы тукылмаган материалы бактерияләр үтеп кермәслек итеп ясала. Тәүлегенә 600 комплект җитештерелә.

City Star Wear модалы кием бренды көн саен **2500 САКЛАГЫЧ БИТЛЕК** чыгаруны оештырды. Алар 100% киҗе-мамык тукымадан тегелә. 2020 елның апрелендә City Star Wear 10 мең шундый битлекне катлаулы эпидемиологик вазгыять шартларында эшли торган «Казан» аэропорты персоналына хәйрия ярдәме буларак тапшырды.

«ТАНЕКО»да **БИТЛЕКЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ** җайга салынды. Алар Татарстанның медицина һәм социаль хезмәтләренә тапшырыла. 2020 елның апрель урталарына татарстанлыларга 60 млн битлек тапшырылды, шулай ук аларны җитештерү станоклары алынды, дип хәбәр итә нефтьчеләрнең матбугат хезмәте.

КАРШЫ

Кулланучыга «Носкофф» сәүдә маркасы буенча билгеле «Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы бер тапкыр кулланыла торган саклагыч комплектлар һәм киҗемамык тукымадан күп тапкыр кулланыла торган битлекләр җитештерә башлады. **КУЛЛАНУЧЫГА БИТЛЕКЛӘРНЕ ҺӘМ САКЛАГЫЧ КИЕМНӘРНЕ ФАБРИКА ТҮЛӘҮСЕЗ НИГЕЗДӘ ОЗАТА.**

«Полиматиз» һәм «Элекон» заводлары **ТУКЫЛМАГАН МАТЕРИАЛ ҖИТЕШТЕРҮНЕ** күп тапкырларга арттырды. Алар медицина битлекләре һәм медицина киемнәре җитештерү өчен каралган. Киемнәр өчен резинка җитештерүне «КВАРТ» предприятиесе үзләштерде.

Гомумроссия халык фронтының яшьләр бүлеге, «Волонтёр медиклар» хәрәкәтенең төбәк бүлеге белән бергә, өлкәннәргә азык-төлек һәм медикаментлар китерә. Гаризалар кайнар линия телефонына кабул ителә: 8 (800) 200 43 11. Үзара ярдәм буенча #МыВместе бөтенроссия акциясе кысаларында Татарстанда 3276 кешедән торган волонтёрлар командасы оештырылган.



«Татнефть» түләүсез нигездә Татарстанның көньяк-көнчыгышында **ТРАНСПОРТ, АШЫГЫЧ ЯРДӘМ МАШИНАЛАРЫ ӨЧЕН ЯГУЛЫК БИРӘ**, йогышсызландыру матдәләре сатып ала, госпитальләрне кирәкле җайланмалар белән тәэмин итә.



Нефть башкаласында «Игелекле Әлмәт» шәһәр штабы эшли. Ул ярдәмгә мохтаҗ шәһәрлеләргә тиз арада булышу өчен оештырылган. Өлкән кешеләргә ярдәм итү буенча «Татнефть» ГАҖ тарафыннан оештырылган ресурс үзәге беренче булып эшләп китте. Компаниянең яшьләре һәм Әлмәт дәүләт нефть институты студентлары пенсионерларга **АЗЫК-ТӨЛЕК, ДАРУЛАР САТЫП АЛА, ТКХ ӨЧЕН ТҮЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ.**

«ТАНЕКО» комплексы базасында **АНТИСЕПТИК ЭРЕМӘ ҖИТЕШТЕРҮ** җайга салынды. Җитештерүчәнлеге – тәүлегенә 7,5 тонна. Эремә Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тәкъдимнәренә буенча ясалган рецептура нигезендә җитештерелә. Беренче булып мондый эремәләр түләүсез нигездә «Ярдәм янәшәдә!» республика хәрәкәте волонтерларына бирелде.



КАМАЗ 2 нче класслы саклагыч үзлеккә ия **РЕСПИРАТОРЛАР ҖИТЕШТЕРҮ ӨЧЕН ҖАЙЛАНМА** сатып алды. Җитештерү линиясе 2020 елның июне ахырында эшләп китте. Респираторлар республика дәвалау-профилактика һәм дәүләт учреждениеләре медперсоналы өчен каралган.

2020 елның 10 апрелендә дөньяда иң зур «Руслан» йөк самолеты Кытайдан Казанга **5,8 МЛН МЕДИЦИНА БИТЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҖИТЕШТЕРҮ БУЕНЧА 6 ЛИНИЯ** алып кайтты. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча рейсны «Татнефть» ГАҖ оештыра. Бортта шулай ук **КОРОНАВИРУС БЕЛӘН АВЫРГАННЫНАРНЫ КҮЧЕРЕП ЙӨРТҮ БОКСЛАРЫ** да кайтты. Җитештерү линияләре аена 15 млн нан артык битлек җитештерүгә көйләнгән.

«Азнакай киемнәре» тегү предприятиесендә **ТИЗ АРАДА ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ ХЕЗМӘТЕ ҺӘМ МЕДПЕРСОНАЛ ӨЧЕН САКЛАГЫЧ КОСТЮМНАР ҺӘМ КОМБИНЕЗОННАР** җитештерәләр. Тәүлегенә 600 ләп комплект тегелә. Предприятие җитештерү күләмнәрен арттырырга ниятли.

УМАРТАЧЫНЫҢ ҖАН АВАЗЫ

Фото: Александр Ефремов

Автор: Руфия Фазылова

Узган көз Кама Тамагы районы җирләрен «Август» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте алган. Һәм шуннан бирле җирле халыкның төн йокысы качкан – алга таба ничек булыр? Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, район газетасында рус телендә игълан басылган. Аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: «2021 елның 20 апреленнән 25 ноябренә кадәр кырлар химикатлар белән эшкәртеләчәк. Шуңа күрә «Август-Кама Тамагы» ҖЧҖ җитәкчелеге белән килештермичә, кырга мөгезле эре терлек, сарык, умарта кортларын чыгармаска». Әлбәттә, халык шок хәлендә калган. Хәзер мөгезле эре терлек белән бал кортларын бергә абзарда ябып тотаргамы?

ЫШАНМАУ...

Кама Тамагы районы умартачыларга бай. Корт тотучы өч йөзләп хуҗалык бар биредә. Шуларның иң күбе Балтач авылында яши икән.

– Авыл буенча көзен барлыгы 466 баш умарта бар иде, – ди умартачылык буенча районның баш инспекторы Сәет Мөхәммәдуллин. – Язга азрак кимегән дип беләм. Кышны барыбер бер үлемсез дә чыгып булмый инде.

Узган елга кадәр Балтач авылы җирләре «Ак Барс» холдингына караган. Көз көне яңа хуҗа килгән – «Август» ҖЧҖ. (Район җирләре бүген «Август» ҖЧҖ һәм «Кызыл Шәрык» ААҖ кулында). Дөресен әйтим, әлеге яңалыкны халык сөенеп кабул итмәгән. Моның сәбәпләре төрле. Беренчедән, «Август» ҖЧҖ – Мәскәү оешмасы, Татарстанда әле чагыштырмача яңа эшли башлаган агрофирма. Җирле халык алардан ни көтәсен белми. Икенчедән, Мәскәү оешмасы районга зур акчалар белән килгән. Инде бү-

геннән үк Кама Тамагы җирләрен яңа заманча техника эшкәртә башлаган. Әлбәттә, бу бик яхшы – ташландык җирләр булмаячак, кешеләр эшкә дә тилмермәс, дип өметләник. Ләкин җирле халыкны икенче әйбер куркыта – аларның хәленә кererләрме?

– «Август» ҖЧҖ бик зур оешма, алар бөтен төр агуны да үзләрендә ясый, – диде Сәет Мөхәммәдуллин. – Яшерен-батырын түгел, элеккеге «Ак Барс» агрофирмасы болар кебек бай түгел иде. Җирне дә өсте-өстенә агуламадылар. Аңа бит акча кирәк. Ә «Август» ҖЧҖ өчен ул проблема түгел...

Чынлап та, әлеге Мәскәү оешмасы Татарстанга зур амбицияләр белән килгән. Рәсми сайтларында урнаштырылган мәгълүматка караганда, корткычларга каршы, уңыш бирүне яхшырткан гербицид, десикант, фунгицид кебек химик препаратларны хәтта БДБ илләренә сатуга чыгаралар. Ә гомумән алганда, «Август» ҖЧҖ мәгълүм табышмактагы кебек – ура, суга, җилгәрә, үзе төяп җибәрә. Ягъни игенне үстерәләр, итне җитештерәләр, аны сатуга чыгаралар. Шунысын да әйтим: алар үзләрен, фәкать экологик чиста продукция җитештерәбез, дип рекламалый. Ә киләчәккә планнарга килгәндә... алар бик зур. Мисал өчен, Казаннан йөз кырык чакрым ераклыкта, ә төгәлрәге Яшел Үзән районында, берьюлы 140 мең тонна ашлык саклый ала торган элеватор комплексы төзиячәкләр, һәм башкалар, һәм башкалар...

Менә шуңа да җирле халык бу көчле инвестордан шүрли. Алар белән исәпләшерләрме? Җирләрне агулап эштән чыгармасларымы? Умартачылар исә бигрәк тә ут йотып яши, чөнки таякның юан башы иң беренче аларга төшәчәк бит. Дөрес, барысының да Сәет абый кебек батырлыгы юк – диктофонга сөйләргә шүрләделәр.

– Ә алдагы елларда кортлар үлмәдеме? – дим районның баш умартачысына.

– Бер дә үлмичә булмый инде. Тик күпләп кырылмады, – ди Сәет Мөхәммәдуллин. – Агрофирма агу сибәсе көнне безнең белән килештерә иде. Гомумән, алар артыгын кыланмадылар...

Дөрес, «Август» ҖЧҖ дә җирле умартачыларга «артыгын кыланмаска» вәгъдә биргән. 12 апрель көнне Кама Тамагы районы хакимиятендә очрашу булган. Анда район башлыгы Наил Вазыйхов белән «Август» ҖЧҖ нең генераль директоры Алексей Копанев катнашкан. Җитәкчеләр җирле умартачыларны тынычландырырга тырышкан – агуланасы кырлар турында мәгълүмат ике-өч тәүлек алдан вотсап төркеменә хәбәр ителәчәк. Ә иң мөһиме – өченче класслы агу кулланачаклар, ягъни куркынычсызрагын.

– Ул очрашуга ун умартачы килергә тиеш иде, – ди Сәет абый. – Алдан исемлек төзедек. Ләкин 12 апрель көнне кисәк кенә барысының да «эше» килеп чыкты. Нәтиҗәдә, район хакимиятенә ике генә умартачы бардык. Гаҗәпләнәсе юк инде, шушы районда яшибез. Алдагысын уйлыйлар...

АТА-БАБАДАН КАЛГАН ШӨГЫЛЬ

Умартачыларны бер сыйфат берләштерә – алар үз эшләренең фанаты. Бал кортларын карау ул сиңа фәлән сәгатькә эшкә барып кайту гына түгел, бу – яшәү рәвеше. Ә күбесенең ата-бабадан калган шөгыле дә. Балтач авылында да умартачы нәселләре күп. Шул ук Сәет Мөхәммәдуллинның да ата-бабасы умартачы булган.

– Кечкенәдән кортлар янында үстем. Ә умартачылык белән ныклап торып армиядән кайткач шөгыльләнә башладым, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – 1990 нчы еллар башы иде ул. Бүгенге көндә 130 оя кортым бар. Көзгә кергәндә 150 баш иде.

– Ел саен шулай егерме оя корт үләме? – дим.

– Төрлечә була. Хәзер кортларның иммун системасы какшады. Моны тәҗрибәле умартачылар да таный. Хәтта кырда тургайлар үлеп бетте, башкага кая барасың. Бал кортлары да шул агулы үсемлеккә килеп куна бит. Соңгы елларда кортлар күпләп югала. Чыгып китәләр дә кайтмыйлар, кайдадыр үлеп калалар.

Дөрес, тәҗрибәле умартачы бал кортларын агудан гына һәлак була, дип уйламый. Аның бүтән сәбәпләрен дә атый. Мәсәлән – бет. Ояга бер керсә, ул кортларны үтереп бетерә. Шуның өчен һәр ояны карап, көздән химикатлар белән эшкәртеп калдыралар.

– Тагын бер сәбәп – кортлар хәзер элеккегә караганда азрак яши, – ди Сәет абый. – Бу, әлеге дә баягы, агуларның зыяны булырга мөмкин. Әлбәттә, моны раслый торган документларым юк. Ләкин башка төбәкләрдә яшәүче умартачылар да шундый нәтиҗәгә килгән. Әле бит бал кортларының төрле төре бар. Кайберләре агулы чәчәк серкәсен ашауга үлми, ә күпмедер вакыттан гына җан бирә. Мисал өчен, «Урта рус» кортлары көз көне бик эшләми, ягъни

Балтач авылының умартачылар нәселләре вәкилләре – Сәет Мөхәммәдуллин, Рим Әхмәдуллин.

еракка очмыйлар. Шуның өчен алар көзгә агуланып кермиләр. Димәк, кышны да җиңелрәк кичерәләр. Минем кортларның яртысы «Урта рус», ә калганнары «Карпат» һәм «Карника» токымлы. Кышны чыга алмаучылар арасында соңгылары күбрәк.

Балтач авылының тагын бер умартачысы – Рим Әхмәдуллин. Шулай ук умартачылар нәселеннән. Башта бабасы, аннан соң әтисе бал кортлары асраган.

– Әти хәзер урын өстендә инде. Кырык оя кортны үзем генә карыйм, – диде Рим.

Дөрес, бал аерткан чорда читтә яшәүче абыйсы булыша икән. Әхмәдуллиннарның да берничә оя кортлары кышны чыкмаган. Көздән дә үлгәләгәннәр. Нәтиҗәдә, илле баштан кырыкка гына калган.

– Әлбәттә, агуның зыяны зур, – диде Рим. – Хәтта кырларны агулаган чорда иртәнге якта бакчага да зәһәр ис тарала. Безнең авыл тау астында утыра, ягъни кырга сипкән агу һава белән авылга да килә.

– Район газетасындагы игъланны укыдыгызмы? – дим.

– Әйе. Сыерлар, бал кортлары белән үзебез дә каралтыда ябылып утырырбыз, дип уйлаштык. Еласаң ела, көлсәң көл...

Рим өчен умарта кортлары хобби гына түгел, ә яшәү, тормышны алып бару чыганагы да. (Хәер, биредәге умартачылар өчен бал сату төп керем, чөнки авылда бүтән эш урыны юк). Ялгызы ике бала үстерә ул. Кортлар үлеп бетсә, ничек яшәрбез, дип бик борчыла.

ӨМЕТ...

Районның тагын бер атаклы умартачысы – Рөстәм Сафин. Ул Кама Тамагының үзендә яши. Белеме буенча икътисадчы, юрист та ул. Шул юнәлештә хезмәт тә куйган. Ә соңгы елларда фәкать умартачылык белән шөгыльләнә. Тик бу юнәлештән дә Рөстәм абый бизнес ясаган – кечкенә әрҗәләр ясап, оясы белән бал кортлары сата икән.

– Районда фермерлар продукциясен җыя торган бер урын булсын иде, – ди Рөстәм Сафин.

Район газетасында басылган игъланга аның әллә ни исе китмәгән:

– Миңа калса, анда аңлашылмаучанлык килеп чыккан, – диде тәҗрибәле умартачы. – Әлбәттә, алты ай буе мөгезле эре терлекне, бал кортларын ябып яткырып булмый, бу мөмкин түгел. Районда яңа эшли башлаган«Август» ҖЧҖ, мөгаен, халыкны алдан кисәтеп кенә куйгандыр.

– Авылларда яшәүче умартачыларны курку баскан – җирләрне агулап бетерерләр, дип борчылалар. Ә сездә андый курку юкмы? – дим.

– Курку дип... Җәй көне күренер инде, алдан борчылмыйк. (Елмая. – авт.) Өченче класслы агу сиптерәбез, дип вәгъдә бирделәр бит. Агрофирмалар да шундыйны сиптерә иде. Аллаһка тапшырган инде...

Рөстәм Сафин, бик рәхәтләнеп, умарта ояларын күрсәтеп йөрде. Чын фанатларча, бик яратып эшләгәне күренеп тора – балалары турында сөйли диярсең!

– Иң беренче эш итеп, кыш чыккан һәр оя кортны чиста әрҗәгә күчерәбез, – ди хуҗа. – Рамнарның да чисталарын тезәбез. Аннан бал запасларын куябыз. Иске баллар күп бит, сатылып бетми ул.

Рөстәм абыйның умарталары йөз баштан артык. Шуның яртысы үзе яшәгән йорт бакчасында, калган яртысы туган авылы Салтыкта тора икән.

– Күршеләр бакчада моның кадәр корт тотканга сүз әйтмиләрме? – дим.

– Күршеләр белән уртак телне табабыз, Аллаһка шөкер. Ике метрлы калай коймалар куйдык. Аннары, кортлар оча торган юлда йортлар юк. Безнең кортлар «Урта рус» токымлы, ә алар усал түгел. Менә әле сезнең белән торабыз, берсе дә тими.

Рөстәм Сафин умартачыларның тагын бер проблемасын атады – балны урнаштырырга урын юк. Ун, егерме оя корт булганда әле җае табыла. Аз-азлап та алып бетерәләр. Ә менә баш саны ун дистә белән исәпләнгәндә, бу чын проблема икән.

– Безнең балны Россиядән читкә чыгарып булмый, рөхсәт юк, – ди умартачы. – Әле ярый ел саен алучы клиентларым бар. Ярминкәләргә дә йөрибез үзе. Тик аның өчен базарга иртәнге өчтә чыгып басарга кирәк. Әле балың сатыламы-юкмы. Районда фермерларның продукциясен җыя торган бер урын булсын иде ул. Элек бит шундый үзәкләр бар иде. Эш күпкә җиңеләер иде.

«УЙЛАП БЕТЕРМӘГӘННӘР...»

Умартачылар белән аралашканнан соң, Кама Тамагы районының Авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек идарәсе җитәкчесе Илфат Вәлиев янына юнәлдек. Җирле җитәкче менә нәрсәләр сөйләде:

– Әлеге мәсьәлә белән республикада беренчеләрдән булып февраль аенда ук шөгыльләнә башладык. Районның сиксәнләп умартачысын

җыеп, конференция үткәрдек. Чагыштыру өчен – районда өч йөзләп умартачы бар. Республикадан да вәкилләр килгән иде. Борчыган барлык мәсьәләләрне уртага салып сөйләштек. Умартачылар белән ел әйләнәсе элемтәдә торабыз. Әлегә кадәр кортлар үлү буенча районда зур проблема булганы юк. Алга таба да шулай эшләрбез дип өметләнәм.

– Район газетасында игълан басылган икән бит... – дим.

– Әйе, ул турыда да сөйләшү булды. Халык ул игъланны бик дөрес аңлап җиткермәгән. Беренчедән шуны әйтим: монда кортлар турында гына сүз бармый. Бүген көтүче дигән һөнәр югалып бара. Авылларда сыерлар аз калгач, көтүләр дә бетте. Кеше хәзер сыер, бозауларын кырга куа да чыгара. Ә мөгезле эре терлек, сарыклар иң беренче яшеллеккә чаба. Язын ул кышлап чыккан иген була. Андый уҗымны ашаган маллар агуланырга яки эчләре күбәргә мөмкин. Аннан соң, уҗымны таптау да бит бу. Шуңа күрә, ике якка да зыян килмәсен өчен, «Август» ҖЧҖ әнә шундый игълан бастырды.

– Анда бит бал кортларын да чыгармаска диелгән...

– Монда инде игъланның эчтәлеген уйлап бетермәгәннәр. Кортларны алты ай чыгармау турында сүз бармый. Ә фәкать агу сиптергән көнне кортлар кырга очмасын дигән киңәш инде ул. Алдагы елларда да шулай умартачыларны кисәтә идек. Умартачылар белән вотсапта аерым төркемебез бар. Кырларга агу сибеләчәге турында ике тәүлек алдан хәбәр иттек. Әлбәттә, алга таба да шулай эшләячәкбез.

Узган ел Илфат Вәлиев белән Кама Тамагы районында язгы чәчү барышын карап чыккан идек. «Татарстанның үз Кырымы бар», – дигән иде җитәкче ул чакта. Чынлап та, биредә җирләр ташлы, таулы. Без моңа үзебез инандык. Шул ук күрше Буа районы белән чагыштырганда, җир белән күк арасы.

– Шуңа да безгә инвесторлар килергә бик атлыгып тормый, – диде Илфат Вәлиев. – Куркалар. Бәлки әле «Август» ҖЧҖ биргә килү район өчен авыл хуҗалыгы юнәлешендә үсү булыр. Бик көчле оешма бит, эшләп карасыннар.

– Җирләрне агулап бетермәсләрме? – дим.

– Ә агуламыйча бүген нәрсә үсә? Авыл кешесе шул бәрәңгене дә агуламыйча ашамый. Әле колорадо коңгызына сиптерелә торган агу икенче класслы санала. Ә кырларга өченче класслысы сибелә.

– Аны тикшереп торучы булмас, дип борчыла авыл халкы...

– Соң, санитар таләпләр бар. Аны үтәмәгән очракта зур штрафлар каралган. Аннан соң – район җитәкчелеге халыкка дошман түгел бит, моны контрольдә тотачакбыз.

Район башлыгы дигәннән, Наил Вазыйхов белән очрашып булмады. Эшләре буенча Казанга киткән иде ул. Җитәкче белән телефоннан шактый озак сөйләштек. 12 апрельдә районның

– Бәлки әле «Август» ҖЧҖнең биргә килүе район өчен авыл хуҗалыгы юнәлешендә үсү булыр, – ди Илфат Вәлиев.

җирле умартачыларына әйткән бөтен сүзне янә кабатлады ул – агу өченче класслы булачак, агуланасы кырлар турында мәгълүмат халыкка алдан хәбәр ителәчәк. Елдагыча, сезон вакытында җирләр елга ике тапкыр агуланачак. Наил Вазыйхов моны үз контроленә алачак.

СҮЗ БЕР, ГАМӘЛ ИКЕНЧЕ...

«Татарстан» журналының умартачылар турында беренче генә язуы түгел. Оя-оя корт үлү соңгы елларда республикада гадәти хәлгә әйләнде. Иң аянычы – аның нәрсәдән кырылганын раслап булмый. Шул ук Кама Тамагының баш умартачысы Сәет Мөхәммәдуллин бер очрак турында сөйләде – елдан артык җирле умартачы суд юлын таптый икән. Дистәләп оя корты һәлак булган. Кайсы кырдан агуланганын да чамалый, әмма судта раслый алмаган. Югыйсә үлгән кортларны экспертизага да алып барганнар. Тик анда кортларның төгәл кайсы кырдан (туфрак анализын да алганнар) агуланганын әйтә алмаганнар. Ике ел элек Мамадышта Гыймазовларның 200 оя корты (!) бер ай эчендә үлеп беткән иде. Ул вакытта да кырны агулаучыны җәзага тарта алмаганнар...

Бер карасаң, умартачыларның проблемалары хакында дәүләт башлыгы да белә кебек. 2020 елның 30 декабрендә Президент Владимир Путин Россия Федерациясенең «Умартачылык турында» Федераль законына кул куйды. 6 бүлек, 18 маддәдән торган Законда кортларның пестицидлар, агрохимикатлар белән агулануын булдырмау турында аерым маддә бар. Журнал укучыларыбызга шуның кыскача эчтәлеген биреп узарга кирәктер.

16 нчы маддә. Умарта кортларының пестицид һәм агрохимикатлар белән агулануын булдырмау.

1. Агу сибү эшләренә керешкәнче, әлеге җир кишәрлекләреннән җиде километрга кадәр ераклыктагы торак пунктларда яшәүче халыкка өч көн алдан хәбәр итәргә (радио, басма матбугат, электрон һәм башка элемтә чаралары аша).

2. Әлеге мәгълүмат түбәндәге эчтәлектә булырга тиеш:

1) Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән эшкәртеләчәк җирнең чикләре;

2) Эш вакыты;

3) Эш ысулы;

4) Җир эшкәрткәндә кулланылачак пестицид һәм химикатларның исемлеге һәм аларның куркынычлылык классы;

5) Пестицид һәм агрохимикатларның куркыныч үзлекләре турында мәгълүмат;

6) Бал кортларын умарталарында изоляцияләү вакыты.

3. Бал кортлары өчен куркыныч пестицид һәм агрохимикатларны куллану 1997 елның 19 июлендә кабул ителгән 109 нчы Федераль законга таянып эшләнергә тиеш.

...Әйе, закон бар, тик ел саен фәлән мең корт үлә бара. Башкортостан, Мари Эл һәм Удмуртия республикаларында яшәүче умартачылар да чаң кага – ел саен фәлән мең корт һәлак була. Киров, Воронеж, Брянск, Ростов өлкәләрендә дә шул ук хәл... Хәер, фаҗига Россиягә генә түгел, чит илләргә дә таныш икән – Израиль, Кытай, АКШ, Тайвань... Мисал өчен: АКШта соңгы ун ел эчендә бал кортлары 80 процентка кимегән. Белгечләрнең фикере нигездә уртак – кортларны химик ашламалар юк итә. АКШ галимнәре исәпләп чыгарган: бал кортларының үлеме ил икътисадына ел саен 5 миллиард доллар күләмендә зыян китерә һәм, кимендә, 30 процент уңышны алып җиткермәүгә сәбәп булып тора. Тик... барыбер җирне агулау дәвам итә. Дөрес, Европа илләре бары сыйфатлы химикатлар гына куллана. Моны тикшереп торучы махсус оешмалар бар. Ә арзанлы чимал артыннан куучы Кытайда, мәсәлән, бал кортлары үлеп беткән диярлек. Бичара кытайлылар хәзер җиләк-җимешне таяк белән серкәләндереп йөри. Тагын әле тирес түгеп, шуңа чебен җибәреп серкәләндерү ысулын кулланалар... Кыскасы, безнең ил җитәкчелеге, шул өлкә өчен җаваплы түрәләр дөрес юлны сайлар, дип өметләник.

Ә без Кама Тамагы районындагы хәлләрне алга таба да күзәтеп барачакбыз. Умартачыларга, көзгә тагын бер килербез, дип вәгъдә бирдек. Шул исәптән җирле җитәкчеләр дә халыкка биргән вәгъдәсен үтәр, дип ышаныйк.

Пестицид һәм агрохимикатларны дөрес куллану буенча Россия Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә рәсми хат юлладык. Һәм түбәндәге җавапны алдык:

– 2011 елның 1 августына кадәр пестицидларны саклау, куллану нормаларын тикшерү һәм контрольдә тоту «Россельхознадзор» һәм аның территориаль бүлекчәләре карамагында булды. Әмма закон актлары нәтиҗәсендә әлеге бурыч бездән алынган иде.

Президент Владимир Путин тарафыннан 2020 елның 30 декабрендәге «Умартачылык турында» 522 нче Федераль закон белән «Пестицид һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү турында»гы 1997 елның 19 июлендәге Федераль законның пестицид һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү өлкәсендә дәүләт контролен камилләштерү өлешенә үзгәрешләр кертелде. Нәтиҗәдә «Россельхознадзор» идарәсе әлеге өлкәне контрольдә тота алачак. Моңа кадәр вәкаләтләр ветеринария өлкәсенә генә карый иде.

Кырларга фитосанитар мониторинг үсемлекләрне химик яклау белгечләре, турыдан-туры авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә эшләүче агрономнар тарафыннан алып барылачак.

Пестицидлар кешеләр һәм бал кортларына куркынычсызлык ягыннан 4 класска бүленә. Беренчесе – үтә куркыныч, икенчесе – югары дәрәҗәдә куркыныч, өченчесе – урта дәрәҗәдә куркыныч, дүртенчесе – аз дәрәҗәдә куркыныч. Заманча пестицидлар, нигездә, өченче, дүртенче дәрәҗәдә куркыныч санала. Әмма авыл хуҗалыгында барлык класска караган пестицидлар да кулланыла ала. Тик беренче, икенче класслылары белән бары махсус әзерлек узган кеше генә эшләргә тиеш. Нинди химикатлар белән эшкәртеләсе исә, кырларга фитосанитар мониторинг үткәргәннән соң, регламентка карап хәл ителә.

СанПиН 1.2.2584-10ның 2.21 пунктына ярашлы рәвештә, пестицидлар һәр конкрет очракта тиешле тәртиптә расланган тәкъдим нигезендә, шулай ук РФ территориясендә рөхсәт ителә торган пестицид һәм агрохимикатларның Дәүләт каталогына туры китереп кулланылырга тиеш. Әлеге Каталогта пестидицлар турында бар мәгълүмат күрсәтелгән. Һәм Каталогта күрсәтелгән нормадан ул берничек тә артырга тиеш түгел.

Авыл хуҗалыгында пестицид һәм агрохимикатлар фәкать авыл хуҗалыгы тармагын (чәчүлек җирләре, җитештерү биналары) ныклап тикшергәннән соң гына кулланыла ала.

1997 елның 19 июлендә кабул ителгән «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән куркынычсыз эш итү турында»гы 109 нчы Федераль законга таянып, пестицидлар фитосанитария, санитария һәм экологик вазгыятьне исәпкә алып кулланылырга тиеш.

P.S. Без шулай ук рәсми хатны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары минисртлыгына да юллаган идек. Алар үз чиратында Россия Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә куштылар. Шулай ук ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына да чыктык. Биредә исә: «Агуның ничәнче класслысын сибәргә икәнлеген агрофирмалар үзләре карый, без киңәш кенә итә алабыз», – диделәр.

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Иске Пенәгәрдә **НИЧЕК** яшиләр

Марича өчпочмак **НИЧЕК** була

КАЙДА әле һаман каз бастыралар

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

ИТЕК ЭЗЛӘП – ИСКЕ ПЕНӘГӘРГӘ

Авторы:
Алсу Троицкая,
Олеся Бондаревская

Татарстаннан Киров өлкәсенә барып җитү җиңел генә түгел – хәтта ки артык җиңел, дияр идем. Кукмара шәһәре Северный микрорайонының аргы ягындагы басуга килеп чыксаң, ике генә атлыйсы – басуның теге ягында Иске Пенәгәр җәелеп ята. Киров өлкәсенә сәяхәтебез нәкъ шуннан башланды.

КЕМ НӘФИСРӘК – ШУЛ КӨЧЛЕРӘК

Узган гасырның 90 нчы еллар ахырыннан Иске Пенәгәр авылын «Икенче Мәскәү» дип атыйлар. Җирлектә берничә гаилә берьюлы сәүдә белән шөгыльләнә башлый, башкала базарларыннан дефицит товарлар алып кайтып саталар. Тыныч, әмма ныклы адымнар белән, читтән ярдәм көтми генә тормыш шартларын яхшыртырга омтылу – пенәгәрлеләр бүген дә әнә шул гадәткә тугры. Авылда бу тормыш канунын алга сөрүчеләрнең берсе – Иске Пенәгәр авыл җирлеге башлыгы **Минсәрия Фәләхиева.** Авыл җирлеген генә түгел, җирле хатын-кызлар советын да җитәкли әле ханым. Үз чиратында әлеге совет җирлек тормышында җитәкче ролен дә үти икән. Менә, мәсәлән, янгын сүндерү гидрантлары. Бер карасаң, гаилә, ана һәм балачак институтларының иминлеген кайгыртучы

Фото: Александр Ефремов

хатын-кызлар советының мондый көнкүреш мәсьәләсенә нинди кагылышы бар соң, диярсез.

– Без төрле өлкә программаларында катнашабыз. Еш кына андагы шартлар буенча проектны тормышка ашыру өчен авыл халкыннан билгеле бер сумма акча җыярга, яки кешеләрнең бушка ярдәм итәчәген күрсәтергә кирәк, – ди Минсәрия Миңнехәй кызы. – Хатын-кызлар советы аңлату эше алып бара. Ветераннар советы актив рәвештә ярдәмгә килә. Янгын сүндерү гидрантларын куярга акча җыя алдык. Аңа кадәр спорт залын капиталь төзекләндерүне, Бөек Ватан сугышында катнашкан пенәгәрлеләр истәлегенә һәйкәл куюны да шул рәвешле оештырып чыккан идек.

Инфраструктура димәктән, пенәгәрлеләрнең һәм район халкының да иң зур хыялы юллар мәсьәләсенә килеп тоташа. Әмма бу проектлар бик кыйммәткә төшә. Авыл халкын ике тәгәрмәчле тимер атлар коткара. Үзләренә ни печән, ни бензин кирәкми. Һәр яклап файдалы. Нократ Аланында без очраткан һәркемнең дәрт-дәрманы ташып торуның сәбәбе, бәлки, сәламәт тормыш рәвеше алып барудадыр?

САБАН ТУЕ БЕЛӘН СЫНАЛУ

2017 елның июлендә Киров өлкәсе губернаторы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Игорь Васильев үзенең сайлау алды кампаниясе кысаларында Малмыжда район Сабан туенда катнашырга тиеш була. Әмма зур кунак килергә бер көн кала көчле яңгыр коя, Малмыжны су баса яза. Сабан туен зурлап үткәрергә җыенган районда судан иң аз зыян күргән урын Сосновка шәһәрендә генә табыла.

– Мәйданда су җыелып тора иде, әмма артка юл юк – таң әтәчләре белән торып, территорияне киптерергә керештек, – дип искә ала ул тарихи көнне Киров өлкәсе татарлары конгрессы җитәкчесе урынбасары Наил Сәитов (ул вакытта Сосновка авыл җирлеге башлыгы). Июльнең бер көне чын мәгънәсендә сынау көненә әйләнә – һәм авыл җирлеге башлыгы өчен генә дә түгел.

Баксаң, Игорь Васильевның чын Сабан туенда беренче катнашуы икән. Барысы да ниятләгәннән дә яхшырак үтә. Губернатор вазыйфаларын вакытлыча башкаручы бәйрәм кунакларын татар телендә сәламли, ә аннары кайчандыр

Борис Ельцинның Татарстандагы казанышын кабатлый: күзен бәйләп, бер селтәнүдә балчык чүлмәкне челпәрәмә китерә. Халык күңелен яулый ул! Шул ук елның сентябрендә Игорь Васильев Киров өлкәсе губернаторы итеп сайлана.

– Бүген Сабан туе – мәдәниятебезнең визит карточкасы. Бәйрәм графигын Кукмара районы белән килештереп төзибез, Сабан туйлары кисешмәсен: алар – безгә, без аларга кунакка йөрешәбез, – ди Наил Сәитов. – Татарстаннан килгән артистлар чыгышын бездә аеруча яраталар. Биредә халык ТНВ – Планета каналын карый, йолдызлар килсә, тамашачы су кебек агыла. Безнең Сабан туйларына Татарстан йолдызлары мөмкин кадәр ешрак килсен иде дигән өметтә калабыз!

Сүз уңаеннан, биредә дә спортны Татарстандагы кебек үк, бик яраталар. Безнең чемпионнар катнашында көрәш – Сабан туеның аерылгысыз өлеше. Шулай ук Сосновкада инде 8 ел рәттән алкалы хоккей буенча «Татар кубогы» турниры үткәрелә. Мәртәбәле призны кайвакыт безнең Кукмара командасы да откалый...

ТУГАН ТЕЛ ҖИЛКӘННӘРЕ

«Туган тел» – Пенәгәр сабыйларының тел ачылу белән өйрәнә торган беренче татарча шигыре. Башлангыч мәктәптә татар теле һәм әдәбиятына атнасына яртышар сәгать бүленгән, 5-8 нче сыйныфларда – берәр сәгать, 9 нчы сыйныфта – 1 сәгать татар теле һәм әдәбияты дәресе, 10 нчы сыйныфта ике атнага бер мәртәбә укытыла бу фәннәр.

– Бу сәгатьләр котокыч аз, дип уйлыйбыз без, шуңа күрә дә күптөрле дәрестән тыш чаралар оештырабыз. Үзем татар аш-сулары түгәрәген алып барам, милли ризыкларыбызны әзерләү серләренә өйрәтәм. Һәрдаим әдәби һәм музыкаль кичәләр үткәрәбез, мәсәлән, Җәлил һәм Тукайга багышланган чаралар уза. Татар телендә спектакльләр дә уйныйбыз, – ди Иске Пенәгәр мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Раилә Батыркаева. Аның укучылары, татар теле буенча төбәкара һәм халыкара олимпиадаларда катнашып, җиңүгә ирешә. Уртак тырышлык нәтиҗәсе буларак, Иске Пенәгәрдә сабыйлар бишектән үк матур, дөрес телне ишетеп, сеңдереп үсә. Китапханәдә милли гореф-гадәтләрне һәм уен-йолаларны, мәдәният йортындагы ансамбльдә – татар җырларын һәм биюләрен, ә мәчеттә Ислам дине тарихын һәм нигезләрен өйрәнәләр. Өйдә эти-әни, әби-бабай белән бары тик татарча сөйләшәләр. Эшкә күрше Кукмарага урнашалар – анда да халыкның төп өлеше татарча сөйләшә-аралаша бит.

Кайчак дәресләрдә Раилә Батыркаева укучыларга үзенең яраткан әсәреннән – Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестеннан өзекләр укый. «Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлы-

лар гына максатларына ирешә ала. Түземнәр генә бәхеткә лаек». Бу юллар – укытучының иң яраткан цитаталарының берсе.

ИТЕКЛӘР СЕРЕ

Пенәгәрлеләрнең могҗизага тиң бер сыйфаты сокландыра – заманча технологияләр һөҗүме һәм яшәешнең яңа форматларына күчү заманында да алар гореф-гадәтләрне яңадан торгыза белә. Китапханәче Нурисә Богабиева туган якны өйрәнү музее экспонатларын кулына ала. Менә пычракларда аякны юештән саклаган күтәртмәле чабата (табанына агач шакмак беркетеп ясалган), монысы хан заманында каен тузыннан җилемсез-нисез үрелгән тырыс, менә авыл тирәсеннән табылган хәзинә – мамонтның казык теше, болары – каба белән әбекәйләрнең кул җылысын саклаган тастымаллар, күлмәкләр. Аның янында ук Иске Пенәгәрнең дүрт ел фасылында квадрокоптердан төшерелгән фотолары – язгы, җәйге, көзге һәм кышкы гүзәллеге, Пенәгәр газетасы янында Татарстан вакытлы матбугаты да урын алган. Үткәндәгеләргә бүгенге көндә дә урын табыла икән, димәк, хәтер әле яши, сулый дигән сүз. Әбисе гомере буе Иске Пенәгәр китапханәсендә эшләгән Нурисә исә гореф-гадәтләрне саклап кына калмый, ул аларны яңадан торгыза. Берничә ел элек ире белән бергәләп киез итек басу технологиясен үзләштергәннәр. Күмәртәләп саталар. Кечкенә генә итек басу «бригадасы» – кукмаралыларга көндәш!

– Йонны тирә-күрше авыллардан да җыябыз, Башкортостаннан да алып кайтабыз, яки итеккә алыштырабыз. Эшнең бер өлешен башка осталар башкара, безгә эшен бетереп, мичтә киптерәсе генә кала. Көненә 10–15 пар итекне рәхәтләнеп басарга була, – дип сөйли Нурисә. – Йоны сыйфатлы булса, итек уңа, эш тиз бара. Итеккә бары тик карт сарыкларның көзге йоны гына килешә, ул майлы, тыгыз, карасу төстә була, киптергәндә яхшы утыра. Язгы йон исә саргылтрак, сузылучан, бәйләүгә генә бара анысы...

АВЫЛДА МЕҢ ДӘ БЕР КИЧӘ

Китапханә киштәләрендә яңа әдәбият арасында берничә игътибарга лаек басма урын алган. Җирлекнең имамы Зыятдин хәзрәт Нәҗметдинов нәшер иткән зур булмаган тугыз китап турында сүзем. Белеме буенча тарих укытучысы булган Зыятдин Мөхәрләм улы – туган төбәге тарихының чын фанаты. Китапханәдә шулай ук тарихчының үз көндәлекләренә таянып төзелгән, берничә дистә ел эчендә авылда теркәлгән никахларны тасвирлаган җыентыгын да табарга була. Әле биредә бер гасыр дәвамында Нократ Аланы басмаларында Иске Пенәгәр турында язмаларны туплаган брошюра да бар. Имам белән Нурисә ханым сурәткә төшереп алган текстларны Иске Пенәгәрнең өлкән сыйныф укучылары компьютерда җыйган. Нинди файдалы һәм саваплы хезмәт – туган төбәгенең матбугатта макталуына сөенү дә, гаиләң тарихының ил тарихына тыгыз үрелгәнлегенә гаҗәпләнү дә...



1 Иске Пенәгәр узган гасырның 60 нчы елларында.

2 Иске Пенәгәрнең үз язучы Кадыйровасы да бар, әмма Зифа түгел – Альфира. Аның инде ике хикәяләр җыентыгы дөнья күргән. Иҗатын яратучылар чит илләрдә дә бар – Греция, Германия, АКШта да укыйлар аны...

3 Киез итекләр.

Зыятдин Мөхәрләм улының туган якны өйрәнүгә керткән саллы хезмәтенә сокланып, без Иске Пенәгәр мәчетенә юл тотабыз. Монда да безне гаҗәпкә калдырырдай күренешләр байтак – 180 ел элек салынган бинага имам инициативасы белән күптән түгел капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Намаз бүлмәсе, лекцияләр бүлмәсе, ике эш кабинеты, һәм... тагын китапханә. Андагы иң күп укылган китап – Зифа Кадыйрованың «Сөмбел»е.

– Кукмара тарихын өйрәнүче Фәрит Галиев белән бергәләп яңа басма әзерлибез – «Кукмара районындагы диннәр тарихы» дип исемләнгән энциклопедия булачак ул. Мамадыш һәм Малмыж өязләре буенча сакланган барлык метрика кәгазьләрен тупладык. Хәзер мин шуларны

укып, тәрҗемә итәм, – дип сөйләде Зыятдин хәзрәт. – Кызыклы фактлар байтак. Мәсәлән, 1830 елның декабрендә Тимерче авылында 57 кеше дөньяга килгән, 153 кеше үлгән. 108 кешене нибары 12 көн эчендә җирләгәннәр! Фаҗиганең сәбәбе гади – холера алып киткән...

Тагын бер дөнья күрәчәк китапның тышлыгын Зыятдин хәзрәт аеруча горурлык белән күрсәтә. Рәсемдә падишаһ белән Шәһрәзадә әңгәмә кылып утыра. Басма «Иске Пенәгәр авылында мең дә бер кичә» дип исемләнгән. Биредә архив материаллары, газеталарда басылган язмалар урын алачак. Иң мөһиме – авылның аксакаллары сөйләгәннәр. Әкият дисәң дә әкият болары – куркыныч та, мәҗаралы да. Әкият шул, чөнки кайчандыр бабалары шушы хәлләрне баштан кичергәнлегенә бүген берәү дә ышана алмый инде.

РУС МИЛЛӘТЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫСЫ

2019 елның август ае. Самолётта Мәскәүдән Казанга «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына ике команда оча – Көньяк Африка Республикасы һәм Австралия вәкилләре. Славян милләтле яшь егет, очыш сәгатьләрен тизрәк уздырыр өчендерме, Көньяк Африка командасы капитаны белән танышып ала һәм кунакларга инглиз телендә мини-экскурсия үткәрә:

– Менә инде без Татарстан Республикасы өстеннән очабыз, иллюминатордан Идел елгасын күрә аласыз. Идел – Россиянең иң зур елгасы. Татарстан халкының үз туган теле бар. Татар теле. Ул рус теленә бер генә дә охшамаган.

Дәрес башлана. Кунаклар рәхәтләнеп «укытучы» артыннан яңа сүзләр кабатлый:

– Башладык. «Здравствуйте, привет» ничек була? Исәнмесез, сәлам. «Как дела?» –Хәлләр ничек? Ничек җавап бирергә? «Хорошо!» – Әйбәт!

– Яхшы, әле тагын яхшы дип әйтергә була! – дип кушыла берничә рәт арттарак утыручы ир-ат.



4
Зыятдин хәзрәт яңа китапның тышлыгын күрсәтә.

5
Иске Пенәгәрдәге 200 еллык мәчет.

6
Нократ Аланы муниципаль районы башлыгы Андрей Чернов.

Шул тирәдә утырган пассажирлар рәхәтләнеп көлеп җибәрә. Чит ил вәкилләре очкыч трабыннан Татарстан җиренә аяк басканда, Казан аларга инде туган шәһәрләредәй якын булып тоела.

Ә татар теле дәресен оештырган Андрей Чернов Киров өлкәсенә, Нократ Аланы муниципаль районы башлыгы вазыйфаларын башкарырга кайтып китә. Уйламаганда гына уздырылган татар теле дәресенең файдасы тиюенә иманы камил аның:

– Тел – һәр кешегә саф һава кебек үк кирәк әйбер ул. Үз гореф-гадәтләреңне өйрәнүгә сусауны берничек тә тыеп торып булмас. Күпмилләтле районда яшәвемә сөенәм мин – бездә руслар, татарлар, удмуртлар, марилар, чеган-

7
Урта Шөн авыл җирлеге башлыгы Фәнис Ибраһимов.

8
Нократ Аланы оештыру-методика үзәге методисты Регина Гафиева.

Җирлек тарихын өйрәнүчеләр сүзләренә караганда, соңрак Малмыж өязенә керәчәк җирләрдә инде XVII гасырда ук татарлар яшәгән. XX гасырда аларны Киров өлкәсенә һәм Татарстанга бүлгәннәр. Бүген татарларның төп өлеше (барысы якынча 35 мең кеше) өлкәнең көньяк-көнчыгышында – Малмыж, Нократ Аланы шәһәре һәм районында яши, шул исәптән Сосновка шәһәрендә, Иске Пенәгәр, Урта һәм Түбән Шөн, Сосмак, Ямул, Чумачар авылларында).

нәр, украиннар яши... Милли күптөрлелек – безнең район өчен норма ул. Без һәрвакыт уртак тел табабыз. Минем дусларым арасында, мәсәлән, татарлар бик күп.

Идел буеның күптөрле халыкларны һәм мәдәниятләрне тоташтырган күпер булуы белән берәү дә бәхәсләшмәс. Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, диалектлары, хәтта үз кызыксынулары бар. Нократ Аланында гомер сөрүче татарлар да шулай – һәр авылның үз тормышы. Пенәгәрлеләр җитештерү һөнәрләрен үз итсә, Сосмак, Урта һәм Түбән Шөн авылларында халык күбрәк җиргә тартыла. Хезмәт сөючәнлек исә тегеләренә дә, боларына да хас уртак сыйфат.

КАРГАЛАР КИЛДЕ, БОТКА ПЕШЕРДЕ

Май иртәсе. Урта Шөннең беренче этәчләре белән йокыдан торып, бала-чага авылның ике ягына таралыша. Һәр төркемдә авылның үз балалары да, шәһәрдән әби-бабасына кунакка кайткан кызлар-малайлар да җитәрлек. Өй борынча йөреп, алар ярмадыр, шикәр, тоз, май, күкәй, сөттер, конфет, печенье ише тәм-том җыя... Тиз-тиз генә авылны әйләнгәч, Мәдәният йорты каршындагы мәйданга килеп, җыелган байлыкны бер күчкә бушаталар. Әкренләп бирегә өлкәннәр дә агыла башлый. Күчтәнәчсез берәү дә килми – икмәк, бәлеш, бавырсак, коймак, гөбәдия, дисеңме... Кем әйтмешли, хәзинәдә булганның барын чыгаралар. Баянчылар гармун тарта, казаннарда балалар җыйган төрле ярмадан тәмле ботка пешә. Ару гына май да салгач, ботканы бергәләп ашау аеруча күңелле шул. Җыр-бию, уен-көлке тынып тормый. Тамаклар тук, күңелле, җанга рәхәт. Кайчандыр Урта Шөндә ботка пешерергә берьюлы 15әр казан асканнар, дип тә сөйлиләр – авылда бала-чаганың күплеген күр син. Хәзер казаннар да җидәү генә, балалар да күпкә азрак...

– Карга боткасын бәйрәм итүне Урта Шөн татарлары күп еллар элек яңартып җибәрде, – дип аңлата Нократ Аланы районы оештыру-методика үзәге методисты Регина Гафиева. – Кошларның җылы яклардан кайтуына гына бәйле түгел бу. Әйе, нәкъ менә кошлар кайткач яз чын-чынлап үз вазыйфаларына керешә, дип санаганнар. Әмма «Карга боткасы»ның төп мәгънәсе – елның уңышлы килүенә өметләр баглау көне ул. Сабыйларның кулларына тәм-том тоттырганда, авыл халкы бер-берсенә сәламәтлек тели, бергәләп пешергән ботканы авыз иткәндә, уртак хезмәтнең җимешеннән һәркемгә өлеш чыга. Ул ботканың тәмлелеген белсәгез сез!

СОСМАКЛАР БӘЙРӘМ ИТКӘНДӘ

Шат көлү авазлары, мәзәк-көлке, күңелле мәшәкатьләр көн буена сузыла – авылның тәҗрибәле апалары каз өмәсе гөрләтә бүген. Аннары, ак түшкәләрне көянтә очларына элеп, елга юлына тезелә апалар, салкын суда соңгы кабат «коендырып» кайталар – урамда инде кара көз бит. Эшне бетереп кайтуларына өйдә аларны мул табын көтә. Иң башта каз шулпасында пешкән токмачлы кайнар аш чыга, аннан авызда эреп китә торган каз ите белән сыйлыйлар. Соңыннан каз маенда пешерелгән коймак белән чәй эчү мәслихәт. Каз өмәсез татар авылы – авылмыни ул?! Аны Нократ Аланының икенче бер авылында – Сосмакта әле дә элеккечә зурлап үткәрәләр. Сосмаклылар казны күп үстерә. Каз өмәсеннән соң әле берничә көн авыл урамнары, ишегаллары ап-ак кар-

га күмелгән сыман – бала-чага каз мамыгы очырып уйнаганга ул. Йортка байлык һәм тынычлык китерә, имеш.

ЧЫН КЫЙММӘТЛӘР

Урта Шөндә һәр шәхси хуҗалык хәлле, аягында нык басып тора. Нократ Аланында яшәүчеләр табынындагы ит, сөт, эремчек, каймак, яшелчәне Шөн татарлары үз куллары белән булдыра-үстерә.

Җәй уртасына исә Фәнис Ибраһимов плантацияләрендә кыяр өлгерәчәк. Урта Шөн авыл җирлеге башлыгы әнә шундый бизнеска да вакытын таба, якташларын кетердәп торган тәмле кыяр белән кинәндерә.

– Сез әллә бөтенләй йокламыйсызмы? – дип сорыйбыз үзеннән, Фәниснең вазыйфасы болай да бик җаваплы, эшенең күп икәнлеген чамалап.

– Нишләп? Иртәнге 5кә кадәр йокы симертәбез, аннан мал-туарны ашатып-эчертәсе дә – хезмәткә. Өйдәге хуҗалык хатыным кулында. Без инде эшне җайга салган – үсентеләр, кыяр белән биш ел шөгыльләнәбез. Бездә бар халык шулай яши – һәр хуҗалыкта берничә баш сыер, үгез, сарыклар, кош-корт...

Фәнис үзе монда туып-үскән кеше түгел. Тумышы белән Болгардан, Казанда аспирантура тәмамлаган:

– Минем хатынымның туган ягы биредә, беренче тапкыр кайткач та, бик яраттым Урта Шөнне. Биредә заман шаукымыннан бозылмаган милли атмосфера саклана. Чын кыйммәтләр яши – көнкүрештә, диндә, гаиләдә. Нindидер сафлык бар. Мин инде хәзер татарча уйларга өйрәндем. Югыйсә, туган ягымда, Татарстанда яшәгәндә, татар телендә начаррак та сөйләшә идем әле.

АЛГА КУЕЛГАН БУРЫЧ

– У-у-утыр әле яннарыма, ял булсын җанна-а-арыма, – Урта Шөн мәдәният йорты фойесында акустика шундый яхшы ки, җырның сүзләре гимн кебек яңгырый. Гармун моңнарына кушылып, безне «Алтын ай» фольклор ансамбле каршылый.

– Иялэнгән тормыш агымыннан, көнкүреш һәм хезмәттән тыш, кешегә һәрчак аз гына вакытка булса да үзгә тын алу мөмкинлеге кирәк. Ә монда килгәч, без инде гади эшчеләр генә түгел – артистлар, – дип көлә гармунчы Альберт Хәлимов. – Балаларны да татар мәдәниятенә һәм теленә җәлеп итәбез. Язын «Йолдызлар яңгыры» музыкаль фестивален уздырдык. Шуны сиздем: балаларның барысы да диярлек заманча эстрада җырларын башкарырга омтыла. Аңлатсым-күндердем үзләрен – безнекеләр дә начар түгел: әйе, заманча түгел ул җырлар, әмма аларда халык рухы, милләт җаны яши. Иманым камил: рус телен алар барыбер өйрәнәчәк, шуңа өстәп, туган телләрен, татар телен дә белсәләр, халкыбыз яшәячәк.

9
«Алтын ай» фольклор ансамбле.

10
Гармунчы Альберт Хәлимов.

Һәр гаиләдә диярлек әби-бабай бар – шөнлеләргә татар телен сакларга алар да булыша. Әби-бабай оныкларын кечкенәдән өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтә, гореф-гадәтләрне, йолаларыбызны сеңдереп үстерә. Уй-гамәлләреңне, хезмәтеңне намус белән башкар, «Нәселгә тап төшерәсе булма», дип аңлата.

Илебез әнә шул телләр һәм милләтләрнең күптөрлелеге белән уникаль. Без, татарлар, гасырлар дәвамында башка милләт вәкилләре белән дус яшибез. Әмма үз алдыбызга куелган бурыч та зур – мәдәниятебезне һәм телебезне үсеп килүче буынга тапшырасыбыз бар.

БЕР ҖИРНЕҢ ИКЕ ЕЛГАСЫ

Кукмара районыннан Кәркәвеч елгасы ага, Нократ Аланыннан Аллавык юл сала. Ике кече елга, кушылып, Нократка коя... Татарстанның Кукмара районы һәм Киров өлкәсе коньяк-көнчыгышының тарихлары – үткәне һәм бүгенгесе – шундый ук мул сулы тарих елгасына кушыла. T

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ОЛЕГ ТРЕТЬЯКОВТАН МАРИЧА БИЗНЕС-ЛАНЧ

Автор: Татьяна Вафина

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында «Татарстан» журналының редакция кухнясы төрле милләт аш-сулары белән яхшырак танышырга карар кылды. Әлеге тәмле юлда беренче булып мари кухнясы очрады. Һәм юкка гына түгел. Татарстан марилары – иң тәртипле, төгәл халык. «Марича бизнес-ланч көтәчәк – сыйланырга әзерләнә торыгыз», – дип әйткәннәр икән, димәк, шулай булачак та!

Фото: Александр Ефремов

МАРИЧА ТЫЛСЫМ-МОГҖИЗА

Корсак, кашык һәм алъяпкычлар – барысы да тулы әзерлектә. Тик соңгысының кирәге чыкмады – «Татарстан Республикасы мариларының милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Олег Третьяков милли киемдәге ярдәмчеләре белән бергәләп өстәлгә экияттәгедәй тылсымлы ашъяулык җәеп җибәрде, ә анда исә бер-бер артлы иң атаклы мари ашлары пәйда була башлады. Кайнарлар, яңа пешкәннәр. «Татарстанга» исә татып карап, мактый-мактый ашыйсы гына калды. Әле тагын язып та барырга кирәк-мари ашамлыкларының атамалары бик үзенчәлекле шул.

ПОДКОГЫЛЬО

Уң яктан киләбез. Безгә украиннарның эремчек пилмәненә охшаган ризык күз кыса. Тик бу эремчек пилмәне түгел.

– Бу – **подкогыльо,** – ди Олег Александрович, зур пилмәнне урталай бүлеп, эчендәге эремчеген күрсәтә-күрсәтә. – Эчлеге төрле булырга мөмкин – бәрәңге, җиләк яки гөмбә. Болар һәр мари гаиләсендә элек-электән булган нәрсәләр, чөнки халкыбыз һәрвакыт сыер асраган, бәрәңге үстергән, урманда гөмбә, җиләк җыйган.

– Варениклар бит инде! – дип шатлана вегетариан фотографыбыз.

– Подкогыльо! – дип төзәтеп куя аны марилар башлыгы. – Йошкар-Олада хәтта «Подкогыльная» дип аталган ашханә дә бар. Казанда элегрәк «Пельменная»лар булган кебек, хәтерлисезме?

Ничек инде хәтерләмисең ди! Әбҗәлилов урамындагы «Пельменная» ашханәсендә безнең пилмәнле студент яшьлегебез узды. Хәзер яшьлек тә, «Пельменная» да юк...

Сагышлы истәлекләргә чумарга ирек бирмичә, карашны күрше тәлинкәгә юнәлтәбез – анда әлеге дә баягы подкогыльога охшаган, тик кызарып пешкән читләре генә башкарак нindiдер ризык хуш ис тарата.

– Кугече когыльо, – дип аңлата Олег Александрович. – Сезнеңчә бөккән инде. Аларның да эчлеге төрле була. Ит белән, балык, гөмбә, ярма белән дә пешерәләр...

Телеңне йотарлык!

УСПУСМАК ҺӘМ КУЗЫКМАК

Мари табынының сул ягы... татар ашларын хәтерләтә.

– Таныш булыгыз **– кузыкмак!** – ди Олег Александрович, бәрәңге боламыгы кысты-

– Подкогыльо! – дип төзәтеп куя аны марилар башлыгы. – Йошкар-Олада хәтта «Подкогыльная» дип аталган ашханә дә бар. Казанда элегрәк «Пельменная»лар булган кебек, хәтерлисезме?

рылган аппетитлы җәймәләрне камера каршында әйләндергәләп.

– Кыстыбый инде, – күрәсең, безнең фотограф бүген маричадан тәрҗемәче булып эшли.

– Успусмак, – дип күз кыса Татарстанның баш марие, һәрберебезгә өч почмаклы бөккән тоттырып. Анысының татар өчпочмагыннан бердәнбер аермасы – эчлегенә кабак өстәлү.

Тәме исә егылып китәрлек!

– Пәрәмәч! Мари пәрәмәче татар пәрәмәче түгел ул сезгә. Ул ачы камырдан, пешкән бәрәңге, атланмай, каймак, йомырка белән әзерләнә һәм эремчегә күбрәк булырга тиеш. Марилар эремчекне бик ярата.

– Табынның төп бизәге – бәлешме? – дип, уртадагы искиткеч матур булып пешкән, бик тәмлегә дә охшаган таныш түгәрәк ризыкка ымлыйбыз.

– Палыш тышкы яктан татар бәлешен хәтерләтә, – ди аш-су остабыз. – Тик гадәттә эченә ярма (кемгә нинди ошый, катгый кагыйдәсе юк), үрдәк ите һәм һичшиксез кабак салына. Кабаклы эчлек бик йомшак, нәзакәтле килеп чыга.

– Кавун, – дип, фотографыбыз мари телен шәп белүен күрсәтә. – Мин бу сүзне мари авылында ишеттем. Мариларның яраткан яшелчәсе ул, алар бөтен нәрсәгә кабак өсти.

– Әйе, без кавунны яратабыз, – дип җөпли героебыз. – Аннан **кавун немыр** бик тәмле килеп чыга. Кабак боткасы ул.

КОМАН МЕЛНА

Өстәл уртасында аеруча үзенчәлекле ризыклар, башка беркемнекенә дә охшамаган мари ашлары. Тыңлый-тыңлый татып карыйбыз.

– Олма когыльо – арыш оныннан пешерелгән алма бәлеше – чын мари ризыгы, – дип, аны кисәкләргә бүлә Олег Александрович. – Ә монысы – **коман мелна** – төче камырлы кабартма белән эремчектән манный ярмасы һәм йомырка кушып ясалган ике катлы, ә еш кына өч катлы ашамлык. Кайчагында кабартмаларга тары йә солы боткасы, ә кайвакыт эремчек ягыла. Коман мелна табынга куас белән бирелә. Кайбер гаиләләрдә, тимер савытта сөт кайнатып, атланмай өстиләр һәм кабартманы шуңа манып ашыйлар.

Шәңгәләр туган көннәргә, юбилейларга, туйларга – барлык бәйрәмнәргә пешерелә. Шәңгәләр бәрәңге яки эремчек белән була.

Ә менә, рәхим итегез, марича балык – **Күктымө кол.** Эченә кишерле суган тутырылган. «Татарстан» журналы өчен Чулманнан махсус тотылган балык бу.

Десертка «Марий чон» концерты «бирелде».


[illegible]

Добрый день, уважаемые марийцы Республики Татарстан!
С приходом весны красное солнце обогревает сердце каждого из нас, дает силу, и уверенность, надежду на светлое будущее.
Будьте здоровы, оставайтесь [illegible] активными, жизнерадостными, [illegible] «Республика Татарстан» [illegible] в этом
Председатель [illegible]

Марича бизнес-ланчның төзүче-авторлары.

МАРИЙ ЧОН

Марилар «татарстанлыларны» Халыклар дуслыгы йортында сыйлады. Десертка исә «Марий чон» концерты бирелде. «Озан Мари» ансамбле җыр белән дә кунакларның күңелен күтәрде, үзләренең данлыклы» сигезле» биюен дә күрсәтте. «Марий чонның» мари рухы дип тәрҗемә ителүе һич тә юкка түгел.

«Татарстанда мари халкы ничек көн күрә?» дигән сорау Олег Александровичны елмаерга мәҗбүр итә:

– Без бит монда борын-борыннан яшибез. Шәхсән үзем Әгерҗе районының Күләгәш авылында гомер кичерәм. Минем әти-әнием дә шунда яшәде, һәм җиде буынгача барлык ата-бабаларым шунда туып-үскән. Татар тарихын карагыз – ул тарих марилардан башка була алмый да. Тарихчы Альберт Халиков 10–15 мең ел элек кабиләләрнең чал Урал тауларыннан төшүе турында язган иде. Һәм алар монда да, тегендә дә урнашып кала. Болар – фин-угыр кабиләләре: арлар (вотяклар), чирмешләр, болгарлар... Татар халкының борынгы бабалары – болгарлар, мариларныкы – чирмешләр, удмуртларныкы – арлар. Без элек-электән монда тату яшәгәнбез.

МАРИ ИСЕМНӘРЕ

Хатын-кызлар: Эрви, Саскави, Шәрви, Салика, Чачави, Айвика, Чинчавей, Санды, Йэнай, Пикэнай, Сэйлан, Уоснай.
Ир-атлар: Эчан, Онтон, Изэрге, Кугэрге, Чолпан, Чокай.

КУШТАЛТЫМАШ

– Чирмеш марилар нинди ул? Үз халкыгызны ничегрәк тасвирлап бирә аласыз?

– Сугышчылар алар. Чирмешләр һәрвакыт оста сугышчы була. Чирмеш гаскәрләре болгар ханнарына да, Казан ханлыгы чорында да хезмәт итә. 1552 елда чирмеш гаскәрләре Казанны яклый. Бүген без бии торган «сигезлене» дә чын мари хәрби сәнгате дип атыйлар. Бу сезгә сәхнәдәге шырдый-бырдый гына бию түгел. Чирмеш сугышчылары **«кандыра»** – «сигезле» биюен, үкчәгә баса-баса, сигезәр-унар сәгать бии алган һәм ару-талу белмәгән. Ә хәзерге спортчыларга карагыз әле! Әйтик, боксчыларга! Алар берничә минут бокслашып ала да рәтләре бетә, тизрәк почмакка чүгәли. Чыдамыйлар. Ә чирмешләр волынка көенә менә шулай, кара-каршы килеп бии... – Олег Александрович үкчәләрен шакылдата-шакылдата биеп җибәрә... – Һәм каршыдагы дошман чирмешнең киләсе хәрәкәте нинди булачагын аңлый алмый аптырап калган. Әллә уңга борылачак, әллә сулга китәчәк... Сугышчан хәйләкәрлегебез әнә шуннан гыйбарәт булган.

Мариның «хәрби хәйләкәрлеге» фотоаппаратка һөҗүмгә күчте һәм камера хуҗасының башын әйләндереп алды. Олег Третьяков һәм «Татарстан» журналы фотографы Александр Ефремов башкаруындагы дәртле «кандыра» «сигезлесен» protatarstan.ru сайтыннан карагыз.

АВЫЛ ЯШӘСӘ, ТЕЛ ДӘ ЯШИ

Саубуллашкан арада Татарстан марилары мохтарияте төбәк иҗтимагый бүлеге рәисе мариларның туган телләрен ничек саклавы турында да сөйләде.

– Туганда ук безгә бирелгән ана теле ул. Без үзара шул телдә сөйләшәбез, җырлыйбыз. Беркем дә, беркайдан да килеп, махсус өйрәтми. Һәр авылның үз диалекты бар һәм, авыллар яшәгәндә, алар сакланачак. Авыл яшәсә, тел дә яши. Ә зур шәһәрләргә китәбез икән, тел югала, юкка чыга, мәдәни мохиттә эреп бетә. Зур шәһәрдә телне һәм гореф-гадәтләрне саклап калу бик авыр. Әмма шулай да без тырышабыз. Ә мариларның элекке исемнәре нинди матур! Мәгънәле дә алар, өстәвенә, авазлар шундый ярашкан, җырлап тора: Саскави, Чачави, Извай, Айвика, Эрвика кебек... Боларны югалтырга ярамый, авылларда моны яшәтәләр әле, буыннан-буынга күчерә-күчерә саклыйлар. Тел – безне үткәнебез, ата-бабаларыбыз, хәтер белән бәйли торган нәрсә, һәм ул безне хәзерге көндә бергә яшәтеп, халкыбызның киләчәктә үсешенә өмет бирә. Дөньяда халыклар күп, һәркемнең үз тарихы һәм һәркайсы үзенчәлекле, кызыклы һәм тиңдәшсез – нәкъ менә бүгенгә табыныбыз кебек. Килешәсезме? Шулай булмыйча соң!

МАРИ АШЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ

ПОДКОГЫЛЬО – ЭРЕМЧЕК ЯКИ БӘРӘҢГЕ, ГӨМБӘ ЯИСӘ ҖИЛӘК ЭЧЛЕКЛЕ ПИЛМӘН.

КУГЕЧЕ КОГЫЛЬО – ИТЛЕ-ЯРМАЛЫ БӨККӘН.

КИЗЫКМАК – ЭЧЕНӘ БӘРӘҢГЕ БОЛАМЫГЫ КЫСТЫРЫЛГАН ТӨЧЕ КАБАРТМА.

ОЛМА КОГЫЛЬО – АРЫШ ОНЫННАН АЛМА БӘЛЕШЕ.

ПЭРЭМЕЧ – БӘРӘҢГЕ, АТЛАНМАЙ, КАЙМАК, ЭРЕМЧЕК, ЙОМЫРКА ҺӘМ ШИКӘРЛЕ ЭЧЛЕК САЛЫНГАН КАБАРТМА.

КОМАН МЕЛНА – МАННЫЙ ЯРМАСЫ БЕЛӘН ТӨЧЕ КАМЫРДАН ӨЧ КАТЛЫ БӘЛЕШ.

УСПУСМАК – ЭЧЛЕГЕНӘ ИТ, БӘРӘҢГЕ ҺӘМ КАБАК САЛЫНГАН ӨЧ ПОЧМАКЛЫ БӨККӘН.

ШАНЕЖКИ – БӘРӘҢГЕ ЯКИ ЭРЕМЧЕКЛЕ КАБАРТМА.

ПАЛЫШ – ЭЧЕНӘ ЯРМА, ҮРДӘК ИТЕ ҺӘМ КАБАК САЛЫНГАН ТҮГӘРӘК БӘЛЕШ.

1 Подкогыльо

2 Кугече когыльо

3 Кизыкмак

4 Успусмак

5 Палыш

6 Олма когыльо

7 Кӱктымӧ кол



«Васильевский» шифаханәсе – саулык чишмәсе

Шәһәр ыгы-зыгысыннан һәм тупланган стресстан туйдыгызмы? Саулыкны кыска вакыт эчендә ничек ныгытып булуны белмисезме? Буш вакытыгызны гаиләгез белән файдалы үткәрегез! «Васильевский» шифаханәсендә. Бернинди ыгы-зыгысыз, саф табигать һәм ихлас кайгыртучанлык мохитендә.

Инде менә бер гасыр буе Казаннан кул сузымында гына дәвалау дәрәҗәсе буенча Европадагы атаклы курортлардан бер дә калышмый торган шифаханә эшли.

Шифалы гаилә ялы тәкъдим итә торган курорт әүвәлгечә үк табигый минераль суы, саллы дәвалау-диагностика базасы һәм гасырлык традицияләре белән данлыклы. Биредә нарат ылысы исе белән сугарылган һава, табигать үзе дәвалый. Хәзерге «Васильевский» территориясе 50 гектарга якын мәйданлы парктан гыйбарәт, аның үзәгендә исә табигый күл урнашкан. Болар барысы да шифаханә белгечләренә төрле авыруларны нәтиҗәле дәвалау мөмкинлеген бирә. Шифаханәнең Бөтенроссия форум һәм конкурсларында ел саен төрле номинацияләрдә диплом һәм медальләр алуы тикмәгә генә түгел.

Иң мөһиме – дәвалау

Бүген биредә күп кенә заманча сәламәтләндерү программалары гамәлгә ашырыла. Шулардан берсе – авыруларны инфаркттан соң тернәкләндерү системасы. Аларны шифаханә капкасы төбенә реанимация машиналары алып килгән очраклар да сирәк түгел. «Васильевский»ның андый кунакларына хәтта җәяү йөрү күләме дә чикләнгән була – көненә нибары берничә адым гына ясарга мөмкин. Дистәләрчә ел дәвамында тупланган дәвалау тәҗрибәсе шифаханә белгечләренә мондый авыруларны тулы канлы тормышка кайтарырга мөмкинлек бирә.

Онлайн ярдәмгә килә

Интернет үсеше шифаханәнең дә мөмкинлекләрен киңәйткән. Төрле профильдәге табибларның консилиумнары, дәвалау эшендә Казанның медицина кафедралары хезмәткәрләреннән консультацияләр алу, алдынгы белгеч-табибларга күренү, киңәшмәләр уздыру – боларның барысын да бүген шәхсән күрешеп тә, онлайн режимда да үткәрергә була.

Карловы Варыдагы кебек, тик якынрак

Шифаханәнең үз чишмәләреннән алынган, составында йод һәм бром булган югары концентрацияле эремәләр йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системаларына яхшы йогынты ясый, умыртка баганасы авырулары вакытында нәтиҗәле дәвалый. Бальнеопроцедуралар өчен кулланыла торган җирле су үзенең химик составы ягыннан атаклы Карловы Вары һәм Усть-Качка курортларындагы йод-бромлы эремәләрнең аналогы булып тора. 2 нче скважинаның минераль суы составы белән Трусковец курортындагы «София» чишмәсе, шулай ук «Новоижевская» чыганагы сулары белән бер үк төрле. Әлеге минераль суны, барыннан да элек, ашказаны-эчәк трактлары авырулары вакытында кулланы киңәш итәлә.

«Васильевский» кунакларына диагностик тикшеренүләр, ләм белән

Фото: Санаторий «Васильевский». Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

дәвалау, гидромассаж һәм радонлы дәвалау ванналары, сөлек дәвасы, углекислый газлы коры ванналар, спелеотерапия, төрле массаж төрләре, магнит һәм озон терапиясе, җылылык белән дәвалау һ.б. тәкъдим ителә.

Коронавирус кичергәннән соң тернәкләнү программасы да ял итүчеләр арасында бик популяр.

МОННАН ТЫШ

Хатын-кызлар югары квалификацияле, өстәвенә, бәя ягыннан кесәгә сукмый торган косметологияне ошатмый калмас. Шифаханәнең үз стоматология кабинеты да эшли.

«Васильевский» алга куелган теләсә нинди бурычны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирә торган заманча медицина аппаратурасы белән җиһазландырылган.

МАТУР ХИС-КИЧЕРЕШЛӘР

«Васильевский» шифаханәсе – дәвалану гына түгел ул. Бу тараф иң мөһиме булса да, бердәнбер максат дип әйтеп булмый. Кайбер кунаклар бирегә... ял итәргә, туйганчы йокларга, саф һавада йөрергә, спорт һәм күңел ачу чараларында катнашырга дип кенә килә. Алты кунакханә базасында корылган шифаханә инфраструктурасы, сауналы һәм бассейнлы ләм-су белән дәвалау бүлмәләре, ресторан һәм ял итү үзәге теләгегезгә ирешергә мөмкинлек бирәчәгенә шикләнмәгез! Ә яхшы хис-кичерешләрнең үзе үк дәва икәне күптән расланган нәрсә. Шифаханә берьюлы 500 дән артык кешене кабул итә ала.

РИЗЫК ТА ДӘВАЛЫЙ

Шифаханәдә туклану «швед өстәле» системасы белән һәм заказлы меню рәвешендә оештырылган. Табиб күрсәтмәләре нигезендә пациентларга махсус диетик ризык әзерләнә, хәләл меню яки вегетариан ризыклар да сорап алырга мөмкин. Ял итүчеләр табынында – һәрвакыт төрледән-төрле ризык, җиләк-җимеш һәм яшелчә.

ҮСЕШ ПЛАННАРЫ

Санаторий-профилакторийның баш табибы, «Сәламәтлек саклауны оештыру һәм җәмгыять саулыгы» белгечлеге буенча югары квалификация категориясенә ия Роберт Муллабаев җитәкчелегендәге медицина персоналының бай тәҗрибәсе шифаханәдә дәвалануны нәтиҗәле генә түгел, ә җанга һәм тәнгә рәхәт итеп оештырырга юл ача.

Санаторийның дәва төрләре исемлегендә ел саен берничә яңа процедура барлыкка килә. Бу исә-яңа табиблар, яңа кабинетлар һәм эш урыннары кирәк дигән сүз. Хәзерге көндә дәвалау корпусының беренче катын тулысынча су белән дәвалауга бирү планлаштырыла. Баш табибның тагын бер зур проекты – тулы циклдагы спа-үзәк төзү.

«Васильевский» шифаханәсе һәркемгә сыйфатлы дәва һәм сәламәтләнү процедураларын гарантияли. Нибары ун көн эчендә өйгә сафланып, яңа көч туплап кайтырга мөмкинлек бирә торган урын ул...

АЗ-МАЗ ТАРИХ

Төрле елларда шифаханәдә Муса Җәлил, Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Туфан булып китә. Табигатьнең нәкъ менә шушы почмагы аларга илһам биргән дип санала. Бөек Ватан сугышы елларында монда эвакуация госпитале урнаштырыла, анда фронттан яралыларны кабул итәләр. Дөрес, яу кырыннан кайтарылганнарның барысы да аякка баса алмаган, араларында Васильеводa мәңгегә ятып калганнары да бар – алар туганнар каберлегендә җирләнгән. Кемдер тернәкләнеп, яңадан фронтка юл тота, кемдер өенә кайта. Йөзләгән гомерне саклап калган хәрби табиблар истәлегенә, санаторийның 100 еллыгы уңаеннан, аның территориясендә көзен зур матур парк ачылачак.

САУ-СӘЛАМӘТ БУЛЫГЫЗ!

100 еллыгын билгеләп үткән әлеге көннәрдә »Васильевский» шифаханәсе коллективы җитәкчеләре, санаторийның баш табибы Роберт Муллабаевны 50 яшьлек юбилее белән чын күңелдән тәбрик итә:

– Хөрмәтле Роберт Фаяз улы! Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлап, һәрчак шундый зирәк һәм сизгер җитәкче булып калуыгызны телибез. Тормышыгыз күңелле вакыйгалар, шатлыклы очрашулар һәм өметле проектлар белән тулып торсын. Булганнарны арттырып яшәргә, кайчак ял итү өчен дә вакыт табарга насыйп булсын! Һәм, билгеле инде, кешеләрне сәламәтләндерү өлкәсендә күп еллар хезмәт куеп, иң мөһим байлык – сәламәтлек икәнен сез һәркемнән яхшырак беләсез. Шуңа да иң зур теләгебез – сәламәт булыгыз!

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



ЯКТЫ ШӘХЕС

Рафаэль Мостафин дигәч, минем өчен идеалга якын әдип образы күз алдына килә. Болай уйлаучылар бер мин генә түгел, алар байтактыр. Бу затны сыйфатлар өчен күп эпитетлар тезәргә мөмкин: кешелекле, зыялы, талантлы, гыйлемле... Якты күңелле шәхестән кешеләргә нинди дер җылы нур бөркелә иде...

Автор:
Равил Фәйзуллин,
Татарстанның
халык шагыйре

Үткән гасырның 60 нчы елларында Рафаэль Мостафинга, татар интеллигенциясе яшь буынының күркәм бер вәкиле буларак, өлкән әдипләр аңа зур ышаныч баглады-лар, студент яшьләр аңа охшарга тырыштылар. Аңлап та була: гали мәдрәсәләрдә тәрбияләнгән укымышлы катлам инкыйлаб чорында, шәхес культы һәм сугыш елларында бик нык кырылды. Рухи-мәдәни мәйдан бушап калды. Рафаэль Мостафин «җепшеклек» чоры тудырган сирәк һәм зирәк зыялыларның берсе булды.

Казан университетының рус әдәбияты бүлегендә укыган, татар әдәбияты кафедрасында аспирантура тәмамлаган яшь әдәбият галименең дәрәҗәсе ифрат зур иде ул елларда. Хәзерге татар әдәбиятындагы хәлләрне дөнья әдәбиятында барган хәрәкәт белән бәйле рәвештә өйрәнде һәм бәһаләде ул. Аның әдәбиятыбыздагы актуаль проблемаларны яктырткан үткен һәм үтемле мәкаләләре, чыгышлары җирле һәм үзәк матбугатта еш басылды, әдәби җәмәгатьчелек даирәсендә зур резонанс тудырды. Ул елларда татар әдәбияты үсешендә азмы-күпме өлеш керткән әдипләребезнең төп әсәрләре аның күз уңыннан читтә калмады шикелле. Кайберләрен генә искә алып узыйк: С.Хәким иҗаты турында махсус монография (ул хезмәт рус телендә Мәскәүдә аерым китап булып та чыкты), Х.Туфан, Ә.Еники, Г. Әпсәләмов, Ф.Хөсни, М.Әмир, М.Юныс, Ш.Галиев, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин турында күләмле иҗат портретлары... Соңрак ул хезмәтләр «Силуэты: литературные портреты писателей Татарстана» дигән китапта туплап бирелде. 2006 елда чыккан бу җыентык авторның исән чагында дөнья күргән соңгы китапларыннан берсе булды.

Рафаэль Мостафин – күпкырлы талант иясе: тәнкыйтьче-галим, публицист, эссечы, сәясәтче һәм сәяхәтче... Әдип-гражданин буларак, яшәешебездәге күп нәрсәләр аның игътибары үзәгендә булды. Туган якны, бигрәк тә борынгы Казанны өйрәнү буенча да аның саллы хезмәтләре бар. Чыккан китапларының исемнәрен генә искә алыйк: «Кабан күле серләре», «И Казан, серле Казан», «Казань и ее слободы» һ. б.

Шулай да, Рафаэль Мостафин гомеренең төп күп өлешен Муса Җәлилгә багышлады, дип әйтсәк тә ялгышмабыз. Герой-шагыйрьне киң дөньяга танытуда иң күп көч куйган кеше Рафаэль абый Мостафин булды дип беләм. Җәлилне, данлап, бүтән халык-кавемнәр алдында татар халкының дәрәҗәсен күтәрде, күпләрне рухи турайтты. Бу очракта аның күпсанлы хезмәтләрен санап үтү хаҗәте дә юктыр. Алар һәммәбезгә мәгълүм.

Шулай да аның бер хезмәтен аерым атап үтәр идем: ул – «Өзелгән җыр эзеннән» («По следам оборванной песни») дип исемләнгән китап. Төрле елларда рус һәм татар телләрендә ярты миллионга якын тираж белән чыккан. 2006 елда бу китабы өчен Рафаэль Мостафин Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Заманында М.Җәлил исемендәге кораб диңгез-океаннар гизгән искән, бүген бортына «Җәлил» дип язылган зур самолет-авиалайнер күкләрне иңләп оча икән, шагыйрь рухы матдиләшкән бу гамәлләрдә Р.Мостафинның да өлеше зур, дип исәплим.

Зур чын язучы, гадәттә, менә дигән журналист та ул. Аларны хәтта аерымлау да кыен. Безнең язучыларның байтагы, төрле газета-журнал редакцияләрендә эшләп, зур тәҗрибә туплаган кешеләр. Бүген дә дистәләгән язучыларыбыз төрле басмаларда җаваплы мөхәррир яки бүлек хезмәткәрләре булып эшли. Алар арасында Рафаэль абый Мостафин, һичшиксез, өлге-үрнәк булырлык. Ике телдә – татар һәм рус телләрендә иҗат итте (андыйлар хәзер юк ши-

келле). Журналист буларак та, язучы буларак та һәрвакыт югары профессионал дәрәҗәдә булды. Шуңа күрә дә, үз вакытында республиканың ике төп журналлары («Казан утлары», «Татарстан») белән җитәкчелек итә алды да. Рафаэль Мостафин турында сөйләгәндә тагын шуны да әйтергә кирәк: әсәрләренең барысы да диярлек – документаль әсәрләр. Чын вакыйгалар, төгәл фактлар, конкрет кешеләр. Кабинетта утырып ярым уйдырма язмалар оештыру бер нәрсә, ә архивларда эзләнеп, кеше язмышларының асылын ачыклап, белгән-тапканыңны бүтәннәргә җиткерү – бөтенләй икенче нәрсә. Минемчә, хәзерге заман әсәрләре, нигездә, документаль булырга тиеш. Хәер, бу хакта Л.Толстой кебек бөекләр дә әйтеп калдырган инде. Бу уңайдан Рафаэль Мостафинның репрессиягә эләккән язучыларга багышланган, татарча, русча, инглиз телләрендә чыккан «Һәммәсен исемләп искә алыйк» дигән китабы аеруча гыйбрәтле һәм әһәмиятле.

Әдип турындагы биобиблиографик белешмәләргә яки юбилейлар уңае белән язылган мәкаләләргә карап, аның тормыш һәм иҗат юлы эзлекле рәвештә гел өскә үрләгән, бәхетле язмышлы булган икән, дигән уй да килергә мөмкин. Болай уйлау да дөреслеккә туры килә үзе. Ул – күпсанлы укучыларын тапкан зур әдип. Димәк, бәхетле язучы. Әмма партия диктатурасы чорында аның җитәкче даирәләр тарафыннан гаделсез рәвештә рәнҗетелгән, тибәрелгән чаклары да яхшы ук хәтердә әле. Бер генә мисал: Татарстан язучыларның 1968 елда узган VII съездында Рафаэль Мостафинның чыгышына югарыдагыларның реакциясе. Аның чыгышының төп бер тезисы шул: 1913 елда татар китаплары сан буенча хәзергедән күбрәк чыккан. XIX йөз ахырында Казанда 15 басмаханә эшләгән, аларда русча китаплар белән беррәттән татар телендә дә 140–180 исемдә китап нәшер ителгән (гомуми тиражы 1,5–2 млн!). Әдәбият әһелләре арасында сөйкемле сөяк саналган, русча-татарча иркен сөйләшә һәм яза алган дәрәҗәле Рафаэль Мостафинның бу чыгышы партия түрәләре өчен һич тә көтелмәгән хәл булды. Ничек инде революциягә кадәр шулай булырга тиеш ди? Әнә бит республика җитәкчеләреннән берсе, «татарлар революциягә кадәр тоташ грамотасыз булган», дип бара! Нинди каршылык! Дөресрәге, партия линиясенә каршылык!.. Бу чыгышка рәсми реакция катгый булды: бер айдан Рафаэль Мостафин «Казан утлары» журналы баш мөхәррире вазыйфасыннан азат ителә...

Сүземнең башында Рафаэль абыйны «минем өчен идеалга якын әдип» дип атадым. Болай диюемнең нигез-сәбәбе шунда: ул миңа гомере буе яхшы мөнәсәбәттә булды, өлкән әдип һәм остаз сыйфатында гомере буе теге яки бу рәвештә ярдәм итте. Әдип 80 елга якын гомер кичерде. Шуның 50 ләп елында миңа аның белән якыннан аралашып яшәргә, иҗат итәргә туры килде. Язмышка рәхмәт! Ничектер, беренче әдәби адымнар ясаганда ук игътибар итте ул миңа. 60 нчы еллар башында шигырьләремне рус телендә Татарстанда һәм Үзәк матбугатта («Литературная газета», «Литература и жизнь») бастыруга ярдәм итте һәм алар турында язып та чыкты. 1965 елны төп әдәби журналыбызда «Нюанслар иле» дип аталган кыска шигырьләрне зур итеп бастырып чыгаруы, ул вакытта баш редактор булып эшләгән Рафаэль Мостафинның зур кыюлыгы һәм тәвәккәллеге иде. Кемнәргәдер ошады ул 3–4 юллыклар, кемнәрдер каршы чыкты, әмма шау-шуы хәйран булды, һәм бу хәл минем язганнарыма күпләрнең игътибарын юнәлтте. Кирәк вакытта сузылган ярдәм кулы гомергә онытылмый ул!

Үткән гасырның, 60 нчы еллары уртасында (әле студент чак) миңа «Казан утлары»ның төрле бүлекләрендә вакытлыча эшләп алырга туры килде. Нәкъ шул вакытта – 1965 елда журналыбыз «Совет әдәбияты»ннан (шул ук исемдә Төрекмәнстанда да әдәби журнал чыга иде, язылу вакытында СССРның бүтән өлкәләрендә буталыш-аңлашылмаучанлыклар да килеп чыга иде) «Казан утлары»на әйләнде. Менә шушы күчеш чорында бу яңалыкны бөтен ил буенча таралган әбүнәчеләребезгә җиткерү эшен ул миңа йөкләде. Хәлне аңлатып, илнең төрле төбәк җитәкчеләренә, СССРдагы барлык өлкәләрнең рәсми газеталарына 150 ләп махсус хатлар җибәрелде. Редакциянең бөтен коллективы белән бергәләп эшләгәч, ахыр чиктә, яхшы нәтиҗәгә дә ирешелде: ел ярым эчендә тиражыбыз 25 меңнән 60 меңгә җитте! Безнең бүгенге хәлләрне искә алганда – фантастика! Әгәр баш редакторның оештыру сәләте, алдан күрүчәнлеге, стратегик зур максатлары булмаса, мондый нәтиҗәгә ирешелер иде микән?

Әйе, Рафаэль абый минем остазым. Шунысы да кызык: тормышымның кайбер этапларында аның үткән юлы күпмедер кабатланылды да. 60 нчы еллар ахырында Рафаэль абый Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы секретарь (рәис урынбасары) булып эшләгән иде, 4–5 ел үткәч, миңа да бу вазыйфаны башкарырга туры килде; бер заман ул «Казан утлары» журналының баш редакторы булды, соңрак миңа да бу журналның җитәкчесе булып 25 елга якын хезмәт куярга язды... Традицияләрнең дәвам итүе, буыннар чылбырының өзелмәве, киресенчә, ныгуы түгелме соң бу?

Бездә теге яки бу шәхес турында, кагыйдә буларак, юбилей елларында мәкаләләр язу, кичәләр үткәрү, радио-телетапшырулар язды-ру-төшерү гадәткә кергән. Бу хәл аңлашыла һәм аклана да шикелле. Шулай да, әгәр зур шәхесләрнең хезмәтләре киләчәкне кайгыртуга юнәлтелгән булса, аларны һәрдаим истә тоту лязем. Бу очракта сүз чын әдипләр, чын журналистлар турында бара. Җәмгыятебездә иман һәм әхлак какшаган заманда аларның мирасы безгә нык рухи терәк була ала.

Язманың видеоварианты да бар

Автор: Руфия Фазылова

КАЗЛАРДА ДА АККОШ МӘХӘББӘТЕ

«Татарстан» журналы халкыбызның ата-бабадан килгән затлы һөнәрләрен, шөгыльләрен барлауны дәвам итә. Бу юлы без Тәтеш районының Кече Әтрәч авылында булдык. Бирегә гыйбрәтле язмыш юлы узган Римә апа Гафиятуллина яши. Сиксән бер яшендәге бик тырыш бу апа 14 каз (!) асрый – җидесе ана, җидесе ата. Шулкадәр казны ул бәбкә бастырып чыгару өчен махсус тота. Гомер буе каз асраган әби әлеге шөгыльнең барлык нечкәлекләре турында сөйләде.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

«СУКЫР ӘБИ БЕЛӘН ҮСТЕМ»

Казларны Римә апа өйгә алып кергән. Берьюлы бишесе бәбкә чыгарырга утыргaн. Ә калган ике ана каз әле йомырка сала гына икән. Аларын соңрак утыртачак.

– Римә апа, хәзерге казлар бик басмый, сезнекеләр ничек барысы да бәбкә чыгара? – дим.

– Моның төре шундый, әби заманыннан ук калган. Хәзерге казлар инкубаторда чыга бит. Шуңа да басмыйлар.

– Ә сезнең казларның төре нинди?

– Белмим дә инде. Кара каз дип кенә йөртәбез.

Римә апа башта үз язмышы турында сөйләде. Әти-әнисез үскән ятим бала икән. Алты яшендә йон тетә торган машина астына кергән. Сукыр әбисе аны шуннан сөйрәп чыгарган. Нәтиҗәдә бер як битендә җәрәхәт эзләре калган...

– Әтием сугышта үлгән, – диде Римә апа. – Әни кияүгә чыгып киткән. Мине әтинең сукыр апасы тәрбиягә алган. Кечкенәдән аны җитәкләп йөргәнемне хәтерлим. Әбием бик тырыш иде, гомер буе сыер асрады, кош-корт тотты. Начар яшәдек, дия алмыйм. Ирле хатыннар да бездән бурычка акча алып тора иде.

Римә апа сөйли, ә мин гаҗәпләнәм – язмыш аны күпме сынаган, ә ул ник бер сукранып карасын! Сүз саен: «Аллаһка шөкер», – ди. Ә бит гомер буе битендәге җәрәхәт эзе белән яшәү җиңел булмагандыр. Ни дисәң дә кыз бала, кыенсыну, кимсенү бар. Әллә Римә апа ул вакытларны оныткан, әллә чынлап та аңа исе китмәгән, һәрхәлдә, безгә сер бирмәде.

– Мин гел хезмәттә булдым, – диде ул. – Шуннан рәхәтлек алдым. Әбием кечкенәдән бар эшкә өйрәтте. Аның белән көтүдән сыер каршыларга барганыбызны, каз бәбкәләре саклауны әле дә сагынып искә алам. Кул арасына керә башлагач, чәй кайнату, аш пешерү кебек эшләрне үзем башкардым. Әби миңа карата бик мәрхәмәтле булды. Сиксән дүрт яшенә кадәр яшәде, тәрбияләп, соңгы юлга озаттым. Урыны оҗмахта булсын, мин аннан бик риза. Әле ярый әни үзе белән алып китмәгән дим, кайларда үскән булыр идем. Язмышыма рәхмәтлемен. Алма

Фото: Лилиана Вәлитова

кебек матур, акыллы ул белән кыз үстердем. Кызым да авылда гына яши, көн саен килә. Киленем дә әйбәт, оныклар «әби» дип кенә тора. Шулай булгач, ничек язмыштан зарланырга кирәк?!

«АДӘМГӘ ОХШАТАМ»

Әле мин дә сәке астында каз басып утырганын хәтерлим. Ешрак бу хәл апрель башларына туры килә иде. Нәтиҗәдә, беренче яшел чирәм белән йомыркадан бәбкәләр дә борын төртә. Без, бала-чага, каз бәбкәсе чыгуын зур түземсезлек белән көтәбез. Ник дигәндә, димәк, тиздән бәбкә сакларга чыгарачаклар. Ә бу инде калын бишмәт өстенә чалкан ятып, тәмле ризыклар ашау дигән сүз. Аннан өйгә бик зур эш башкарган кебек кайтып керәсең... Икенчедән, йомыркадан чыккан яңа бәбкә шулкадәр наный, якын була, әйтерсең, гаиләдә сабый бала туган. Беренче көннәрдә аларны кулда гына күтәреп йөртәсең, туйганчы иснисең, кочасың, сыйпыйсың. Ә алар сиңа җавап итеп: «Пи-пи», – ди. Хикмәт инде. Бер ай эчендә ана каз да гаилә әгъзасына әйләнә. Ул йорттан чыгып киткәч, хәтта күңелсез дә булып кала...

Кече Әтрәчкә баргач әнә шул хатирәләр яңарды. Сыер, ат кебек, ана каз белән ата каз да унар, унбишәр ел яши. Һичшиксез, ул ишек алдының, каралтының күрке иде. Ә хәзер... Хәзер фәкать каз тавышын җәй, көз көннәрендә генә ишетәбез. Шуңа да бүген каз асрау бүтәнчә, кызыгы юк, димме. Әле менә «Әбидә кунакта» проекты өчен ана казы булган кешеләрне эзләп тә, уннан артык районга чыктык. Юк бит, бер генә казлы кешене дә таба алмадык. Бәхеткә, Кече Әтрәчтә бер гаилә бар, дигән хәбәр җиткерделәр. Тырыш кешеләрдер, берьюлы үндүрт каз тотмаслар, дип уйлап барган идек, рас килде. Гафиятуллиннар гаиләсендә бөтен мал дистәләр белән исәпләнә – егерме бер баш савым сыеры, уннан артык үгез-тана, егермегә якын парлы күркә (шулай ук бәбкә чыгару өчен тоталар), ике дистә сарык, берничә ат...

– Малларны балалар карый, минем өстә шушы казлар гына, – ди Римә апа. – Сиксәннән соң дилбегәне аларга бирдем. Салават оныгым бик тырыш, сарыкларны да карый, аппарат белән сыерларны да ул сава.

Казларга күз салам, берсе усалга охшаган – янына бара башласаң, ысылдый. Ә берсе, киресенчә, бик тыныч.

– Менә монысы иң карты, иң акыллысы да, – дип тыныч каз янына чүгәләде әбекәй. – Ә теге ысылдый торганы иң яше. Ата казның да шулай берсе усал, хәтта безне дә таларга килә.

– Ә казларның усал яки тыныч булуы нәрсәгә бәйле? – дим.

– Мин казларны адәм баласына охшатам: аларның да төрлесе бар инде. Югыйсә шул ук ризыкны ашыйлар, тәрбия дә бер үк. Теге усал каз да менә бу тыныч анадан туган. Әйтәм бит, адәмнеке кебек аларның да холкы төрле. Кайберсе бәбкәләрне дә талый.

«БЕР АЙ ДИГӘНДӘ БӘБКӘ ЧЫГА»

Римә апа каз астыннан йомыркаларны алды. Атна-ун көн утыргач, аталанган йомырканы күреп була икән. Моның өчен аны утка гына куеп карарга кирәк.

Кызлар җитезлеге белән әбекәй урындыкка менеп басты да, йомыркаларны бер-бер артлы лампочкага якын китерде.

– Әнә, күрәсезме, очлаеп торган башы ак, ә йомырканың түгәрәк өлеше караңгыланган. Димәк, монда биби бар. Аллаһ боерса, менә шушы өске өлешеннән, ак җиреннән биби тишеп чыгачак. Әле ике атналап утырасы бар. Бәбкәләр егерме сигез, егерме тугыз көннән чыга.

– Бер каз астына ничә йомырка куясыз? – дим.

– Казның түшенә карап, уннан да артыкны куймыйм инде. Алайса йомыркаларга җылы җитми. Ә җылы җитмәсә, биби зәгыйфь булып чыга. Йә кендеге кереп бетмичә үлеп китә, йә бөтенләй кабыкны тишеп чыга алмый.

Ана казлар көн саен иртән ояларыннан чыгып йөреп керә икән.

– Көн яктыруга, кыбырсына башлыйлар, – ди Римә апа. – Шунда ашыйлар да, эчәләр дә. Әле бит аларны парлары – ата казлар да көтеп тора. И, күрсәгез ана казлар чыккач ничек сөенгәннәрен! Ана казларның яннарында биеп кенә йөриләр. «Ата каз биюе» дигән сүз шуннан калган инде ул.

– Җиде ана казга бер-ике ата каз гына җитмиме? Ел әйләнәсе шулкадәр ата казны ашатырга да кирәк, – дим.

– И, парлап яшәсеннәр инде, алай кимсетәсем килми. Парлап яшәүгә ни җитә...

Чынлыкта сәбәбе бар икән – ана каз фәкать парын гына янына китерә, аккош кебек. Ата каз да үзенең пары янына бүтәннәрне китерми – сугыша башлыйлар икән.

– Аннары җиде ана казга бер-ике ата каз гына булса, йомыркаларның барысы да аталанмый, – дип дәвам итте Римә апа. – Әбием дә гомергә казларны парлап асрады. Мин дә гел шулай иттем. Биш янына ун сыя инде ул.

Гафиятуллиннар узган ел 160 баш каз үстергән. Гадәттә үз бәбкәләре янына инкубатордан чыкканын да сатып алалар. Быел да йөз баш кечкенә биби алып кайтканнар инде. Тик алары аерым үсә икән, ана каз басып чыгарган бибиләргә кушмыйлар.

– Ә бибиләрне сатып кына алу җиңелрәк түгелме? – дим әбигә.

– Өйдә басып чыгарган казларның ите тәмлерәк, – ди Римә апа. – Аннары, өйрәнелгән дә бит. Казсыз йорт буш кебек...

Соңыннан әбинең килене Хамисә чәй табынына чакырды. Каз бәлеше пешергән иде. Килен кайнана туфрагыннан ярала шул. Хамисә дә Римә апа кебек бик тырыш. (Хуҗалыкта ничә баш мал икәнен алда әйткән идем). Ире Фәннүр белән үзләре кебек тиктормас, малларны яратучы ике ул үстергәннәр. Шик юк, бу кунакчыл, гади гаилә турында җылы хатирәләр күңелдә озак сакланыр әле...

«МАЙСКИЙ»НЫҢ ИГЕЛЕКЛЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Ябык грунтта ел саен 45 мең тоннага якын яшелчә үстерә торган Россиядә иң эре предприятиеләрдән берсе ул, товарларын сату географиясе илнең күп төбәген колачлый, продукциясен төрле конкурсларда һәм күргәзмәләрдә тәкъдим итә. Җитештерү эшенә бик җитди караган хәлдә, «Майский» комбинаты үзенә уңыш һәм үсеш китергән кешеләр турында беркайчан да онытмый.

Теплица комбинатының төп кыйммәте һәм горурлыгы продукция җитештерүдә кулланыла торган яңа технологияләрдә түгел, ә аны яшәтүче һәм гөрләтеп эшләтүче кешеләрдә, дип басым ясарга ярата «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры Илшат Ганиев:

– Шуңа күрә үз хезмәткәрләре турында кайгырту, нәтиҗәле социаль сәясәт алып бару компания өчен өстенлекле бурыч булып тора.

Предприятие хәйрия эшчәнлегендә һәрвакыт актив катнашып, социаль яктан авыр хәлдәге гражданнарга, балалар бакчаларына, мәктәпләргә, мәчетләргә һәм гыйбадәтханәләргә ярдәм күрсәтә. «Майский» хезмәтчәннәре яшелчә һәм азык-төлек белән арзан бәядән тәэмин ителә, алдынгы эшчеләр Кара диңгез ярындагы пансионатларга юллама белән бүләкләнә, хезмәткәрләр өчен спорт һәм гаилә бәйрәмнәре оештырыла.

Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре аерата кайгыртучанлык тоеп яши. «Майский» теплица комбинаты төзелгән көннән башлап, биредә хезмәт куйган ветераннарга һәм сугышта катнашучыларга фатирлар бирелә килә. Аннан соңгы елларда торак йортларны һәм фатирларны төзекләндерүдә ярдәм күрсәтелә.

Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидларына, тыл хезмәтчәннәренә һәм сугыш чоры балаларына ел саен акчалата бүләк һәм азык-төлек җыелмалары өләшү күркәм гадәткә әйләнә. «Майский» теплица комбинатында хезмәт куючы сугышчы-интернационалистлар һәм Кавказдагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар да Җиңү көне уңаеннан һәр ел акчалата бүләк ала. Ел саен бу максатларга 400–500 мең сум акча бүлеп бирелә.

Өлкән буын турында шулай кайгырту – коллективның изге бурычы, дип саныйлар предприятиедә. Чөнки нәкъ менә ветераннар сугышның иң кызган чорында Ватаныбызның бәйсезлеген һәм хөрлеген саклап калды. Ә шинельләрен салып ташлауга, илне сугыштан соңгы җимереклектән торгыза башлады.«Майский»ның бүгенге уңышларында һәм казанышларында алар хезмәтенең, йөрәк җылысының өлеше бик зур.

«Майский» теплица комбинаты ярдәме белән 1987 елда Осиново авылындагы Җиңүнең 40 еллыгы урамында Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар һәм якташлар истәлегенә яңа һәйкәл ачылган. 2015 елда исә Нагорная урамында Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә куелган иске һәйкәл ремонтланган һәм Осиновоның Җиңүнең 40 еллыгы урамына караган яңа өлешендәге мәйдан һәм сквер төзекләндерелгән.

Фотолар «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ матбугат үзәгеннән алынды. Реклама

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

Мәңгелек кыйммәтләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанлылар Оборона фондына **КҮПМЕ** акча кerтк...

«Татарстан» **НИЧЕК** итеп фин хатынына татар бабасын табарга булыша

Садрый Максудиның язмышы **НИЧЕК** булган

Олы Тигәнәле халкы үз тарихын **НИЧЕК** саклый

186 ТАТАРСТАНЛЫ –
Советлар Союзы Герое

46 ТАТАРСТАНЛЫ –
Дан орденының тулы кавалеры булды

1941-1945

ТАТАРСТАН:

ҖИҢҮГӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШ

Сугышның беренче айларында ук Татарстан Язучылар берлегенә кергән **53 ЯЗУЧЫНЫҢ 25Е ФРОНТКА КИТӘ**. Алар арасында – **Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян, Сибгат Хәким, Гадел Кутуй.**

Фронтка китә –
700 МЕҢ КЕШЕ

Фронтка китүчеләр арасында –
10 МЕҢ ХАТЫН-КЫЗ

350 МЕҢГӘ ЯКЫН КЕШЕ сугыштан кайтмый.

Сугышка китәннәрнең **ҺӘР ИКЕНЧЕСЕ ДИЯРЛЕК ҺӘЛАК БУЛА.** Республика **11,5%** кешесен югалта.

Казанда сугыш елларында **10 МЕҢ «Пе-2» БОМБАРДИРОВЩИГЫ**,

11 553 «По-2» ТӨНГЕ БОМБАРДИРОВЩИГЫ җыела.

Татарстан сәнәгате продукциясенең тулаем күләме сугышка кадәрге 1940 ел белән чагыштырганда түбәндәгечә арта:
1941 ЕЛДА 1,4 ТАПКЫРГА,
1942 ЕЛДА 2,4 ТАПКЫРГА,
1944 ЕЛДА 3 ТАПКЫРДАН КҮБРӘККӘ.

Илдә бердәнбер булган Казан кетгут заводы **ЯРАЛАРНЫ ТЕГҮ ӨЧЕН КЕТГУТ ҖЕПЛӘРЕ** җитештерә. Сугыш вакытында кетгут җитештерү биш тапкырдан күбрәккә арта. Бу йөзәрләгән яралының гомерен саклап калырга булыша.

1944 елда Татарстанның **22 сәнәгать предприятиесенә Бөтенсоюз социалистик ярышындагы югары уңышлары**, хезмәт фидакарьлеге өчен Оборона дәүләт комитетының **Кызыл Байраклары тапшырыла**. «По-2» самолетлары җитештергән коллективта Кызыл Байрак мәңгелеккә калдырыла.

Татарстан фронтка **1 МЛН ШИНЕЛЬ, 1,5 МЛН ПЛАЩ-ПАЛАТКА** тегеп озата. Һәр көнне татарстанлылар бер полкны киендерәләр, 1 дивизияне аяк киеме белән тәэмин итәләр.

Республика илгә бирә:
- **131 МИЛЛИОН ПОТ ИКМӘК,**
- **59 МИЛЛИОН ПОТ ИТ,**
- **39 МИЛЛИОН ПОТ БӘРӘҢГЕ ҺӘМ ЯШЕЛЧӘ,**
- **200 МИЛЛИОН ЛИТР СӨТ,**
- **ЯРТЫ МИЛЛИОН ПОТ ЙОН.**

Татарстанлылар сугышчылар өчен әзерләгән:
- **23 МЕҢ КЫСКА ТУН,**
- **54 МЕҢ ПАР ИТЕК,**
- **59 МЕҢ ҖЫЛЫ СЫРМА ҺӘМ ЫШТАН,**
- **106 МЕҢ ПАР ҖЫЛЫ ЭЧКЕ КИЕМ Һ.Б.ЛАР.**

262 МИЛЛИОН СУМНАН АРТЫК АКЧА ТАТАРСТАНЛЫЛАР ТАРАФЫННАН ОБОРОНА ФОНДЫНА КҮЧЕРЕЛГӘН. Җыелган акчаларга «Красная Татария» һәм «Колхозник Татарии» танк колонналары, «Совет Татарстаны» авиадивизиясе, бронекатерлар, бронепоездлар һәм башкалар төзелә.

70 ТӘН АРТЫК ЗАВОД ҺӘМ ФАБРИКА, ФТИлары Татарстанга эвакуацияләнә һәм үз эшен җайлап җибәрә.

Сугыш вакытында фронт ихтыяҗлары өчен Татарстан сәнәгате **600 ТӨРДӘН АРТЫК ПРОДУКЦИЯ** чыгара:
- хәрби самолетлар,
- артиллерия һәм ату кирәк-яраклары,
- атаклы «Катюшалар» өчен реактив снарядлар һ. б. лар.

Казанга СССР Фәннәр академиясе һәм Белоруссия Фәннәр академиясе Президиумнары, **20 ГӘ ЯКЫН ФТИ** күчерелә.

Биредә **ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНЕҢ 100 ДӘН АРТЫК АКАДЕМИГЫ ҺӘМ МӨХБИР ӘГЪЗАСЫ** эшли: **Отто Шмидт, Сергей Вавилов, Александр Несмеянов, Евгений Тарле, Игорь Курчатов, Пётр Капица** һәм башкалар.

Сугыштан исән кайткан аталы-уллы Мостафиннар.

«КАЙТЫП ҖИТКӘЧ, ӨЙГӘ КЕРМӘДЕҢ...»

Автор: Руфия Фазылова

1944 елның кышында авылда хәбәр тарала. Фронттан кайткан Хизбулланы күргәннәр. Тик ир туган авылына – гаиләсе янына кайтмаган. Хәләл җефете Миңнебәян әлеге хәбәрдән соң якын-тирәдәге төрмәләрне йөреп чыга. Соң, дүрт баласының әтисе, сугышта өч ел гомерен уздырган ире суда эреп югала алмый бит! Йөрәк ярасын тирәнәйтеп, авылда төрле имеш-мимеш тарала... Ә бәлки Хизбулла сатлыкҗан булгандыр, шуңа да туган ягына кайткач, гаиләсе янына кермәгән. Ә бәлки...

«БИШЕКТӘ КАЛГАНМЫН»

Әлеге җан әрнеткеч хәлләр 1944 елда була. Алексеевск районының Олы Тигәнәле авылы кешеләре бу хәлне һаман да искә алып сөйли.

Сугыштан туган ягына исән әйләнеп кайтып та, гаиләсен күрү бәхетенә ирешмәгән Хизбулланың кызы Зөлкәрия апа бүген Алексеевск район үзәгендә яши. Ни кызганыч, берничә ай элек алтмыш елга якын гомер иткән җәмәгате Шамил абый Мөлековны югалткан.

– Ковидтан соң тернәкләнә алмады, – ди.

Зөлкәрия апа этисен хәтерләми, чөнки газиз кешесе сугышка киткәндә аңа нибары өч ай гына була. Ул аны фәкать әнисе, якыннары сөйләгәннәрдән генә хәтерли:

– Әнием Миңнебәян сөйли иде: «Сугышка китәр алдыннан әтиең синең янга килде дә битеңнән үпте. Син бишектә ята идең. Мыеклары кытыклады булса кирәк, битеңә кулың белән кагылып алдың...»

Сугышка киткәндә Хизбуллага кырык дүрт яшь була. Өйдә аның дүрт баласы, хатыны кала.

– Әтинең документлары сакланмаган, –диде Зөлкәрия апа. – Район хәрби комиссариаты аша соңыннан белешмә алдык – ул, башы яра-

Фото: Лилиана Вәлитова

ланып, берничә ай Новосибирск госпиталендә яткан. Шуннан соң аны, тернәкләнергә дип, алты айга туган ягына кайтарып җибәргәннәр. Казанга кадәр солдатлар озата кайткан. Әти Казан вокзалыннан сеңлесе Кафиягә киткән.

Әтинең әтисе Мостафа бабайның ике хатынга унике баласы булган. Әти – беренче хатынның иң олы баласы. Ә Кафия апа икенче хатыннан туган кыз була. Сеңлесендә берне кунып чыкканнан соң әти юлга – Олы Тигәнәлегә кузгала. Кайда ат очрап, кайда җәяү берничә көн кайта.

Фронттан кайткан Хизбулла Казан вокзалында Галиулла исемле авылдашын очрата. Алар тиз генә хәбәрләшәләр. «Туган якка – гаиләм янына кайтып барыш», – ди Хизбулла. Ноябрь уртасы була бу. Яңа ел алдыннан Галиулла атлы кеше Олы Тигәнәлегә кайта һәм Хизбулла белән очрашуын әйтә. Бу хәбәр авылда яшен тизлегендәй тарала. Хизбулла бит гаиләсе янына кайтмады! Сәбәп нәрсәдә? Берничә көннән тагын бер шомлы хәбәр килеп ирешә – Хизбулла ноябрь аенда күрше Кыркүл авылына кереп, чәй эчеп чыккан. «Балалар янына өйгә кайтам»- дигән. Кешеләр, ирен сугыштан көтүче Миңнебәянгә турыдан-туры әйтмәсәләр дә, үзара шыпырт кына сөйләшә башлый: «Бәлки ул сугыштан качып кайткандыр? Һәм берәр җирдә яшеренеп ятадыр?!»

– Хәтта безнең өйгә тентү белән дә килгәннәр, – дип дәвам итте Зөлкәрия апа. – Базны, каралты-кураларны тикшергәннәр – әтине эзләгәннәр. Әнинең бу вакытта ниләр кичергәнен күз алдына да китерүе авыр. Әле бит олы улы, абыемны да шул чакта сугышка алган булалар. Ничекләр йөрәге түзгән дим...

Тентүчеләр киткәннән соң Миңнебәян апа, балаларын күрше әбигә калдырып, ирен эзләргә үзе китә. Башта Чистай төрмәсенә бара. Аннан Питрәчкә юл ала. Бәхетенә (ә бәлки бәхетсезлегенә), ирен анда тапмый. Шул салкыннарда җәяү, ач килеш йөри торгач, көчкә өенә кайтып егыла.

«ӘЙДӘ, КИЛЕН...»

Ямьле яз җитә. Миңнебәян ирен, менә бүген кайтып керер, дип, көн дә көтә. Җитмәсә, военкоматтан хәбәр килә – Хизбулла сугыштан качып кайтмаган икән, башы яраланганга, аны туган ягына кайтарып җибәргәннәр. Мөгаен, ул күрше авылда берәр йортка кергәндер, хәтере начарлангандыр. Ире барысын да искә төшерер дә, кайтып керер.

Март ае була ул. Ишектән күрше бабай керә:

– Миңнебәян, килен, берәр капчык ал әле. Кырга барып кайтырга кирәк...

– Кырга? Ә нишлибез анда? Әле бит кар эреп кенә килә.

– Иген таптым. Шуны алып кайтырга кирәк.

Миңнебәян килен, аны-моны уйламыйча, капчыгын ала да күрше бабай артыннан иярә. Авылдан чакрым ярым ераклыктагы үзәнлеккә килеп җиталәр. Бабай эндәшми генә Миңнебәянгә ишарәли... Шунда ул... Иренең утырган җиреннән катып калган гәүдәсен күреп ала.

– Әтине зиратка алып кайтып җирлиләр, – дип, күз яшьләрен сөртте Зөлкәрия апа. – Күрәсең, ул җәяү кайтып арган булган, ял итәргә утырган. Ә бәлки хәле киткәндер. Күрше Кыркүл авылында яшәүче танышы янына кергән бит. Эх, шунда кунып чыккан булса... Ул вакытта танышы аңа: «Хизбулла, хәзер караңгы төшәчәк, бездә генә кун. Иртән юлга чыгарсың», – дигән. Тик әти тыңламаган. «Меңәр чакрым юлны узгач, җиде чакрымын гына узам инде. Балалар мин кайтканда кичке аш ашарга утырган булалар. Ә мин тәрәзәгә чиртәм дә, барысын шаккатырам», – дигән. Букчасында безгә дигән солдат ризыгы – консерва, шикәр, сохари булган. Әтинең солдат букчасында ул ризыклары шулай кайтып ирешә, үзе генә кайтып җитә алмый...

Ирен җирләгәннән соң Миңнебәян бакча артларына терәлеп үк торган зиратка бик еш бара. Һәм гел бер сүзне әйтә: «Их, Хизбулла, кайтып җиткәч, өйгә кермәдең бит! Соң шулай арыймы, җә?! Мең чакрымнар йөреп, бер чакрымны уза алмадыңмы?.. Балалар көтте...»

– Тәкъдир бар, – диде Зөлкәрия апа. – Күрәсең, әтигә туган авылын, әнигә яраткан ирен, ә без балаларына әтине күрергә язмаган. Әле, Аллаһка шөкер, абыебыз сугыштан исән-сау кайтты. Дөрес, ул да озын гомерле булмады – өйләнеп, бер баласы тугач, сугышта алган яраларыннан җан тәслим кылды. Сугыш бик күпләрнең язмышын астын өскә китерде. Шул исәптән безнекен дә. Шуңа да бүгенге тыныч көннең кадерен аңлый, матурлыгын күрә белсәк иде. Гомер бер мизгел генә...

...Зөлкәрия апа гомер буе башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләгән. Хәләл җефете Шамил Мөлеков белән үрнәк, тату гаилә корган. Районның хөрмәтле кешеләре, атаклы гаиләсе бу. Балалары да әти-әниләре кебек матур тормыш корган. Бүген Зөлкәрия апа ялгызы яши, намазда. Мәрхүм булган якыннары рухына, балалары исәнлегенә багышлап көн дә дога кыла.

Хизбулланың кызы Зөлкәрия Мөлекова.

ТЫЕЛГАН МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

«Мин үземнең татар бабамны эзлим. Бу печән кибәненнән энә эзләүгә тиң. Бабамның фамилиясен дә белмим, карточкасы да юк. Бөтен өмет сездә!»

Автор:
Олеся Бондаревская

Туйа Арсадның берничә ел элек социаль челтәрләргә элгән хәбәре әнә шул сүзләрдән башлана. Эзләнә торгач, җеп очы Финляндиядә яшәүче Туйаны Татарстанга кадәр алып килгән. Аның бабасы кем булган дигән сорауга җавап нәкъ шушында. Әмма бу тарих башка җирдә башланып киткән.

АВЫЛДАН – ӘСИРЛЕККӘ

Бөек Ватан сугышы вакытында Карелия фронтында ТАССРдан чакырылган 2300 дән артык солдат һәм офицер һәлак була.* Финнарда әсирлектә булган Татарстан кешеләренең төгәл саны билгеле түгел. Туган якны өйрәнүчеләр һәм тарихчылар җыйган мәгълүматларда исә саннар төрле. Шунысы мәгълүм: мәсәлән, 1941 елның 7 июлендә Зур Тәрбит авылыннан (хәзер Татарстанның Кайбыч районы) фронтка 18 егет киткән. Соңрак алар барысы да диярлек Карелия фронтына эләккән. 18 солдатның 9 ы әсирлеккә төшкән һәм исән калган. Тугызысы исә һәлак булган.

Былтыр ноябрь аенда безне Туйаның гаилә хикәяте, төгәлрәге, кыз Финляндия архивларында тапкан Николай Кириллов исемле хәрби әсирнең карточкасы нәкъ менә Зур Тәрбиткә алып килде. Ул – керәшен татары, 1908 елда Зур Тәрбит авылында туган. 1941 елда фронтка киткән. Аны хатыны һәм кызы озатып калган.

Сугышка кергүгә, Николай Кириллов әсирлеккә төшә һәм финнар оккупацияләгән Карелия территориясендәге дистәләгән лагерьдан берсе – Куркиёкига эләгә. Биредә әсирлеккә төшкән рус солдатлары яши.

** Татарстанның «Хәрби дан клубы» Ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов мәгълүматлары буенча.*

Фотолар чыганагы: http://sa-kuva.fi/ сугыш вакыты фотографияләренең Фин архивы, Туйа Арсадның шәхси архивы,Александр Ефремов фотолары




Sv. leiri 12. 1.12.41.
Sv. järj. leiri N:o Päivämäärä
Vangin N:o 10-1363. 5.

SOTAVANKIKORTTI.

1. Suku- ja etunimi Kirillov, Nikolai. – Кириллов, Николай.
2. Syntymäaika ja -paikka 1908, Kazanj'in alue.
3. Vanhempien nimet, äidin tyttönimi Илья, – Ирина, o.s. Данилова
4. Kenelle ja mihin ilmoitettava tapaturmasta t. m. s. vaimo: Ирина Романовна Кириллова, Тат. АССР, Кайбицкий р-н, Б. Тябрикеский с/с, с. Больш. Тябрино.
5. Siviiliammatti maanvilj. 6. Kansallisuus tatari.
7. Tuntolevyn N:o 8. Sotilasarvo stm.
9. Joukko-osasto (div. rykm. kompp.) 3/JR. 951.
10. Vangitsemisaika ja -paikka 20.8.41.
11. Vankilaantuloaika 24.9.41.
12. Vanki lähetetty edelleen (milloin ja minne)

Kuulustelija (nimi ja arvo)

Лагерьларда яшәү шартлары төрлечә була: кайсындадыр ачтан үләләр, кайсыларында түзәрлек була, эшләтәләр. Куркиёки әсирләрен якын-тирәдәге фермаларга ялчы итеп җибәрәләр.

СУГЫШ МИРАСЫ

«Әбиемнең фермадагы әсирләрне саклаучы туганы бабамның күпләрне гашыйк итәрлек бик чибәр булуын хәтерли. Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле ир-егет булган ул. Милләте буенча татар, шуңа да йөз-кыяфәте һәм тиресенең бераз кара-кучкылрак төсе белән аерылып торган. Бабам фин телен өйрәнеп алган. Фермада финнарны русча сөйләшергә өйрәткән. Әсирлеккә төшкәнче, бабам танкчы (механик-йөртүче) булган. Әбиемнең туганы бабамның исемен Николай Хасин (Хашин) дип әйтә иде. Әбием шушы зифа буйлы чибәр әсиргә гашыйк булган, һәм шушы тыелган мәхәббәттән 1944 елның мартында кыз бала – әнием Айла туган. Әнием этисеннән фин кызы өчен экзотик булган татар йөз-кыяфәтен мирас итеп алган», – дип яза Туйа.

«Николай» исеме эзләнүләрне башлау өчен таяну ноктасына әйләнә. 2016 елда Туйа чын-чынлап бабасын эзләп табу ниятен тормышка ашыра башлый. Зур Тәрбиттә туган Кирилловның карточкасын ул 2020 елның ноябрендә таба. Бу вакытка инде Туйа үзе һәм әнисе ДНК-тестлар ясаткан була, аларның тамырларында татар каны агуы раслана.

ТУГАНЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

Зур Тәрбиткә килү белән без, ДНК-тест ясауларын үтенергә дип, Николай Кирилловның туганнары янына ашыктык. Тест аларның Айла һәм Туйа Арсадлар белән туганлыгын расларга яки кире кагарга тиеш иде.

Безне Николайның улы Виктор каршы алды. Без сөйләгән тарихны ул кызыксынып тыңлады. Әтисенең сугыштан кайтуы һәм 1980 елда вафатына кадәр диярлек Тәрбит колхозында хисапчы булып эшләве турында сөйләде. Әсирлектә булуы хакында берни дә сөйләмәгән

1 2 3 Фин лагерьларындагы хәрби әсирләр.

4 Куркиёки лагере хәрби әсире Николай Кириллов карточкасы.

диярлек. Артык сорашмаганнар да, моны кирәк дип уйламаганнар да. Сугыш кагылмаган гаилә булмаган диярлек ул вакытта, һәр йортта диярлек шуңа охшаш тарих бар. Тормыш дәвам иткән. Сугыштан соң Кирилловлар гаиләсендә тагын дүрт бала дөньяга килгән. Виктор этисен болайрак тасвирлый: намуслы, тырыш, тәрбияле, хезмәт сөючән. Шаяртырга яраткан, гаиләсе дип яшәгән.

Без Викторга Айланың яшь чагындагы фотосын күрсәттек – миндальсыман күзләр, очлаеп торган яңак сөякләре, кара-кучкыл төстәге бөдрә чәчләр. Айланың бүгенге фотосын күрсәтәбез.

– Әйе, нәрсәдер бар кебек, – дип җавап бирә Виктор, шикләнеп кенә. Айланың кыяфәтен чагыштыру мөмкин түгел диярлек. Николай Кирилловның сакланып калган бердәнбер фотосы – кабер ташында.

Виктор тест ясарга ризалашты.

5
Айланың берничә ел элек төшерелгән фотосы.

6
Николай Кирилловның сакланып калган бердәнбер фотосы.

«ТӨРЛЕ МӘГЪЛҮМАТЛАР БУЕНЧА ФИНЛЯНДИЯДӘ СОВЕТ ӘСИРЛӘРЕНЕҢ БАЛАЛАРЫ 200–400 КЕШЕ ДИП ИСӘПЛӘНЕЛӘ. Балалар саны турында төгәл мәгълүмат беркайда да юк. Безгә, хәрби әсирләрнең балаларына, мирас булып калган бердәнбер нәрсә – җан тартуы. Бу мирасны тотып карап булмый, әмма ул шундый зур, һәрхәлдә, минем өчен».

Викко Иммнонен, «Фейсбук»та финнарның рус бабаларын эзләүчеләр төркеме администраторы.

ҖИМЕРЕЛГӘН БӘХЕТ

Туйа «ВКонтакте» челтәрендәге сәхифәсенә финнарның Россиядәге туганнарын табулары турында язмаларны куеп бара. Әгәр Николай исемле солдат турында күбрәк белсә, аның тарихы да шулай ук бәхетле тәмамланыр иде. Әмма Николайның фин кызы белән гыйшкы фаҗигале тәгәлләнә. Ферма хуҗасы, аларның мөнәсәбәтләре турында белүгә, кызын хутордан алып китә. 1944 елда Карелиядә каты сугышлар башлана, һәм яшь хатын, кызын алып, Финляндиягә кача. Николай хакында ул башка беркайчан берни ишетми. Алай гына да түгел, ул Айлага да этисе турында бер сүз дә сөйләми. Туйа уйлавынча, әбисе Николайны үлгән, ихтимал, нәкъ менә аның аркасында үлгән, дип санагандыр. Фермер кызына күз салган әсиргә җәза бик тә, бик тә каты булырга мөмкин иде бит...

«Әтисенең совет әсире булуы турында белгәндә, энигә кырык яшь тулган инде. Әбинең әлеге мәхәббәте турында бер дә сөйлисе килмәгән. Ул бу серен үзе белән алып киткән. Әмма әни этисенең язмышын бернигә карамастан ачыкларга хәл иткән», – дип сөйли Туйа.

Без Зур Тәрбиттән, Туйа биредә үзенең тамырларын табар, дигән өмет белән киттек. Әмма тарих яңа борылыш алды.

ДӘВАМЫ БАР

– Без Хашин фамилиясенә таянып эзләүне шундук кире кактык, чөнки лагерьда андый фамилияле кеше булмаган һәм ТАССРдан андый фамилияле кеше килү ихтималлыгы да бик аз. Мөгаен, фамилия карточкага язганда яки фин телендә әйткәндә үзгәргәндер, –

7

«Әниемнең фотосын игътибар белән карагыз әле. Монда аңа 15 яшь. Фин кызы өчен аның йөз чалымнары экзотик. Ул әтисеннән татар чалымнарын мирас итеп алган», – дип яза үзенең мөрәҗәгатендә Туйа. Чыннан да, фотографиядә – бик сөйкемле туташ. Аның яңак сөякләре очлаеп тора, чәчләре кара-кучкыл, күзләре миндальсыман. Әмма эзләнүләр өчен бер фото гына җитми.



ди Idel ДНК-проекты администраторларыннан берсе Олег Владимиров. Ул – генетика генеалогиясе белгече, һәм Туйага Татарстандагы эзләнүләрендә ярдәм итә.

«Николай» исеме дә билгеле бер мизгелдә ориентир ролен уйнаудан туктый. Виктор Кирилловның тест нәтиҗәләре Туйа белән туганлыкны күрсәтми. Гәрчә аның ДНКсында Кайбыч районы татарларына хас өлеш булса да, эзләнүләрне керәшен юнәлеше буенча дәвам иттерү өчен мәгълүмат җитәрлек түгел. Әсирлектә рус исемнәре белән еш кына керәшеннәрне генә түгел, ә башка татарларны да атаганнар – оккупантлар аларның чын исемнәрен әйтә дә, истә дә калдыра алмаган.

Шуның өчен дә хәзер Туйаның Финляндиядәге хәрби әсирләр архивларыннан эзләнүләре өчен төп нигез булып бабасының туган елы – 1908 яки 1909 ел (аның Туйаның әбисеннән берничә яшькә кечерәк булуы билгеле) һәм ТАССРдан чакырылуы тора. Шулай итеп, быел апрель аенда яңа кандидат – Мансур табыла. Билгеле сәбәпләр аркасында, без әле аның чын исемен һәм фамилиясен, шулай ук яшәгән урынын әйтми торабыз.

Мансурның гаиләсе безне якты йөз белән каршы алды. Тестны аның улына ясадылар. Николай Кириллов кебек үк, бу «Николай» да сугышка кадәр өйләнгән булган, ике баласы бар. Аның фронттагы һәм әсирлектәге тормышы турында гаиләдә сөйләшмәгәннәр. Шул гына билгеле: Куркиёки лагереннан азат ителгәч, ул Җиңүгә кадәр сугышкан. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнгән. Сугыштан соң туган авылына кайткан, механизатор булып эшләгән. Тагын дүрт баласы туган. Бүген инде 70 тән узган улы һәм аның гаиләсе Туйаны һәм аның әнисен туганнары кебек кабул итәргә әзер.

Тест нәтиҗәләре 9 майдан соң билгеле булачак. Ихтимал, Туйаның үзенеке генә булган Җиңү көне дә барлыкка килер әле...

P.S. Материалны басмага әзерләгәндә, Туйаның бабасының килеп чыгышы буенча тагын бер фараз барлыкка килде. Укучыларыбыз арасыннан берәрсе Татарстанның Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылыннан Ибраһим Садыйков (1909 елгы) язмышы турында хәбәр бирсә, рәхмәтле булыр идек.

8

Тест ясар өчен яңакның эчке ягын махсус щетка белән сыпырып алырга кирәк.

9

Олег Владимиров тест үрнәкләрен җайлап урнаштыра. Алар лабораториягә җибәреләчәк.

«МИНЕМЧӘ, ҺӘРБЕР КЕШЕ ҮЗЕНЕҢ ТАМЫРЛАРЫН БЕЛЕРГӘ ЛАЕК. Минем әнинең дә әтисенең кем булуын белергә хакы бар, – ди Туйа. – Сугыш – коточкыч, әмма аннан башка минем әни дә, мин дә булмас идек. Мин һәрвакыт үземнең бер өлешемнең югалганлыгын тоеп яшәдем. Аны табасым килә. Бабамның каберен зиярәт кылыр, мөмкин булса, аның туганнары белән очрашыр идек. Безнең өчен бик әһәмиятле бу!»

БЕРЕНЧЕ ПРОФЕССИОНАЛЬ ТАТАР СӘЯСӘТЧЕСЕ: САДРЫЙ МАКСУДИ

Автор: Илдус Заһидуллин

Садрый Максуди – совет идеологиясе җимерелгәч, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Йосыф Акчура, Фатыйх Кәрими, Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар кебек фикердәш һәм мәсләктәшләре төркемендә исеме вә эш-гамәлләре халыкка әйләнеп кайткан күренекле татар интеллектуалларыннан берсе.

2016 елның 7 декабрендә Казандагы Истанбул паркында Садрый Максудига һәйкәл ачылды. Бу һәйкәл Максудиның татар һәм төрек халыклары мәнфәгатенә риясыз хезмәтенә хөрмәт билгесе буларак кабул ителә.

ШУЛАЙ ДА, САДРЫЙ МАКСУДИ ФЕНОМЕНЫ НӘРСӘДӘН ГЫЙБАРӘТ СОҢ?

Аның биографиясендәге күп вакыйгалар гаҗәпсендерә. Әйтик, авыл мулласы баласының Сорбонна университетында укуы, хокук фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсе алуы; Россия империясе һәм Төркия Республикасы парламентларында сәяси эшчәнлеге; Франция һәм Төркия югары уку йортлары профессоры булуы; төрки халыкларның борынгы тарихы буенча күренекле галим, татар мөһаҗирләре арасында иң югары дәрәҗәгә һәм танылуга ирешүе...

XX гасыр башында Казан өязе Ташсу авылы имамы Низаметдин хәзрәт улларының язмышлары төрлечә язылa. Сәләхетдин исемле уртанчы улы, сәүдәгә кереп китеп, Казанда аяк киемнәре кибете ачып җибәрә. Олы улы Әхмәтһади һәм кече улы Садретдин, фән юлын сайлап, гыйлем өлкәсенә тугры кала.

1878 елның 23 июлендә дөньяга килгән төпчек улы Садретдин 1888 елда абыйсы артыннан башта Күл буе мәдрәсәсенә укырга керә. 1894 елны 17 яшьлек яшүсмер Садрый, хәлфәсенә ияреп, Бакчасарайга, «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә бара, биредә русча өйрәнә башлый, үзен укырга чакырткан Исмәгыйль Гаспралы һәм аның гаилә әгъзалары белән аралаша. Татар яңарышы идеологы булган бу олуг шәхесне Садрый үзенең рухи остазы, атасы дип атый. Бер уку елыннан соң, рус телен тирәнтен өйрәнергә теләп, 1896–1901 елларда рус-татар башлангыч мәктәпләре өчен педагоглар әзерли торган Казан Татар укытучылар мәктәбендә белем эсти. Биредә укыганда «Мәгыйшәт» (1898) исемле роман да яза. 1901 елның җәендә, куен дәфтәренә сораулар язып, Ясная Полянага бара, бөек рус язучысы Л.Н.Толстой белән берничә сәгать гәпләшә.

Садретдин киләчәк язмышы хакында сөйләшү өчен кабат Кырымга И. Гаспралы янына килә һәм, аның киңәшен тотып, Франциягә укырга китә. 1902 елда Сорбонна университетының хокук факультеты студенты булганчы, егеткә бер ел хәзерлек курсларында укырга, француз телен камилләштерергә туры килә. Университетта дүрт ел уку дәверендә кызыксынучан Садретдин, программадан тыш, фәлсәфә, социология һәм филология фәннәре буенча да лекцияләргә йөри.

Фотолар автордан алынды

ЕГЕТ ПАРИЖДА НИНДИ ХИСАПКА УКЫГАН-ЯШӘГӘН СОҢ?

Аңа баштарак күпмедер күләмдә акчаны 3-4 ай саен абыйсы Әхмәтһади җибәреп тора, шулай ук И.Гаспралы да акча күчерә. Рәхмәт йөзеннән Садретдин, «Тәрҗеман» газетасында бастыру өчен, 1904–1905 елларда Америка язучысы Эдуард Белламиның тигез хокуклы кешеләр яши торган социалистик җәмгыять турындагы «2000 ел» исемле фантастик романын французчадан татарчага тәрҗемә итә. Әсәр 1906 елны «Тәрҗеман»да дөнья күрә.

1904 елның гыйнвар азагында башланган Рус-япон сугышы, аннары Россиядә кабынган Беренче буржуаз революция көтмәгәндә татар студентының матди хәле яхшыру гына түгел, ә көрәеп китүенә сәбәп була. Ул Россиядәге вакыйгаларны тасвирлауда беренчел чыганак булган рус матбугатында басылган хәбәрләрне күпләп французчага тәрҗемә итеп, Париж газеталары редакторлары белән актив хезмәттәшлек итә башлый, студентның аралашу даирәсе киңәя.

Парижның Ирекле сәяси фәннәр мәктәбендә укучы милләттәше Йосыф Акчура белән Садретдин, үзләре дә сизмәстән, Россиядә мөселман халыклары арасында либераллар хәрәкәте оеша башлауга этәргеч бирә. Вакыйга болай була. Студентлар ашханәсендә утырганда, сүз аркылы сүз чыгып, Йосыф Акчура Исмәгыйль Гаспралыдан тиздән «Тәрҗеман» газетасы чыга башлауга 25 ел тулу турында язган хат алганын әйтә. Дуслар бу вакыйганы билгеләп үтәргә ниятли. Садретдин бу хакта зур булмаган текст язып, Йосыф Акчура аны почта конвертына сыярлык зурлыкта 100 данә бастыртып, Казан, Кырым, Төркестан һәм Азәрбайҗан җәмәгать эшлеклеләре адресларына юллыйлар. Юбилейны уздырырга өндәгән шушы китапчык төрки дөньяны хәрәкәткә китерә. Бер төркем җәмәгать эшлеклесе 1903 елның көзендә Бакчасарайда мәҗлескә җыелып, берничә көн дәвамында фикер алыша, шул рәвешле Россия мөселман либерал хәрәкәте оеша башлый.

Садретдин Париждан турыдан-туры Түбән Новгородка, 1906 елның 16–20 август көннәрендә либераллар оештырган III Бөтенроссия мөселманнары съездына кайтып төшә. Бу олуг мәҗлеснең сәясәт комиссиясендә ул Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспралы, Галимәрдән Тупчыбашев, Габдерәшит Ибраһимов, Сәидгәрәй Алкин, Гобәйдулла Буби, Муса Бигиев һәм абыйсы Әхмәтһади белән бергә эшли, «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең Үзәк комитетына сайлана.

ДЕПУТАТ САДРЫЙ

Татар либераллары, кадетлар партиясе белән берләшеп, Казан губернасы крестьяннарыннан сайланган депутат буларак, II Дәүләт Думасы урнашкан Таврия сараена Садрый Максуди да килә. Әле сәяси эшчәнлек тәҗрибәсе булмаган, ләкин киң эрудицияле, үзен европача тотучы 29 яшьлек егет кадетлар партиясе фракциясе бюросына тәкъдим ителә, ул фракция сәркатибенең урынбасары итеп сайлана, ягъни Дәүләт Думасы Президиумы әгъзасына әверелә. Садрый, моңардан тыш, 1907 елның 17 мартында оешкан мөселман фракциясе бюросына да сайлана. Ул шулай ук Думаның Дин иреге мәсьәләләрен карый торган комиссиясендә дә эшли.

Максуди II Дәүләт Думасы мөнбәреннән берничә тапкыр гына чыгыш ясарга өлгерә. Дүрт ай эшләгәннән соң, II Дума куып таратылгач, «Йолдыз» газетасының сигез санында Казан губернасы сайлаучыларына биргән вәгъдәләренең ничек үтәлгәне турында турында хисап бастыра.

Ул III Дәүләт Думасына да депутат булып сайлана, парламент тәүге тапкыр тулы срокта 1907 елдан 1912 елга кадәр эшли. Садрый шушы биш елда олы сәясәт мәктәбен үтә, төрле фикерле шәхесләр һәм сәяси төркемнәр белән хезмәттәшлек итәргә, кирәк булганда үз фикерен яклап бәхәсләшергә өйрәнә, оста дипломатка әйләнә. Аның Думада ясаган кыю, дәлилле чыгышлары бу елларда Садрый Максудины Россиядә иң популяр мөселман сәясәтчесе итеп таныта. Шунысын да искәртү мөһим: ул заманда Дума мөнбәре төрки халыкларның мәнфәгатьләрен яклауда бердәнбер рәсми урын һәм дәреслекне хакимияткә вә Россия җәмәгатьчелегенә җиткерә алырлык иң ышанычлы канал була.

Садрый Максуди II Дәүләт Думасы президиумы әгъзалары һәм матбугат бюросы вәкилләре арасында. Басканнар арасында – сулдан дүртенче.



Максудилар гаиләсе. Уңнан сулга: Садрый Максуди, кызлары Наилә һәм Гадилә, хатыны Камилә. Төркия. Якынча 1930 нчы еллар.

Сәяси карашлары буенча уң либераллар лагерена караган Садрый Максуди, активлык күрсәтеп, III Думада канун проектлары әзерләү, шәхеснең кагылгысызлыгын тәэмин итү һәм финанс комиссияләрендә эшли. Шулай ук Исмәгыйль Леманов белән мөселман фракциясенең сәркатибе вазыйфасын башкара.

Максуди бу елларда 10 депутатны берләштергән Котлымөхәммәд Тәфкилев җитәкчелегендәге мөселман фракциясе исеменнән чыгыш ясаучы төп докладчы була. Аның чыгышларында хокук, халык мәгарифе, дәүләт һәм дин, халыкара сәясәт һ.б. мәсьәләләр күтәрелә. Шушы чыгышлар арасында иң танылганы – Дәүләт Думасы ябылыр алдыннан сөйләгәне, Россия мөселманнарында панисламчылыкның булмавы хакындагы доклады.

Депутат булып эшләгәндә Садрыйның тормышында ике зур вакыйга була. 1909 елны Садрый мөселман фракциясе вәкиле сыйфатында Дәүләт Думасы депутатлары составында Англия парламентында була. Күргән-белгәннәрен һәм тәэсирләрен «Англиягә сәяхәт» исемле юлъязмада теркәп бастыра. 1910 елны ул Муса Бигиев димләве буенча Оренбургтагы алтын прииск хуҗасы Шакир Рәмиевнең кызы Камилә туташка өйләнә. Бу никахтан Гадилә һәм Наилә исемле кыз балалар туа. Гаиләсе, хатыны һәм балалары Максудига тормышның авыр мизгелләрендә көч һәм ял бирә торган кирмән була.

1913–1918 ЕЛЛАРДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Садрыйның Дума мөнбәреннән ясаган тәнкыйди чыгышларыннан туйган империя хакимияте сәясәтчене, авыл җирендә күчемсез милке юк дигән урынлы сәбәп табып, IV Дәүләт Думасына сайлауга катнаштырмый.

Максуди тормышында яңа этап башлана. Ул, Мәскәү университетында экстерн юлы белән имтиханнар тапшырып, югары юридик белем турында диплом ала һәм 1913–1917 елларда Казан мәхкәмә палатасында антлы вәкил ярдәмчесе һәм адвокат булып хезмәт куя, берничә тапкыр шәһәр Думасына гласный итеп сайлана.

Адвокат 1917 елдагы Февраль революциясеннән соң зур сәясәткә тартыла. 23 мартта «Йолдыз» газетасында «Милли съездны ничек җыярга?» дигән мәкалә бастырып, Уфада Мәхкәмәи шәргыя каршында корылтай ясап, аны дини һәм милли үзәккә әверелдерергә тәкъдим итә. Бу мәҗлес бөтенроссия дәрәҗәсендә җыелып, анда күпчелекне Идел-Урал төбәге вәкилләре тәшкил итәргә тиеш, дип ассызыклый. Апрель аенда съездны Оештыру үзәге төзелә. Ул да түгел, Вакытлы хөкүмәт Садрыйны, Төркестан белән идарә итү комитеты составына кертеп, Ташкентка җибәрә. Максуди үзенә эш юнәлеше итеп мәгариф өлкәсен сайлый. Садрый 1917 елның 16 апрелендә I Бөтентөркестан мөселманнары съездында катнаша. Анда Россиянең киләчәге мәсьәләсе дә карала. Зәки Вәлиди, Россия федерация булырга тиеш, дип чыгыш ясый, Садрый Максуди бу фикергә каршы төшә.

Мәскәүдә 1–11 май көннәрендә I Бөтенроссия мөселманнары съезды була. Россиянең мөселман халыклары мәнфәгатьләренә җавап бирә торган дәүләт төзелеше тупраклы мохтәрияттән торган федерация булырга тиеш, ә үз җирләре булмаган халыкларга милли-мәдәни автономия бирергә, дигән карар кабул ителә. Бу мөһим вакыйгадан Максуди читтә кала һәм, мине Төркестанга җибәреп зур сәясәттән читләштерделәр дип, июнь аенда, комитеттагы вазыйфасын калдырып, Мәскәүгә кайтып китә. Әмма аны, үзе съездда катнашмаса да, мөселманнарның Казанда узачак II Бөтенроссия съездын әзерләргә тиешле Милли шурага сайлыйлар.

Максуди, 1917 елның 20 июлендә ачылган II Бөтенроссия мөселманнары съездында доклад ясап, Идел-Урал төбәге һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясен игълан итәргә тәкъдим кертә. Бу көннәрдә Казанда руханиларның һәм хәрбиләрнең дә Бөтенроссия съездлары җыелган була. Садрый Максуди 22 июль көнне хәрбиләр, руханилар һәм II Бөтенроссия мөселманнары съезды делегатлары бергә җыелган мәҗлестә мөселман төрки-татарларның Милли-мәдәни мохтәрияте турында Декларация игълан итә. Аның башкаласы итеп Уфа шәһәре тәгаенләнә. Мәҗлестә Милли-мәдәни мохтәриятне вөҗүдкә чыгару комиссиясе һәм ноябрь аенда Уфада узачак Милләт мәҗлесен хәзерләү өчен Садрый Максуди рәислегендә Вакытлы идарә төзелә һәм эшли башлый.

Съезд Милли-мәдәни мохтәрият турында канун проектын кабул итә. Максуди тәкъдиме белән ул финанс, дин һәм мәгариф министрлыкларыннан торачак, дип раслана.

Бер үк вакытта Галимҗан Ибраһимов һәм бер төркем җәмәгать эшлеклесе тупраклы мохтәриятне яклап чыга, ләкин бу хакта җитди сөйләшүне Уфада булачак Милләт мәҗлесенә калдыралар.

Биредә берничә әйберне ачыклап китү сорала. Садрый Максуди, тупраклы мохтәрият илнең чик буе төбәкләрендә тупланып яшәүче халыкларга туры килә, ә таралып яшәгән татарларның милли тормышларын көйләр өчен бердәнбер кулай яшәеш формасы – милли-мәдәни мохтәрият дип санаган. Ә большевиклар милли-мәдәни мохтәриятне танымый, 1917 елның 2 ноябрендә ил халыкларына үзбилгеләнү хокукын биргән «Россия халыклары хокуклары декларациясен» кабул итә.

1917 елның 20 ноябрендә Уфада Эчке Русия һәм Себер мөселманнары Милли-мәдәни мохтәриятенең Милләт мәҗлесе ачыла. Мәҗлес 29 ноябрьдә Идел-Урал штаты (тупраклы мохтәрият) төзү турында карар кабул итә. 1918 елның 5 гыйнварында Милли идарәнең рәисе итеп Садрый Максуди сайлана. 11 гыйнварда Милли-мәдәни мохтәриятнең Конституциясе кабул ителә, Садрый Максуди Милләт мәҗлесенә таралырга һәм кабат май аенда җыелырга тәкъдим итә. Үзе, Милли идарә эшләре буенча урынбасары Ибниәмин Әхтәмевкә инструкцияләр калдырып, Казанга кайтып китә, җитәкчелектән читләшә. Бу көннәрдә Максудиның практик түгел, теоретик, публицист һәм оратор икәнлеге бик ачык күренә. Ә революция шартларында Садрыйга хас гаделлек, дөреслек кебек принципларга таянып эшләү кимчелек санала, киресенчә, кыюлык, кискенлек кебек сыйфатлар кыйммәт йөри.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘГЕ ТОРМЫШЫ

1918 елның 13 апрелендә большевиклар Милли-мәдәни мохтәриятне юкка чыгара. Милли идарә, аның нәзарәтләре, төбәкләрдәге җирле милли оешмалар ябыла, мохтәриятнең милке тартып алына, җитәкчеләре төрмәгә утыртыла. Садрый Максуди, кулга алынудан качып йөреп, Финляндиядәге татар җәмгыятенә барып сыена. Бу илдә яшәргә рөхсәт булмау сәбәпле, Стокгольмда виза юнәлтеп, Милли идарә вәкиле буларак, 1919 елның гыйнварында Парижда ачылган Солых конференциясенә бара. Россиядәге Казан татарларының аяныч хәле турында Америка, Англия, Франция делегацияләре җитәкчеләренә меморандумнар тапшыра.

Максуди 1920 елда виза җибәреп шулай ук Милли идарә вәкилләре Гаяз Исхакый һәм Фуад Туктаровны Япониядән Парижга чакыртуга ирешә. Аларның өчесен Франциянең булачак тышкы эшләр министры кабул итә. Татар җәмәгать эшлеклеләре Россиядәге төрки-татарларның милли хокукларын яклауда ярдәм һәм Төркия хәлифәтен төрекләр файдасына хәл итүне сорыйлар.

1921 елда Россиядә ачлык башлангач, алар Идел-Урал төбәге татарларына ярдәм оештыру максатында төрле дәүләтләргә мөрәҗәгатьләр тарата, бу эшкә үзләреннән өлеш кертә. 1922 елда Садрыйның дуслары аның гаиләсен Россиядән яшерен рәвештә Финляндиягә алып килә, җәй көне Максудилар Берлинга күчәнә. Садрый, акрынлап сәясәттән читләшеп, тарих фәне белән тәм табып шөгыльләнә башлый, иртәдән кичкә кадәр китапханәләрдә утырып, язылачак китаплары өчен материал туплый.

1923 елда кабат Франциягә кайта, Парижда кызларын гимназиягә укырга урнаштыра, яхшы гына фатирга күчәнә, бер сүз белән әйткәндә, тормышын җайлап җибәрә. Азия җәмгыятендә чыгышлар ясый. Шушы җәмгыятьнең ике күренекле әгъзасы тәкъдиме белән, аны Сорбонна университетының Славяннарны өйрәнү инситутына профессор вазыйфасына эшкә алалар. Ул биредә 4 декабрьдә төрки халыклар тарихы буенча беренче лекциясен укый.

Садрый Максуди бәлки Парижда яшәп тә калган булыр иде. 1924 елның көзендә ул үзе «Төрек очагы» җәмгыятенә барып лекцияләр укырга теләк белдерә. Биредә Мостафа Кемаль Ататөрек белән таныша, аралаша, Төркия Президенты аны Әнкарага эшләргә чакыра.

1925 елда, тәкъдимне кабул итеп, Садрый Максуди гаиләсе белән яшь республикага күчәнә. Бөтен сәләтен, гыйлемен, тәҗрибәсен демократик дәүләт коруга, дөньяви җәмгыять төзүгә һәм гуманитар фәнне үстерүгә багышлый.

ОЛЫ ТИГӘНӘЛЕНЕҢ ОЛЫ СӨЕНЕЧЕ

Автор: Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

– Республика авыллары буйлап сәяхәт иткәндә берәр (ә кайсыбер очракта берничә) гаҗәп кеше белән очрашасың да таң каласаң. Инде янә бүтән болай тәэсирләнмәм, дип уйлыйсың. Ә юк, янә сокланасың! Алексеевск районының Олы Тигәнәле авылына баргач та, әнә шундый гаҗәп кешеләргә тап булдык.

ОЛЫ ТИГӘНӘЛЕ

ТАРИХЛЫ АВЫЛ

Алексеевск районында татар авыллары бармак белән генә санарлык. Олы Тигәнәле шуларның берсе. Биләргә бара торган юлда кала ул. Мәдәният йорты каршына килеп туктагач та «аһ» иттек – каршыда җәелеп елга ага. Ул нәкъ авыл уртасында. Шул елга буеннан урамнар уч төбендәге кебек күренеп тора. (Йортлар тау башынарак урнашкан). Искиткеч матурлык! Өстәвенә табигатьнең уянган мәле – бөтен җирне яшькелт төскә манып, яшел чирәм борын төртеп килә. Ә һавасы!..

Шушы матурлыкка карап күпме исәрләнгән булыр идек, телефон шалтырады – Туган як музеена килергә чакыралар. Машинабызга утырып шунда киттек.

Без булган авылларның («Татарстан» журналы татар авыллары турында даими яза) бик сирәгендә генә музей бар. Аерым бинасы, дәүләт статусы булган музей турында сүз бара. Олы Тигәнәледә андый дәрәҗәле урын бар икән. Авылның хөрмәтле апалары шунда җыелып, безне көтеп тора булып чыкты.

Танышабыз, бик сөйкемле ханым – музей җитәкчесе Фаягөл Хәлилова икән.

– Биредә әле сентябрьдән генә эшлим, аңа кадәр егерме биш ел мәктәптә физика, математика укыттым. Музей эше бик күңелле, үзем өчен күп яңалыклар ачам, – дип сүз башлады ул.

Музей рәсми рәвештә 2003 елда ачылган. Авыл кешеләренә мәдрәсә буларак та хезмәт итә ул. (Дөрес, рәсми рәвештә түгел.) Музейның оешу тарихын Лилия ханым Зарипова сөйләде, чөнки ул биредә ике дистә елга якын эшли.

– Уналты ел музейны җитәкләдем. Лаеклы ялга чыккач, фонд буенча җитәкче булып калдым. Бездә дә кәгазь эше күп бит, Фаягөл яшьрәк, шуңа да урынымны аңа бирдем. Бик аңлашып эшлибез. Музейның чишмә башында хөрмәтле мөгаллимә Даһия апа Хафизова тора. Бик авыл җанлы иде ул, туксан биш яшенә кадәр яшәде. Даһия апа музейны башта мәктәпнең бер классында оештырды. Инде экспонатлар күбәйгәч, үзенең укучысы – Әлмәт «Татнефтепромның» элеккеге җитәкчесе Ралиф Кәрим улы Зариповка мөрәҗәгать итте. Ул чагында район башлыгы

1
Мәдәният йорты каршына килеп туктагач та «аһ» иттек – каршыда җәелеп елга ага.

2 3
Музей өч яклы, заманча, зур. Авылның бар тарихын үз эченә алган.

4
Музейның оешу тарихын Лилия ханым Зарипова сөйләде.

5
– Олы Тиганәледә дүрт мәчет эшләгән, – диде Гөлсирә апа Хәмәтшина.



Алексей Иванович Демидов иде. Алар бергә әлеге бинаны төзеп чыктылар.

Олы Тигәнәле музее белән танышып чыктык. Өч яклы, заманча, зур ул. Авылның бар тарихын үз эченә алган. Аннары биредә зурлап сөйләрлек, республика тарихында да эз калдырган шәхесләр күп. Мисалга, Олы Тигәнәленең атаклы уллары Батталовларны китерергә була: Салих Баттал – язучы; 1941 елны Мәскәү консерваториясен тәмамлаган Мөбарәк Баттал исә – Татар дәүләт опера һәм балет театрында гобойчы; Абдулла Баттал – җәлилчеләрдән берсе. Һәркайсының язмышы турында аерым язарлык...

Музей мәдрәсә ролен дә үти, дидем. Бүген биргә Олы Тигәнәленең унлап хатын-кызы дин сабагы өйрәнергә килә. Фәния Нәсыйхова – әнә шул гүзәл затларның берсе. Утыз биш ел буе авыл мәктәбендә балаларга немец теле укыткан ул. Хәзер инде лаеклы ялда.

– Шушында килергә атлыгып торабыз, – ди Фәния апа. – Гарәп графикасын өйрәндек. Аллаһка шөкер, инде кулда Коръән. Алга таба да дини гыйлемебезне арттырырга язсын.

Авыл хатын-кызларына дин гыйлемен Гөлсирә апа Хәмәтшина өйрәтә. Гомер буе мәктәптә балаларга белем биргән хөрмәтле укытучы ул. Яраткан эшеннән китсә дә, һаман да аң-белем таратуда. Авылның акъэбисе дә икән, Коръән укырга, мәет юарга да аны чакыралар.

– Мин шушы авылда тудым, шушы авылда гомер иттем, – диде Гөлсирә апа. – Тормышның төрле вакытын күрдем. Мөгаен, халык өчен иң яхшы чор – совхоз оешкач булгандыр. Әйбәт хезмәт хакы да алып эшләделәр, газ да керде.

– Ә дингә кайчан килдегез? – дим.

– Күңелдә иман гел яшәде. Әби-бабайларыбыз да динле булган. Олы Тигәнәледә дүрт мәчет эшләгән. Без исә шул туксанынчы елларда, халыкка дин юлы ачылгач килдек. Аллаһка шөкер, авылыбыз иманлы. Өч партия укучылар чыгардым инде. Гарәп хәрефе танымаган хатын-кызлар бик аз кеше калгандыр. Кемнең теләге бар, барысы да өйрәнде. Хәтта ир-атлар да укыды.

САРЫК БИЗНЕСЫ

Олы Тигәнәледә 186 хуҗалык исәпләнә, 471 кеше яши. Биредә татарларга хас тырышлык күзгә ташлана. Йорт-җирләре ялт иткән. Мөгезле эре терлек асраучылар да күп. Мисал өчен, шәхси хуҗалык статусында йөргән өч гаилә бар. Аларның берсендә 10, икенчесендә 12, өченчесендә 21 баш савым сыеры бар. Атлар тотучы гаилә дә яши. Без исә сарык асраучы кешеләр – Гатиннар хуҗалыгында булдык. Гаилә башлыгы Әсгать абый башлаган эшне бүген улы Марсель дәвам итә. Казанда югары белем алганнан соң, егет яшәргә туган авылына кайткан.



6 7
– Фермерлык эшенә 2003 елда керешкән идем, – диде Әсгать Гатин.

– Фермерлык эшенә 2003 елда керешкән идем, - диде Әсгать абый. – КФХ булып теркәлдем. Заманында үгезләр, сыерлар да асрадым. Бүген исә сарыклар гына тотам, мөгаен, иң отышлысы шулдыр. Бүгенге көндә 250 баш сарыгыбыз бар. Корбанга да күпләп үстерәбез. Көнаралаш килеп алалар. Хәзер җәй көне бигрәк сорау зур. Ел әйләнәсе буенча санасаң, мең баш сарык үстерәбездер.

Гатиннарга ул яктан уңайлы – бакча артларында гына болын. Сарыкларны алып чыгып, өчәр чакрым ераклыкта йөртеп кайтаралар. Без килгәндә дә маллар болында йөри иде. Хуҗалар сарыкларның меринос токымына өстенлек бирә икән – авырлыкны тиз җыя, ите тәмле.

– Йонын нишләтәсез? – дидем әле «туннарын» салмаган сарыкларга карап.

– Үзебез алабыз. Хатын, малай, үзем... Йон кыркый торган электр машинабыз бар, аның белән тизрәк. Тик андый аппарат йонны калдыра, шуңа күрә калганын гади кайчы белән кисәбез.

– Ике йөз илле баш сарыкның йонын ничә көн аласыз? – дим.

– Төрлечә инде, вакытка карап. Аның бит яшь бәрәннәре бар, аларына тиясе түгел. Шуңа ике йөз илле баш ук булып чыкмый. Элек йонны кешегә акча түләп алдыра идек, соңгы елларда үзебез маташабыз. Әйтәм бит, электр машинасы алдык.

– Ә сарыкның йонын, тиресен нишләтәсез?

– Йонның бәясе тиеннәр генә, ташласаң да була. Тиресен бөтенләй чүплеккә атабыз. Берәүгә дә кирәк түгел. Ите ярый инде, килосын 400 сумнан сатабыз. Игенен, печәнен сатып алмаганда, сарык асрарга була.

Гатиннарның кырык дүрт гектар җирләре дә бар. Печән, иген үстерү өчен техникасын да юнәлткәннәр. (Барысын да берәмләп үз акчаларына сатып алганнар). Көтү көтәргә, сезон вакытында булышырга даими эшкә бер кеше яллаганнар. Калганына үзләре. Гаиләдә берәү дә тик тормый.

– Әле ике кибет тә тотабыз, – ди Әсгать абый. – Кибеттә хатын сату итә. Марсель белән чиратлашып без товар алып кайтабыз. Кибетнең бер ягы кафе кебек – ризыклар әзерлибез. Авылның уңган бер хатынын пешекче итеп эшкә алдык. Бик тәмле пироглар пешерә, яратып алалар.

АЛТЫН КУЛЛЫ ГАИЛӘ

Без, журналистлар, кая барсак та, кызык шөгыльләре булган, үзенчәлекле кешеләрне, гаиләләрне эзлибез. Олы Тигәнәледә ун, сигез балалы гаиләләр бар икән. Тик алар өйдә булып чыкмады. Аның каравы, бик үзенчәлекле гаилә – Бәйрәмовлар белән таныштык. Ир белән хатынны чын мәгънәсендә сәнгать осталары дияргә була. Һөнәрләре буенча икесе дә укытучы. Хәлил абый мәктәп директоры булып та эшләгән. Хәзер инде гади укытучы. Ә Фәридә апа лаеклы ялда, эштән киткән. Бәйрәмовларның йорты музейны хәтерләтә, җитмәсә, һәр бүлмә төрле «экспонатлар» белән тулган. Ишегалдына аяк баскач та, биредә иҗади кешеләр яшәгәнлеген аңлыйсың – башта ук аккошлар, пингвин, ләкләкләр «сәламли». Ир белән хатын үзләре дә бик сөйкемле, елмаеп кына торалар.

Фәридә апа, кәгазьне түгәрәкләп, башта нәзек көпшәләр, аннан аларны беркетеп, төрле фигуралар – тегермән, йорт, читән һ.б. ясый. Аеруча шундый технология белән ясалган курчаклары сокландырды. Кәгазь көпшәләрдән чын курчак ясап куйган!

– Бер елны балалар белән конкурска әзерләндек, шунда бу юнәлешне өйрәндем, – диде Фәридә апа. – Аннан соң укучыларга өйрәттем. Хәзер интернеттан карап әлләниләр эшләргә була бит.

Хәлил абыйның да фантазиясе көчле. Ул вазаларга кадәр ясый. Хатыны иҗат иткән курчак, читәннәрне буйый. Тагын бер шөгыле – тал чыбыгын бөкләп, вазага кую өчен чәчәккә әйләндерә.

– Тал чыбыгын язын кисеп алырга кирәк,- ди хуҗа кеше. – Аннан көрәк сабына чорнап куям. Ул шулай бөтерелеп кибә. Шуннан тал чыбыгын буярга, төсле тасмалар белән чорнарга мөмкин.

Фәридә апаның кулыннан килмәгән эше юк – бәйли, тегә, сәйләннән картиналар, чәчәкләр, хәтта йомырка кабыгын төеп тә әллә нинди савытлар ясый.

Ирле-хатынлы Бәйрәмовлар икесе дә диндә. Хәлил абыйның тарихы аеруча үзенчәлекле:

– Ике ел элек тавыклар бер-бер артлы гарәпчә «Аллаһ» дип язылган йомырка салды,-диде гаилә башлыгы. – Без аларны гарәпчә яхшы белгән кешеләргә дә күрсәттек. Чынлап та шулай, диделәр. Менә шуннан соң намазга бастым, Аллаһ Тәгаләдән моны бер билге дип кабул иттек.

Хәлил абый ул йомыркаларны безгә дә күрсәтте. Чынлап та, гарәп хәрефләренә охшаган язулар бар анда. Гаҗәп...

ЗАМАНЧА МӘКТӘП

Олы Тигәнәленең горурлыгы, олы сөенече – яңа ачылган мәктәп. Бер ел эчендә салып чыкканнар аны. Балалар бакчасын да үз эченә сыендырган бина әллә кайдан балкып тора.

8 9 10
Хәлил Бәйрәмовның да фантазиясе көчле. Ул вазаларга кадәр ясый. Хатыны иҗат иткән курчак, читәннәрне буйый.

11


8


9

10

Мәктәптә кырык алты бала укый, балалар бакчасына 15 сабый йөри. Бакчага килмәгән өч яшькә кадәрле сабыйлар да шактый икән әле. Кыскасы, мәктәпнең киләчәге бар.

– Дөресен әйтим, мондый заманча бина безнең өчен могҗизага тиң булды, – ди сөйләде Олы Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе директоры Айсылу Сәйфетдинова. – Мондый мәктәп әлегә республикада юк дип беләм. Бәхет инде бу, зур бәхет.

– Ә мондый бәхет сезгә ничек елмайды? - дим.

– Элеккеге мәктәп 1985 елда төзелгән иде. Түбәсеннән су ага, тузган иде. Махсус комиссия килде, төзекләндерү мөмкин түгел, дигән нәтиҗә чыгардылар. Әле бездә 2024 елда гына мәктәп салынырга тиеш булган. Тик шушындый хәл булгач, тиз генә эшләргә карар кылалар. Әлбәттә, район башлыгы Сергей Демидовның тырышлыгы да бу. Ул безнең авылга, гомумән, җирле татарларга карата хәерхаһлы мөнәсәбәттә.

Берара авылда мәктәпне ябалар дигән хәбәр дә таралган. Укытучыларда да шундый курку хисе булган. Ә нәрсә, күрше Урта Тигәнәле авылында урта мәктәп бар, тоталар да балаларны шунда күчерәләр. Тик, бәхеткә, авыл кешеләренең, укытучыларның фаразы чынга ашмый.

– И, Олы Тигәнәле кебек борынгы, тарихи авылда мәктәп ябылса, авыл өчен зур фаҗига булыр иде, – диде Айсылу Сәйфетдинова. – Шөкер, Аллаһ Тәгалә безне ишетте. Әле бит мәктәбебез районда татар телен өйрәнү үзәге булып та тора. Татар мәктәпләренә кагылышлы барлык чаралар да бездә уза хәзер. Ел дәвамында башка мәктәпләрдән укучылар, укытучыларны кабул иттек. Татарча рәхәтләнеп аралашып, семинарлар, төрле ачык дәресләр үткәрдек.

Олы Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе сиксән укучыга исәпләнгән. Классларны карап чыктык – барысы да заманча. Һәр сыйныф бүлмәсендә проектор бар, химия, физика кабинетлары җиһазландырылган. Якты, иркен заллар. Биредә укучы балалар өчен чын күңелдән сөенеп йөрдем.

Укучы дигәннән, берничә ата-ана белән сөйләштек. «Улым, кызым, фәлән югары уку йортын тәмалап, шундый урында эшли», – дип бер горурлык белән сөйләделәр. Хәтта күзләренә яшь килде. (Менә ул балаң белән горурлануның чын үрнәге!) Чынлап та, зур дәрәҗәләргә ирешкән егет-кызлар бар биредә.

...Сөенеп кайттык Олы Тигәнәледән. Беренче чиратта шундый заманча мәктәп салынуы куандырды. Кырык баламы, иллеме, мөһим түгел, алар заманча белем бирү йортында укый һәм ана телләрендә белем ала. Аның бит әле икенче ягы да бар – яшьләрне авылда калдыру өчен бер кызыксындыру чарасы да бу. Авылга яңа сулыш өрү дә. Тырыш, кунакчыл халкы турында әйткән дә юк. Биләргә юл тотсагыз, Олы Тигәнәлегә дә кереп чыгыгыз, үзегез дә инанырсыз. Т

11

Мондый заманча бина безнең өчен могҗизага тиң булды, – диде Айсылу Сәйфетдинова.

12-13

Олы Тигәнәле төп белем бирү мәктәбе сиксән укучыга исәпләнгән

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

«...Безнең Тигәнәле авылының исеме каян килеп чыгу турында ике төрле сүз йөри, – дип яза Салих Баттал. – Берәүләр, авылны буеннан-буена урталай бүлеп аккан инеш тигәнә кебек казылма юл салганга, авыл «Тигәнәле» дип аталуын әйтәләр. Авылдашыбыз Максуд Мөбарәкҗаны болай дип аңлаткан иде: «Бабаларыбыз биргә күчеп килгәндә бу урында тигәнәк (кырмавык) үсемлеге баскан булган. Шуңа «Тигәнәкле» дип атаганнар да, тора-бара «к» хәрефе төшеп калган». Салих аганың әйтүенә карагандa, авылыбызга нигез салынуга дүрт йөз сиксән еллар бар. «Ун баба чамасы» – дигән иде Максуд Мөбарәкҗаны 1946 елда», – ди ул. Безнең авылны Олы Тигәнәле дип тә, Зур Тигәнәле дип тә һәм Иске авыл дип тә йөртәләр».

(«Олы юлда Олы Тигәнәле» китабыннан. Авторы – Бәдретдин Шәйхетдинов).

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КИЛӘСЕ САНЫНДА:

Үзеңнең гаджетларга кереп чумган балаңнан «Кама диңгезе» күренешләренә, Лобач тавы мәгарәләренә, Балык Бистәсе маралларының кызыксынучан күзләренә карап, «Нинди матур!», «Шундый шәп!», «Нинди сөйкемлеләр!» дигән сокланулы сүзләрен ишетү рәхәт түгелмени? Һәм үсмер балаңның гаҗәпләнеп: «Ой, ә без кайда соң?» – дигән соравына: «Бу синең Ватаның, улым!» – дип җавап кайтару?

СӘЯХӘТЛӘР БУЕНЧА БЕРЕНЧЕ

Сәяхәтләр буенча төп вазыйфаны үтәүче «Татарстан»ның киләсе саны Татарстан дип аталган Ватаныбыз буйлап сәяхәтләргә багышлана.

Фото: Алексей Ушаков

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Фото: Александр Ефремов

Мари гүзәле.

Татарстанда 18 848 мари кешесе яши (2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).

* Татарстаннан сезне яратып! (маричадан тәрҗемә)

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Фото: Александр Ефремов

Халыклар Дуслыгы йортында «Татарстанның чуваш гүзәле – 2021» конкурсы. Апрель, 2021 ел.

Татарстанда 116 252 чуваш кешесе яши (2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).

* Татарстаннан сезне яратып! (чувашчадан тәрҗемә)